Н. ӘХМӘДИЕВ

КОЯШ ЭЗЛӘҮЧЕ МАЛАЙ

Н. ӘХМӘДИЕВ

КОЯШ ЭЗЛӘҮЧЕ МАЛАЙ

ЛИРИК ҺӘМ ЮМОРИСТИК ХИКӘЯЛӘР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1989

ББК 84(2Р-Тат)-4
Ә87

Ә $\frac{4803010200-014}{М132(03)-89}$ 144—89

ISBN 5—298—00123—8 © Татарстан китап нәшрияты, 1989.



МИНЕМ ТУГАН КӨНЕМ

АНА

Автобус нигәдер озак килми торды. Көне буе җыелышта утырып талчыккан делегатларның түземлеге бетә башлады. Бетәр дә, озакламый төнге ун тула бит. Әле утызкырык чакрым кайтасы да бар. Ә өйдә бала-чага, малтуар... Тышта җелекне куырып алырлык салкын, җиргә төшеп җиткәнче төкрегең бозга әверелә. Ким дигәндә утыз градус бардыр. Кайберәүләрнең өендә миче ягылмаган, ыңгырашып ачылачак бәсле ишектән суык өйгә кайтып керәсеңне уйлауга ук тәннәрең чымырдап китә, бөрешкәнеңне сизми дә каласың. Хәзер бит җылы түшәктә, сыеныр кешең булганда аңа терәлеп сырт кыздыра, тәмле төшләр күреп, изрәп йоклый торган вакыт. Нишләп юк соң бу автобус дигәннәре?

Бәхет бөтенләй үк ташлап бетермәгән икән әле. Күзләрне яктыртып, ниһаять, «пазик» килеп туктады. Шоферы, яшь кенә егет:

— Делегатлармы? Рәхим итегез! — дип, салондагы утын яндырды.

Утыру озакка бармады, җылы автобуска кереп тулгач, күңелләр күтәрелеп китте. Кайберәүләр, ихтимал, үзләрен инде җылы өйләрендә дип хис итә башлагандыр.

Кузгалыр алдыннан шофер, гафу үтенгән тавыш белән безгә мөрәҗәгать итте:

— Иптәшләр, вокзалда безнең якка кайтучы бер егет бар, кереп алсак, ни диярсез? Урын табарбызмы?

Вокзалга өч минутлык юл, кем каршы килсен:

— Утырсын, утырсын! — диештек.

Безнең якка соңгы автобус киткәнгә биш былтыр. Иртәнге алтысыз егылып үләм дисәң дә бер машина да очрамаячак. Ул пассажир да адәм баласы бит. Бәлки, ул, озак еллар чит җирләрдә каңгырып йөргәннән соң, җирсеп, өенә кайтып баручы берәр зимагурдыр. Кемнеңдер газиз баласы... Әллә инде... Әй, фараз итүнең кирәге бармы икән? Ризыгы кемне кайда алып китмәс тә кемне кайда йөртмәс.

Кая гына барып,ниләр күрми
Ир-егеткәй белән ат башы...

Вокзалда интегеп төн уздырганчы, туганнары, якыннары янына кайта торсын.

Шофер, автобусын вокзалның ишек төбенә үк китереп туктатты да кереп китте һәм озак та тормый бер кулына таяк, икенчесенә кечкенә чемодан тоткан егетне култыклап алып чыкты. Таягы белән җирне еш-еш капшавыннан егетнең сукыр икәнлеген аңлау кыен түгел иде.

Егетне күрүгә арткы рәтләрнең берсендә утырган апа урыныннан торды, без ни дә булса уйларга, аңларга өлгергәнче, сүзсез генә барып, сукырны житәкләде һәм үзенең янәшәсенә алып килеп утыртты. Табигый кызыксыну хисе безне әле шул якка каратып тота иде. Җитәкләп алып килгән хатынның ничек итеп сак кына сукыр егетнең кулын сыйпаганын күреп алдык.

Шунда кинәт, барыбызны да аптыраштa калдырып:

— Әнием, исәнме, әнием! — дип, егет бу апаны кочагына кысты.

— Улым, исәнме, бәгырькәем! Нишләп кайтасы иттең? Нәрсә булды? Кыерсыттылармы әллә? — Калтыранган тавыш белән сөйләнә-сөйләнә апа егеткә текәлде.

Сукыр егетнең «күрәсем килде» дигән сүзе безне сискәндереп җибәрде. Йөрәкләр өзелеп төштемени! Ана белән баланың көтмәгәндә-уйламаганда болай очрашуларына ышану кыен иде. Ничектер, төштәге кебек. Хәтта төштә дә алай ук булмастыр.

Әллә кызыксынулы-сораулы карашыбызны тоеп, әллә болай гына, әлеге апа безгә аңлатма бирүне кирәк тапты:

— Бер атна элек кенә әле үзен, колхоздан машина алып, Әлмәткә илтеп куйган идем. Сукырлар җәмгыятенә. Бер дә ялгызы юлга чыкканы юк иде балакаемның... Әйбәт кенә эшләп калган идең бит, балам-бәгырем, ник кайтасы иттең? Кем белән кайттың?

Егет, сабый бала кебек, хатынга сыена төште:

— Ялгызым, әнием. Беләсем килде: үзем генә йөри аламмы икән? Яңадан мине илтеп йөрмәссең, әнием, үзем генә барырмын. Атна саен кайтып, сине күреп торырмын. И-и, әни, кешеләр барысы да шундый яхшылар, безнең авылдагы кебекләр, ярдәм итәргә генә торалар.

Автобус эчендәге саран яктылыкта ана белән баланың күз төпләренә чыккан яшьләрен һәм бәхетле йөзләрен күреп, без алар арасындагы яктылыкның никадәр югары, саф, тирән икәнлегенә ышандык.

Аларның авылы Бүләккә кайтып җиттек. Җай гына барган автобус тормозларын сыкратып туктауга, ана белән бала төшеп калдылар. Без тәрәзәгә каткан калын боз катламнарын эретә-эретә, кузгалып китмичә, аларның бер-берсенә сыена төшеп атлауларын озак карап тордык.

Энисе үзен култыклап алса да, сукыр егетнең, таягын сузып, мина эзләгән шикелле, алдагы сукмакны капшап барганы күренде. Вакыт-вакыт аның дюраль таягы ай яктысында көмеш сыман ялтырап китә. Миңа калса, нигә-

дер, таягы белән ул юлны капшамый, бәлки киләчәк язмышына разведка ясый сыман тоелды.

Ниһаять, алар зират коймалары артына күмелеп, күздән югалдылар. Без бары тик шуннан соң гына юлыбызны дәвам иттек. Машинада тынлык урнашты. Күрәсең, барыбыз да бер нәрсә хакында уйлый идек. Шактый баргач, тынлыкны безнең колхоз председателе Сабирҗан абзый бозды:

— Ә бит ул аның баласы түгел...

Күз алдында җитмештәге карчык унҗиде яшьлек кызга әверелсә, яки аяз көнне яшен сукса, безне бу кадәр гаҗәпләндермәс иде.

— Кит аннан!

— Ни сөйлисең син?!

— Чынлап әйтәсеңме?!

Үзебезнең авылга кайтып җиткәнче Сабирҗан абзыйдан шактый нәрсә белергә өлгердек.

— Буләктә укыткан чакта Факияләрнең күршесендә торган идем мин. Факиянең кайдан баласы булсын, кияүгә дә чыкканы юк аның.

— Балаң булсын өчен кияүгә чыгу мәҗбүри түгел,— дип, ир-атларның берсе төрттерә башлаган иде, Сабирҗан абзый шактый ачулы тавыш белән туктатты:

— Син, энем, авызыңны үлчәп ач. Һәркемне дә бер калып белән үлчәмә. Факиягә җитәргә ерак әле безгә.

Хатын-кызларның гына түгел, ир-атларның да кызыксынулары шул дәрәҗәгә җитте ки, хет автобустан сикереп төшеп кал. Төн уртасы җитеп килгәне дә онытылды.

— Ничек инде алай? — Илле яшьләрендә булуына карамастан, чибәрлеге күзгә ташланып торган бу ханымның үзенә пар тапмый картаюына ышанасы килми иде.

Сабирҗан абзый безнең түземлекне сынарга теләдеме, әллә үзе дә дулкынлана идеме, ашыкмыйча гына кесәсеннән тәмәке чыгарды, аны кабызырга шырпы эзләде. Шырпысын сызгач, өреп кире сүндерде. Гаепләп сүз әйтүче табылмаса да, тәмәкесен тартмасына кире яшерде. Аннан соң гына сүз башлады.

— Яшь чагында Факия эчендә җаны бар теләсә нинди

егетнең һушын алырлык дәрәҗәдә чибәр, сылу иде. Кургәнсездер, хәзер дә төшеп калганнардан түгел. Әтиләре сугышта үлгән, әнисе белән икесе яшәделәр. Янында егетләр югыйсә аз бөтерелмәделәр, ә ул гармунчы Сәйфине яратты. Туйлары көзгә буласы авылдашларына билгеле иде. Аналары, кодагый дип, бер-берсе чәйгә, мунчага чакырышалар иде. Авыл халкы Сәйфи белән Факия туена иртәгә көн туасына ышанган күк өметләнеп яшәде. Тик туй булмый калды.— Сабирҗан абзый авыр сулап куйды.

— Нәрсә, Сәйфи үлдеме әллә? — Түземсезләнеп, минем янда утырган Галимә шундый сорау бирде. Галимәнең генә түгел, барыбызның да хикәянең азагын беләсебез килә иде.

— Факияләрнең икенче як күршесендәге Зәйнәп апа үлде. Аяклары сызлап, бик озак җәфаланган иде, мескен. Баласы ятим калды.

— Ире юк идемени?

— Бар иде. Мәрдан абзый сугыштан контузия белән кайткан иде, Зәйнәп ападан ел ярым чамасы алданрак үлде.

— Сабирҗан абзый, син сөйләгәннәрнең Факиягә ни катнашы бар? — дип сорады берәү.

— Зәйнәп урыныннан торалмый ятканда Факия кереп бөтен эшләрен карады, малларын ашатты-эчертте, авыруны тәрбияләде. Күршесе үлгәч, ятим малайны үзләренә алып чыкты. Ришат аңа бик тиз ияләнде, күрәсең, электән кереп йөргәнгәдер, Факияне озакламый әни дип йөри башлады.

— Бу егет Ришаттыр бит инде?

— Шул үзе.

— Ә нишләп сукырайды?

Сабирҗан абзый тәмәкесен тагын авызына капты.

— Тумыштан сукыр булган ул.

— Шуннан?

— Шуннан шул. Туйга бер-ике атна калгач бик каты үпкәләшкәннәр болар. Сәйфи Ришатны я берәр туганнарына, я балалар йортына илтеп тапшырырга кушкан. Ык

аръягындагы Мостафа авылында Ришатның әнисе белән бертуган апасы бар икән дә бит, үзенең дә сигез бала, ди. Ул кая куйсын? Җитмәсә, сукыр баланы. Факия Ришатны беркемгә дә бирмәсен әйткәч, Сәйфи:

— Бирнәгә сукыр бала алырга минем башыма тай типмәгән лә! Я — ул! Я — мин! — дигән. Факия барыбер сүзеннән кайтмагач, ул кайнар баштан бүтәнгә өйләнде.

Галимә:

— Сез, ирләр, гел шулай инде: койрыкны сыртка салырга гына торасыз,— дия башлаган иде, аңа:

— Туктап тор, сөйләп бетерсен,— дип әйттеләр.

— Барыбер ул хатын белән озак тормыйча аерылыштылар,— дип дәвам итте Сабирҗан абзый.— Сәйфинең гафу үтенеп соңыннан Факия янына әллә ничә тапкыр килгәнен мин дә беләм. Тегесе тыңлап та тормаган. Башкалар белән дә йөрмәде, килгән яучыларны да кире борып җибәрде. Тәки шул көе картаеп бара икән. Менә шулай хәлләр... Мин ул авылдан киткәндә Ришатын сукырлар мәктәбендә укыта башлаган иде инде Факия. Илтеп куйды, кайтыр вакытында барып алды. Бүген очрашкач сөйләшеп торган идек: Ришатны күптән түгел Әлмәткә эшкә урнаштырып кайттым, диде. Ялгызын гына юлга бер дә чыгармаган. Шул бала бүген хәбәрсез-нисез кайтып төшсен инде. Гаҗәп. Бик гаҗәп! — диде Сабирҗан абзый, үз сүзен куәтләп.— Күрәсең, сагынуына түзеп тора алмагандыр. Сагыну бит ул...

Ул сүзеннән туктап калды. Шунда күз алдына тагын айлы сукмактан бер-берсен җитәкләп атлаган Ана белән Бала килде. Башкалар ничектер, әмма мин, кайберәүләр үз балаларыннан да ваз кичеп, яңадан-яңа ятимнәр йортлары ачылган бу заманда Ришат хакына яшьлек мәхәббәтеннән, бәхетеннән баш тарткан Факияне, гомерем буена белгән кешем кебек, бик якын иттем. Ул миңа баласын коткару өчен дөрләп торган ут эченә ташланучы да, бозлы суга сикерүче дә, сабыйны ышыклап фашист пулясына каршы баскан батыр партизанка булып та күз алдыма килә иде. Ир назын тоеп карамаган, кыз көенә картайган бу кеше Ана дигән бөек исемгә лаек түгелмени? Лаек,

йөз тапкыр, мең тапкыр лаек. Шушы хакта минем бар дөньяга аваз саласым, кычкырасым килде.

Юлдашларым да дәшмиләр, күрәсең, алар да шул хакта уйлыйлар иде.

ПОЕЗД

Нәсимнең поезд үткәнен якыннан күрәсе килә.

Үзләре турысыннан үткәндә ерактан тепловоз кычкыртканын ишеткән саен ул, карарга дип, тәрәзәгә каплана, ләкин, никадәр генә инәлеп карамасын, поезд үзе күренми. Бары тик аның артыннан калган аксыл төтен генә һавада бераз эленеп тора да эреп, юкка чыга иде.

Поезд карарга барыйк дип күпме ялынды инде ул әбисенә. Тик әбисе әле аякларым сызлый, әле вакытым юк, әле башым авырта дип, сәяхәтне һаман кичектерә килде. Ә Нәсимнең күрәсе килә шул поездны, бик күрәсе килә...

Әнисенең чыгып киткән көнен бүгенгедәй хәтерли әле Нәсим. Әтисе эштә, әбисе базарга киткән чак иде. Әнисе кайтты да, кызу-кызу әйберләрен җыеп, сары чемоданга тутырды. Аннан соң кәгазьгә нәрсәләрдер язып Нәсимгә тоттырды:

— Мә, улым, әтиеңә бирерсең!

Үзе чемоданын алып чыгып китте.

Соңгы вакытта аның әнисе әллә нишләгән иде. Элек ул Нәсимне сөя, уйный, шаяра, көлә торган иде. Аннары озаклап югалып тора башлады. Кайткач та орынып-бәренеп йөри иде. Аңардан бу көннәрдә әтисенә, әбисенә, хәтта Нәсимгә дә җитәрлек эләгә иде.

Ә әтисе... Һи, Нәсимнең әтисеме? Эштән никадәр арып кайтмасын, Нәсим белән уйнарга, шаярырга вакыт тапмый калмый.Ниләр генә ясап бирмәде ул аңа! Дус малайларының берсендә дә Нәсимнеке шикелле кызык уенчыклар юк. Шуның өстенә әтисе экиятләрне кү-үп белә. Мөгаен, әбисенекеннән дә күбрәктер.

Әтисенең эштән кайтуын түземсезлек белән көтеп ала Нәсим. Ишектә күренүгә, каршысына йөгереп бара да муенына асылына. Әтисе, елмаеп, аны күтәреп ала һәм

туп чөйгәндәй түшәмгә кадәр ыргыта. Аның көрәк кадәр кулларына килеп төшүдән Нәсим һич кенә дә курыкмый. Чөнки бер дә авырттырмасын белә. Киресенчә, аңа шулкадәр рәхәт булып китә. Рәхәтлектән ул чырык-чырык көлә башлый, аңа этисе дә кушыла. Аннан соң көрәшеп тә алалар. Кайвакыт Нәсим этисен җиңә: аның өстенә менеп кунаклагач, шатлыгының чиге булмый:

— Әби, кара әле, мин җиңдем! — дип, әбисен чакыра.

Соңыннан алар әбисе җылыткан ашны бергә утырып ашыйлар. Кайвакыт Нәсимнең ашыйсы килми, бары тик этисеннән аерылырга теләмәгәнгә генә өстәл янына кунаклый иде.

Ул көн исә башкачарак тәгәлләнде. Нәсим, этисе ишектән керүгә:

— Менә, эти, энием сиңа бирергә кушты! — дип сөенче алган иде. Тик, нигәдер этисе Нәсим көткәнчә куанмады, киресенчә, аның кәефе китте, чырае караңгыланды. Моны Нәсим дә сизенде, этисен артык борчымаска тырышты.

Төн җитте. Күптән йокларга вакыт, ә энисе һаман юк та юк. Икенче, өченче көнне дә кайтмады ул. Әйе, озак күрми торгач энисен дә сагына башлады Нәсим. Соңгы вакытларда үзен еш ачуланганын да онытып сагына иде. Энисенең кайдалыгын сорап өйдәгеләрне йөдәтеп бетерде. Ахырда әбисе:

— Эниең поездга утырып киткән, улым,— дияргә мәҗбүр булды. Менә шул көннән соң Нәсим аңына поезд балаларны эниләреннән аеручы явыз бер нәрсә булып кереп калды. Ничек кенә якыннан күрергә шул поездны?! Аңа энисе һәрчак поездда йөридер, улын күрер дә, сагынганын белеп, төшеп калыр һәм алар бергәләп өйгә кайтырлар кебек иде. Кайтсын гына, энисен бүтән беркайчан да поездга утыртмас ул. Тепловозлардан калган төтен якында сыман күренсә дә, Нәсим тимер юл янына бара белми, әбисе үзен генә җибәрми иде.

Шулай да онығы көн дә сорап, йөдәтеп бетергәч, әбисе түзмәде, беркөнне Нәсимне тимер юл буена алып китте. Менә нинди икән ул поездлар йөри торган юл! Бер-берсенә

аркылы агачлар белән беркетелгән рельсларның еракка-рак киткән саен аралары якыная икән һәм, ниһаять, тоташ тасма хасил итеп, алар күздән югалалар. Шул рельсларга карап, яр башындагы яшел чирәмдә озак утырдылар алар. Ә яшел поезд, нигәдер, килмәде дә килмәде. Нәсимнең бик көткәнен белми микәнни ул?

Әбисе кайтырга кыстый башлады. Тик Нәсим:

— Әби, әбекәй, тагын әз генә утырыйк инде?! Килә ул, барыбер килә,— дип туп-туры күзенә карагач, ул яшькә томаланып, тыелып калды. Никадәр өмет, ялвару бар иде оныгының сүзләрендә һәм инәлгән карашында!

Нәсимнең сизенүен раслагандай, борылыш артыннан поездның башта кычкыртканы, уфылдавы ишетелде. Ниһаять, көткән күңелләрне шомландырып та, өметләндереп тә үзе дә килеп чыкты. Менә хәзер поезд туктар, әнисе төшәр һәм алар өчәүләп өйгә кайтып китәрләр сыман иде...

Өметләр тепловоздан калган төтен кебек тараддылар. Поезд туктап тормады, килгән тизлектә ыжгырып узып та китте. Вагон тәгәрмәчләре, «без киттек, без киттек, без киттек» дип бара торгач, бөтенләй күренмәс булдылар. Поезддагылар яр башында утырган Нәсим белән әбисенә күз дә салмадылар диярлек, бары тик чәченә ак бантик таккан, Нәсимнең үзе кебек кечкенә кыз гына аларга карап кул болгап узды...

Кайтканда алар сөйләшмәделәр. Өмете алданудан Нәсимнең күз читләрендә тәгәрәп төшәргә өлгермәгән ике энҗе бөртеге ялтырый иде.

Поезд туктамыйча узды дип кенә сабый күңелендә өмет сүнәме соң? Инде юлны бер белгәч, әбисен борчып тормый, поезд карарга күршедәге иптәш малае Хәким белән бергә йөри башладылар. Хәким аның чын дусты. Яраткан экскаваторын Нәсим юкка гына бүләк итмәде лә аңа! Бу бүләккә Хәкимнең ничек сөенгәнен күргәч үзе дә дустыннан ким шатланмады.

Беркөнне кичкә каршы, алар тимер юл буеннан кайтып килгәндә, Нәсимнәрнең капка төбендә ике кешенең басып торганын күрделәр. Чү! Әтисе белән әнисе түгелме соң? Әнисе икәнлегенә ышану белән Нәсим, дөньясын онытып,

шунда йөгерде. Ул әнисен шулкадәр сагынган, шулкадәр сагынган иде ки, зурларның кулларын бутый-бутый нәрсә турындадыр кызып сөйләшүләрен баштарак игътибарга да алмады. Якынайгач кына ярсулы сөйләшүне ишетте.

— Мин — аның анасы!

— Анасы икәненне элегрәк оныткан идеңмени? Бар, әнә үзең илтеп бирергә кушкан балалар йортыннан эзләп ал улыңны.— Әтисенең гадәттәге тыныч тавышы ачулы яңгырый иде.

Әнисе ярсып кычкырды:

— Кайсысына бирдең? Әйт! Суд аны барыбер миндә калдырачак. Бездә ана белән баланы аера торган закон юк!

Ишетсә дә, бу кычкыруның мәгънәсен аңламаган Нәсим йөгереп килеп җитте дә:

— Әни! — дип аның иңенә сарылды.— Ә мин беләм: син поезд белән кайттың! — дип мактанды ул.— Нишләп мин сине күрмәдем? Без Хәким белән икебез көн саен поезд карарга йөрдек, сине көттек.

Көтелмәгән бу хәлдән Сәлах та, Суфия да югалып калдылар. Аннан соң Суфия аңына килде һәм улын кочагына кысып коча, үбә башлады. .

Суфия Нәсимне җиргә төшерде һәм ни әйтергә белми сүзсез калды. Бераздан Сәлах улына дәште:

— Улым, әниең сине бөтенләйгә алып китәргә кайткан, барасыңмы?

Нәсим, сүзнең ни турында барганын аңламаса да, дерт итеп китте һәм кулларын әнисенең күлмәк итәгеннән ычкындырды:

— Кая алып китә? Кая барабыз? Әти, син дә барасыңмы? Әби дә барамы? — Ул, җавап эзләп, әле әтисенә, әле әнисенә карады.

— Юк, синең үзеңне генә алып китәм, ди әниең...

Ишегалдыннан әбисенең тавышы ишетелде:

— Нәсим, улым, поездны күрдеңме? Кил, әйдә, карының ачкандыр, ятимкәем минем! Тамак ялгап чык.

Нәсим әбисен ишетмәде дә кебек:

— Әнием, ник алай, ник бергә китмибез? Әбием ялгыз

каламы? Ә нигә китәбез? Үзебездә генә торыйк...— Нәсимнең тавышында аптырау да, ялвару да бар иде.

Суфия яшькә манчылган күзләрен улыннан читкә алырга мәҗбүр булды, ләкин җавап бирерлек хәлдә түгел иде. Бу минутта гүя аңа улы түгел, вөҗданы карап тора иде. Вөҗданыннан качып та, аны алдап та булмый шул.

Ә Нәсим, энисеннән күзен дә алмый, җавап көтте.

Шулвакыт ерак чокырдан уфылдый-уфылдый чираттагы поезд узып киткәне ишетелде. Аның тавышына зурлар, ихтимал, игътибар да итмәгәндер, бары тик Нәсим генә, үзе дә сизмәстән, энисенең итәгенә кабат чытырдатып ябышты.

ЧАЛБАР

Беренче укытучым Рәбига апа
Нәдершинага багышлыйм.

Каядыр шалтыратырга дип, Сабиров телефон номерын җыя башлаган иде.

— Керергә ярыймы? — дигән тавыш ишетеп, күтәрелеп карады. Карамаса да тавышның хуҗасын таныр иде Сабиров. Әнә ич тагын, түргә узарга кыймыйча, ишектән керү белән туктап калды. Әгәр дә хәзер янына барып җитәкләп алып килмәсәң, белеп тора: керүче баскан урыныннан кузгалырга базмаячак.

Сөйләшүен тиз-тиз төгәлләп, Рахман трубкасын куйды һәм җәһәт кенә керүченең каршысына атлады:

— Рөхсәт сорап тормагыз, туп-туры узыгыз дип ничә тапкыр үтендем, Рәхилә апа! — Кабинет хуҗасы кунагын йомшак кәнәфигә утыртты.

— И-и, кыенсынмыйча, Рахман Галимович! Сез бит хәзер зур кеше, колхоз председателе. Яныгызга керүченең исәбе-хисабы юктыр. Карт башым белән мин дә йөрим шунда, эш кешесен борчып.

Үзен хөрмәтләп әйтелгән сүзләрдән председатель чәч төпләренә тикле кызаруын, йөрәгеннән тәмле-татлы дулкын узуын, уч төпләренең чемердәп китүен тойды.

— Рәхилә апа, мине оялтмагыз. Кем булсам да, мин барыбер сезнең укучыгыз гына. Йөзләгән шәкертегезнең берсе. Сез — минем остазым. Укытучыдан да олырак кем бар дөньяда? Райком секретаремы? Министрмы? Аларны да кемдер хәреф танырга өйрәткән.

— Зурлавыгыз өчен рәхмәт, Рахман Галимович. Безнең инде укытучылыгыбыз да шуның кадәр генә булгандыр. Тырышып-тырмашып ирешелгән ун класс белем белән башыгызны катырганбыздыр. Укучылар кайвакыт шундый сораулар биреп куялар иде,— Рәхилә апаның тоныклана төшкән күзләрендә укыткан чакларындагы төсле нур ялтырап китте, җыерчыклы бит тиреләре, киерелеп, тигезләнеп калды,— ни дип җавап бирергә дә белми аптырый идем. Хәтерегездәме, Рахман Галимович, өченче класста укыганда миннән тавык алдан барлыкка килгәнме, әллә йомыркамы дип сораган идегез?

— Исемдә, исемдә, Рәхилә апа.— Укытучысы әйткәч, Сабировның чынлап та хәтеренә төште һәм ул елмаеп куйды.

— Шул чакта ул сорауга җавап биралмавыма кыенсынуымны белсәгез! Соңыннан, тәнәфескә чыккач, мәрхүм директор Гыймадиев абыеңнан да сорап караган идем. Ул: «Юк белән баш катырма, сеңелем. РОНОга чакыралар, миңа ат җигә торсаң яхшырак булыр»,— дип кырт кисте. Башкаларның да белем запасы минекеннән әллә ни артмагандыр. Күбесенең ун класс, кайберсендә ул да юк иде бит. Ярый әле син кабатлап төпченмәдең, тора-бара үзем дә оныткынмын. Оят булса да әйтим, мин аны хәзер дә белмим икән.

Сабиров көлеп җибәрде:

— Юкка читенсенәсез, Рәхилә апа. Бу сорауга сезнең белән мин генә түгел, академикларның да җавап таба алганнары юк. Сәламәтлек якларыгыз ничек соң, Рәхилә апа? — Беренче укытучысына Рахманның кинәт мәктәптә укыган еллардагы сыман гади һәм дустанә төстә «апа» дип кенә дәшәсе килеп китте. Һәм ул соравын яңадан кабатлады: — Хәлләрегез ничек, апа?

— Зарланырлык түгел, Рахман Галимович.

— Сез миңа, апа, Рахман гына диегез әле. Аның Галимовичы ник кирәк?

— Сез, Рахман Галимович, җиде авылны берләштергән хуҗалык җитәкчесе. Ә без ике адымда биш сөртенә торган үлалмаган бер карчык. Алай килешер микән?

— Килешер, килешер, апа. Безнең татарда фәләнович, фәләновна димәгәннәр бит элек. Апа, абый, үскәнем, апаем, энем, сеңелем дигәннәр. Әтиегезнең Солтан исемле икәнен белсәк тә, бер укучының да мәктәптә сезгә Рәхилә Солтановна дип дәшкәнен хәтерләмим. Фәләнович диюләр соңгы елларда гына телгә кереп бара. Башкалардан үзләштерәбез.

— Рахман...— карт укытучы өйрәнгән гадәте буенча «Галимович» дип өстәмәкче иде дә, укучысының теләген искә төшереп туктап калды.— Рахман гына диим инде алайса.

— Күптән шулай кирәк иде, апа.

— Рахман, монда керүемнең сәбәбен белмисең бит әле син. Безнең күршедәге Зәлифә әбиеңне, теге Садыйк бабаң карчыгы Зәлифәне хәтерлисеңме?

Сабиров җитдиләнде. Рәхилә апасының мөһим сүзен тыңларга хәзерләнде.

— Зәлифә әбиең авырып урын өстенә егылды әле.

— Шулаймыни, нәрсә булган?

— И-и, Рахман, картларныкын әйтмә инде: кул сызлавы басылса, башы авырта, башы сихәтләнсә, бил кузгала дигәндәй, картлыкныкы. Тик синең яныңа килүем аның чирен сөйләр өчен түгел иде. Өенең рәте калмады аның. Төртсәң, бүрәнәсенә бармак кереп китәргә тора.

— Менә анысын белми идем.

— Гаҗәп түгел, Рахман. Безнең тыкрык аулакта, ул тирәдә сез сирәк күренәсез. Барысына да кайдан өлгермәк кирәк,— диде Рәхилә, элеккеге укучысын акларга тырышкандай.— Зәлифәгә өен сипләтүдә ярдәм итмәссезме дип килүем. Шушы колхозда эшләп картайган кеше бит. Гомере дә, бәлки, күп калмагандыр, тик тере кешене күрәләтә җимерек өйдә яшәтәсеңмени?

— Тыныч булыгыз, апа. Белмәү — безнең гаеп, шуңа

күрә акланып та тормыйм. Зәлифәттәй кебек кешеләргә өен сипләп бирү генә түгел, һәрберсенә алтын һәйкәл куярлык. Мин аның әнкәйләр белән Бөгелмәдән сугыш чорында чәчүлек орлык ташып йөргән чакларын да бераз хәтерлим. Кар ерып, су ерып...

— Аларны онытмавың өчен рәхмәт. Кайберәүләр, түрә булуга, үткәннәрен дә, элекке дусларын да оныталар.

— Минемчә, үткәнен оныткан — киләчәгенә балта чапкан, Рәхилә апа.— Ул, хатирәләр дөньясына кучеп, шактый дәшми торды.— Онытырлык булдымыни ул безнең балачак...— Рахманның сүзен бүлдереп, телефон шалтырады.

— Алло, «Йолдыз» колхозы, Сабиров тыңлый. Исәнмесез, Гәрәй ага. Әйбәт. Кичәге савым — ундүрт тә алты. Бер потка дисезме? Юк, җиткерә алмабыз. Тырышуын тырышабыз анысы. Сәгать бергәме? Яхшы, барырмын.

Райкомның беренче секретаре белән сөйләшкәнен аңлаган укытучысы китәргә җыенды.

— Ник ашыгасыз, апа? — дип туктатты аны Рахман.— Шәхси гозерегез юк идеме?

— Юк, рәхмәт! Сау бул!

Рахман Рәхилә апасын баскыч төбенә кадәр озата чыкты.

— Йомышыгыз төшкәндә тартынып тормагыз, апа,— диде ул соңгы сүзе итеп.

Шул чыгуыннан Рахман кабинетына кереп тормады. Райкомга дип кузгалганчы әле дүрт сәгать вакыт бар иде. Печәнчеләр тирәсеннән урарга да, төзүчеләр янына сугылырга да ул әле өлгерәчәк.

Беренче секретарьны Рахман начар кеше димәс иде. Игътибарлылык, итагатьлелек дигәндә аңарда биш кешегә җитәрлек. Кайвакыт көтмәгәндә-уйламаганда авылларындагы берәр күзгә-башка сирәк чалынучы карт-коры турында сорап, колхоз председательләрен, партоешма секретарьларын аптырашта калдыра иде. Механизаторлар, терлекчеләрне әйткән дә юк, кичә генә эшли башлаганнарына тикле белә. Кайдан барысын да хәтерендә тота? Югыйсә район бит кечкенәләрдән түгел.

Менә шул җитәкче Гәрәй аганың, җәйгә чыкса, бар белгәне һәр сыердан бер пот сөт «даулау» иде.

«Бик яхшы эшлибез», дип, Рахман да күкрәк сугарга җыенмый. Тик колхозның көтүчеләре белән барлык савымчылары тиреләрен салсалар да, сыерларны райком секретаре килеп хәтта үзе сауса да, быел да, алдагы елда да бер пот сөт аларга тәтемәячәк. Нәселле сыерлар кирәк, нәселле сыерлар! Ә алар юлда аунап ятмыйлар.

«Ике сүзнең берендә сөт-сөт дия-дия, ит белән майны талонлап таратуга барып җиттек. Акрынлап хакын күтәрә барабыз». Исенә шул төштеме, Рахманның кояшлы күңел күген кара болыт каплый да куя. Әйтерсең илдәге барлык чатаклыкларга ул гына гаепле.

Колхоздан читкә китмәгәндә Рахман шоферлык вазифасын да үти. Һәр карыш җиренә, чокырына, ташына кадәр таныш шушы басуларда ялгызы калырга ярата ул. Янәшәсендә кеше бар чагында, нигәдер, үзе генә вакытта кичергән хисләр уянмый. Сүз әйтүче, эндәшүче дә юк, тик нидер комачаулый иде.

Күч кулы таулары... Язларын һәркемгә җитәрлек әчкелтем юа үсә анда. Кәҗә кебек тау кырласыннан сикерә-сикерә учма-учма юа җыеп кайткан бала чак көннәрен ничек онытсын Рахман? Онытып та булыр иде, әгәр тормышыңнан бала чагыңны тулысынча сызып ташлый алсаң.

Инеш буендагы тигезлектә исә ике-өч гектарга җәелгән шомыртлык. Язларын шомырт агачлары ап-ак булып чәчәк ата, җәйге карабодай кырын искә төшереп тора. Чәчәкләренең, исерткеч хуш исе әллә ничә чакрымга тарала. Көзгә кадәр монда якын-тирә авыл халкы элек-электән шомыртыннан, куак төпләрендәге үлән арасына качып үскән җиләгеннән, балтырган, кузгалак, кукы шикелле җаны теләгән нәрсәләрдән авыз итә килгән. Көзгә таба күзне чагылдырырлык баланнар үзләрен күргәзмәгә куялар...

Печәнчеләр янында озак тормады Рахман. Бригадир Шаһидулла абзый анда, ә ул бар җирдә тәртип тә булачак. Председательнең күңелендә канәгатьләнүгә якын хис

уйнды, инде кайтып капкаларга да беренче секретарь янына кузгалырга кирәк иде.

Иртән укытучы Рәхилә апасы белән күрешү аны бөтенләй эллә нишләтте: хатирә артыннан хатирә калкып, уйларын кая гына алып китми. Менә хәзер дә, машинасы ындыр артындагы асфальт юлга чыгуга, бала чагы, бер мең тугыз йөз кырык сигезенче ел исенә төште.

Ул өченче класста укый иде. Әтиләре сугыштан кайтмады дип тормадылар, өйдә ике баласын калдыртып, әниләрен февраль азагында Ширәмәткә ай ярымга урман кисәргә җибәрделәр. Өйдәге мал-туарга, бар хуҗалыкка баш булып Рахманның бишенчедә укый торган абыйсы Фиргать калды. Күрше Гандәлифә әби иртә-кич сыерларын савып, сөтле умач пешереп бирә һәм мичкә ягып чыгып китә. Калган эшләрне ике туган тарткалаша-тарткалаша булса да үзләре ерып чыгалар иде.

Әтисезлек кыен иде, ә менә әнисез яшәү бигрәк тә авыр икән.

Урамда гөрләвекләр аккан, инештә ташу ташыган чак иде. Дәрестән, өй эшеннән бушауга малайлар су буеннан кайтып кермиләр. Анда кызык: зур-зур бозлар агып киләләр дә Стәрле аша салынган күпернең субайларына китереп бәрәләр. Аеруча калын бозлар (аларын буа бозлары дип йөртәләр) килеп бәрелгән чакта күпер генә түгел, ярлар да ыңгырашып куялар сыман. Елга буенда яши торган Заһит әйтә:

— Боз белән боз бәрелгәндә очкын чыга, берсе минем бүреккә төшеп йонын көйдерде,— ди. Аның сүзенә ышанган вак ыбыр-чыбыр, күзләре авыртканчы, бәрелешкән бозларга карап торалар. Тик берсенең-бер күзенә очкын күренми, бары тик ике йодрыгын авызына берьюлы сыйдыра ала торган (авылда башка бер малай да алай булдыра алмый) Путхалим Илгизәр генә, күзен дә йоммый алдый:

— Әйе шул, әйе, үзем күрдем!

Ә Рахманны алдый алмассың: Заһитның бүрегенә салам яндырып уйнаганда төшкән иде бит ул очкын, боз бәрелешкәндә түгел.

Малайларның иң көткәне — бозларның күперне агызып алып китүе. Бу көн укучылар тормышында иң бәхетле көн. Чөнки, күпер китсә, Аръяклар мәктәпкә чыга алмыйлар һәм укучылар язгы каникулга туктый. Ташулар тынып, яңа күпер яки вакытлы басма ише нәрсә салынганчы алар ял итәләр. Быел исә, үч иткән шикелле, күпер китми дә китми. Болайга калса, апрельнең уннарыунбишләре җитми торып каникуллар тәтемәс, дип сөйләнәләр малайларның белдеклерәкләре.

Табигатьнең ала-кола чагы: йорт, койма почмакларында, чокырлы урыннарда кояшның күзгә күренмәс энәләре тишкәләп бетергән кар ята; кояш мулрак төшкән калкурак җирләрдә, тау буйларында инде яшь үлән мыек җибәрергә үк өлгергән иде. Малайларга шул да җитә: алар барлы-юклы аяк киемнәрен салып ыргыталар һәм, иркенгә чыккан яшь бозау шикелле, яланаяк уйный-йөгерә яр буе чирәмендә кайнашалар иде.

Ул көнне язмышның Рахманнан көлүдән башка эше табылмады, ахры. Чирәмдә уйнап туеп малайлар белән өйгә кайтулары иде. Күпергә кермичә, субайлар алдына буалган бозлар аша чыгарга уйладылар. Боздан-бозга сикергән чакта Рахманның сул аягының галошы инешкә төшеп китте. Бөтерелеп аккан суда, сау бул дигәндәй, галош бер генә күренеп алды да күздән югалды. Әле өр-яңа, көз көне генә алынган иде ул. Суга аккан галош кире калкып чыкмады, бозлар арасына кереп китте. Болай булса, иртәгә мәктәпкә я сыңар галош белән титаклап, я яланаяк барырга туры киләчәк иде.

Рахман, яр читендә шуны уйлап, уң аягында сикеренгәләп торган арада, таеп, чалбарының төбе белән лайга утырды. Хәерчегә җил каршы, диләр. Шул буладыр инде ул: чалбары пычрак, сул аягында ертык оекбашы гына, ул да лайга баткан иде. Мондый хәлдә эчең бушаганчы еламый нишлисең?

Ә өйгә кайткач, әле абыйсы, галош белән чалбар өчен ипи шүрлегенә кундырып, «акыл өйрәтә» башлады. Хәер, анысына гына Рахман түзде, гарьләнмәде дә, еламады да. Нинди абый ди ул энесен дә тукмамагач! Аның каравы,

башка малайлардан тидертми ул. Абыйсының үзен яратканын белмимени Рахман! Менә хәзер дә Фиргать аны кочаклап алды һәм, энесен аптыраштa калдырып, көтмәгәндә елап та җибәрде:

— Ичмасам, әнкәй дә кайтмый, әйеме...

Рахман башта абыйсына сәерсенеп карады: ничек инде аның абыйсы кадәр абыйсы елап торсын? Әнисеннән кала Рахман өчен Фиргатьтән дә дәрәҗәлерәк берәү дә юк иде. Ә ул әнә, борынын мышык-мышык тартып, елап маташа. Абыйсына ияреп Рахман да елап җибәрде. Әнисен әллә ул сагынмадымы?! Кайчан кайтыр да: «Улым, сабагыңа соңга кала күрмә, тор инде»,— дип чәченнән сыйпап уятыр.

Тынычлана төшкәч, учак ягып казанда су җылыттылар, икәүләп пычрак чалбарны юып, мич башыннан асылындырып куйдылар. Бу төнне Рахманга юрган астында анадан тума хәлендә йокларга туры килде. Чөнки аның эчке киеме дә, тышкысы да юып элгән шул бер чалбар иде.

Иртән торсалар — үкенечтән һәм аптыраудан ни эшләргә белмәделәр. Алар тәмле төш күреп йоклаганда кашка бозау чалбарны сөйрәп төшергән дә чәйни-чәйни мунчала ясаган иде.

— Ах, мур кыргыры нәрсә! — дип каһәрләде аны Рахман. Мич авызында яткан утын агачы белән бозауның сыртына берне сугарга уйлаган иде, соңыннан кызганды тагын.

Чалбарсыз укырга бару турында уйлыйсы да юк. Нишләдең син, бозау, ә? Ник мәсхәрә иттең Рахманны? Хәзер кайдан алсын ул чалбар? Ничек күренсен ул Рәхилә апасының күзенә? Дәрескә йөрмәгәч, әлбәттә, аны классында калдырачаклар. Укыр-укымас йөрүче кайберәүләр шикелле өченче класста тагын бер ел утырырга туры килерме?

Абыйсы мәктәпкә дип чыгып киткәннән соң да Рахман бик озак әрнеп, кашка бозауны каһәрләп ятты. Хәзер аның классташлары кызып-кызып мәсьәлә чишәләрдер, яисә шигырь, әкият укыйлардыр. Ә ул суык өйдә берьялгызы, үз шәрәлегеннән үзе оялып, әнисенең иске бишмәтен киеп утырды. Мунчада да шәрә каласың, тик мунча мунча инде ул, өй түгел.

Бер вакыт ыңгырашып, шыңгырдап аларның капкасы ачылган тавыш ишетелде. Абыйсы мәктәптән кайтадыр дип уйлады Рахман. Ләкин аяк тавышлары өйалдында туктап калды. Чү, кем әле ул ишек шакыган булып маташа, гомердә кыланмаганны?

Ишекне җиңелчә генә шакып Рәхилә апасы килеп керде.

— Исәнмесез! — дип сәлам бирде ул, класс тулы укучылар янына кергән сыман.

— Исәнмесез, апа! — Укытучысы килүгә куанса да, каушавыннан, оялуыннан Рахман шундук юрган астына чума төште.

Рәхилә апасы түргә узды һәм салкынча, йомшак кулын аның маңгаена куйды.

— Авырып киттеңме, Рахман?

Укытучы апасының кулын тою шундый рәхәт, гүя йөз илле чакрым ераклыктагы Ширәмәтнең карурманыннан әнисе кайткан да хәлен сорый диярсең. Рахманның күңеле тулды, ихтыярсыздан күзен яшь элпәсе каплады.

— Юк, авырмыйм, апа,— диде.

— Алайса нәрсә булды, нигә мәктәпкә бармадың?

Дөресен әйтергәме, әйтмәскәме? Ничек инде укытучыга ялган сөйлисең? Рәхилә апасы бит ул!

— Апа, кашка бозау минем... чалбарны чәйнәгән. Кибәргә элгән идек...

— Әниегез кайчан кайта соң?

— Тагын ун көннәрдән ди Гандәлифә әби.

Укытучысы бүтән берни дә сорамады.

— Ярар,— диде ул чыгып киткәндә,— дәресләреңнән артта калмаска тырыш. Фиргать абыең артыннан өйгә эш биреп җибәрермен.

...Икенче көнне иртән алар әле торып өлгермәгәннәр иде, ишек шакыдылар. Кем икән?

— Абый, әни кайткандыр,— диде Рахман терсәге белән абыйсына төртеп.

Бишмәтен бөркәнеп, Фиргать өйалдына чыгып китте.

— Кем анда? — дип сорады ул, зурларга охшатырга тырышып.

— Фиргать акыллым, ач әле, Рәхилә апагыз бу.

Шуннан соң гына Фиргать тышкы ишекнең бигеп ычкындырды. Рәхилә апалары түргә узды һәм Рахманга бер төргәк сузды.

— Рахман, иркәм, тор әле, менә сиңа мәктәптән чалбар биргәннәр иде. Камилгә кигертеп карадым, таман сыман иде, сиңа ничек микән? Сез бит икегез бер чама, ярарга тиеш,— диде.

Юрган астыннан кулын чыгарып, Рахман төргәкне сүтте. Өр-яңа чалбар! Сәдәфләренә чаклы яңа, ялтырап торалар иде.

— Киеп тә күрсәт инде, күңелем булсын,— диде Рәхилә апасы.

— Мин бит, ни бит, апа...

Ни икәнен әйтмәсә дә, укытучысы хәлне аңлады.

— Мин чыгып торам, кигәч эндәшерсез.

Рахман, сикереп торып, чалбарын кияргә кереште. Тизрәк тәнендә күрәсе килүдән ашыкты, кабаланды. Шул ашыгуы аны харап та итә язды. Бер балагын кигән иде, икенчесен кигәндә, чак егылып китмәде.

— Күзең чыктымы әллә? Ике аягыңны бер балакка тыкмасаң! — диде Фиргать, ачуланып.

Чалбарны киде Рахман, тап-таман. Куанычыннан ишекне ачып, укытучысына дәште:

— Кидем, апа, керегез!

Рәхилә апалары Рахманны әйләндерә-әйләндерә күздән кичерде. Чалбарның җөеннән чыгып торган бер җеп күреп, аны теше белән кертләтеп өзеп алды. Аннан саубуллашты:

— Ярамаса ни эшләрбез, дип бик курыккан идем, таман бу. Җылы тәнеңдә тузарга язсын. Сез, балалар, дәресегезгә соңга кала күрмәгез.

Рахманның гомерендә дә мондый чалбарны кигәне булмады. Шуңа күрә ул, мәктәпкә барып җиткәнче, аны пычратмаска тырышып, гел чалбарына карап атлады. Их, шунда берәрсе күрсен, мактасын иде дә яңа чалбарны, әйтсен, шаяртсын: «Ай-яй ла, Рахманның яңа чалбары! Төнлә кайларга куеп йоклыйсың?» — дисен дип хыяллан-

ды ул. Һәм, чыннан да, беренче тәнәфес вакытында Айсылу дигән бер изгесе аның үзенә генә ишетелерлек итеп:

— Яңа чалбарың котлы булсын, Рахман! — дип әйтеп китте...

Вакыт узды. Ул чалбар гына түгел, тагын әллә никадәр киемнәр тузды. Аннан соң да Рахман ничәмә-ничә укытучыда укыды. Чалбар белән булган бу вакыйга күптән инде онытылган да иде. Рәхилә апасының бүген килеп, сөйләшеп утыруы аны Рахман күңелендә яңартты. Әнә бит, чалбар вакыйгасына ияреп иптәшләре дә, классташ кызы Айсылу да күз алдына килделәр.

Истәлекләрне бүлдереп машина район үзәгенә килеп керде. Шоферын гаҗәпкә калдырып, Рахман үзалдына сөйләнеп куйды:

— Олыларга ярдәмне иртәгәгә калдырмаска кирәк...

СЕР

Зираттагы бердәнбер каенның ботагы җилгә түзмәде, сынып, кабер казучылар янына ук килеп төште. Снаряд ярылдымыни, кешеләрнең җилдә киселеп, суыкта күшегеп беткән иреннәре сискәнеп, дерелдәп алдылар.

Йөрәкләргә шом салып оркестр «Матәм маршы»н уйнап җибәрде. Аның күңелләрне актарып чыгара торган авазларыннан кайгы кулагәсе яткан башлар гына түгел, каенның ботаклары да түбән иелде сыман.

Бер-бер артлы хушлашу сүзләре сөйләнде. Хатын-кызларның үксүе көчәйде. Башка вакытта, электән килгән гадәт буенча, алар зиратка кереп тормаслар да иде, ләкин Сания күмелә бит. Хатын-кызларның, укучы балаларның менә елыйм, менә елыйм дигән иреннәре чак тыелып тора. Әйе, укучылар өчен дә, укытучылар өчен дә, авыл халкы өчен дә авыр югалту булды бу хәл — укытучы Сания Гатинаның үлеме.

Сания апаның ире Вильдан табут өстенә бер уч туфрак салды. Оркестрның тегермән ташы зурлыгындагы барабанына китереп суктылар. Зур һәм кечкенә торбалардан

чыккан тавыш үксегән халыкның авазы белән кушылып көзге җил белән еракка-еракка таралды. Күңел белән бергә җил дә елый сыман иде.

Күмү тәмамлангач, кешеләр тавыш-тынсыз гына өйләренә таралыштылар. Зиратның йөзләгән кабере арасында тагын бер хәтер ташы өстәлде, тимер чардуган артты. Аннары, кешеләрнең таралуын гына көткән төсле, салкын яңгыр яварга кереште.

Караңгылык, колачын җәеп, чокыр һәм уйсу җирләрне кочагына ала барды. Ниһаять, аның кодрәте каралтыкура, йорт эше корылмаларга, мәгърур тауларга да житте. Җиһанны караңгылык, караңгылык белән тынлык басты. Еракта, аръяк басуда туңга сөрүче тракторлар гөрелтесе генә, су астыннан чыккан тавыш сыман, тоныкланып ишетелә. Йортларда утлар, күкнең ара-тирә аязып киткәләгән җирләрендә йолдызлар кабынгалый иде.

Шул вакыт караңгылыктан чак кына аерылып торган бер шәүлә, бакча буендагы киртәләргә ышыкланып, зиратка якынлашты. Ул бик сак атлый. Атлаган саен артына, якягына борылып карый-карый бара торгач Сания Гатина кабере янына килеп житте һәм туктап калды. Ни эшләргә белмәгән кеше кебек, яңа чардуганга сөялеп шактый басып торды һәм, кабер өстенә кинәт капланып, куллары белән яңгырда изрәп беткән балчыкны тырмарга, капшарга кереште.

Бу кеше — сигезенче класс укучысы Әнәс Галимшин иде. Җирдә озак ятты ул. Җилнең басылганын да, үзенең туңганлыгын да сизмәде.

Бирегә икенче, өченче, дүртенче көнне дә караңгы төшкәч килде Әнәс. Килгән саен ямь-яшел ылыслар китерде, чөнки чәчәкләр чоры күптән үткән иде. Ылысларны кабер ташына кадерләп сөяп куя һәм, шактый басып торганнан соң, кайтып китә иде.

Авыл халкы гаҗәпләнмәскә өйрәнгән инде, яшел ылысларны куючының кем икәнлеге белән артык кызыксынмадылар диярлек. Кешеләрнең күңеленә аеруча бер якынлык белән үтеп керә белгән бу укытучыны хөрмәтләргә теләүчеләр аз булырмыни?

Беренче яртыеллыкта ике фәннән өлгермәгән Әнәснең өченче чиректә, укытучыларны гаҗәпкә калдырып, тырышлыгы сизелерлек яхшырды. Бигрәк тә элек Сания апасы укыткан татар теле һәм әдәбиятыннан өченче чиректә Әнәс гел дүртле билгесе алды. Моны берәү дә көтмәгән иде. Кинәт үзгәрешнең сәбәбен белергә тырышсалар да, гоманлаудан ары китә алмадылар. Элекке «җан дуслары» белән дә сирәк аралаша башлаган Әнәсне аңлау кыен иде.

Кышның салкынына, карлы сукмагына игътибар итмәстән ул зиратка йөрде. Зиратка барган саен Әнәснең күз алдына теге көн — Сания апасының авырып аяктан егылган көне килеп баса һәм җаны бәргәләнүдән үзенә урын табалмыйча кызарып, уч төпләренә тикле тирләп чыга. Ә бер салкын көнне Әнәс нык туңып, бөтенләй өшәнеп кайткан иде, шуннан авырып китте. Үпкәсе ялкынсынуы ачыклангач, малайны больницага салырга туры килде.

Әнәс терелеп чыкканда кояш турырак караган урыннарда беренче умырзаялар баш калкыткан иде инде. Малай шул ук көнне бер бәйләм чәчәк җыеп, авыл тынгач, аны Сания апасының каберенә илтеп салды.

...Ул көнне Сания апаларының сигезенче класста ике дәресе бар иде. Тел дәресе тыныч узды. Диктант яздылар. Җөмләләр катлаулы, аерымланган кисәкләр, иярчен җөмләләр игътибар биреп язуны сорый, шуңа күрә класста шылт иткән тавыш та юк. Сания апалары диктант язуга керешкәнче үк кисәтеп әйтеп куйган иде:

— Укучылар, алдагы дәресләрдә узганнарны хәтерегезгә төшерегез. Бигрәк тә аерымланган аныклагычларны аерымланмаган аныклагычлар белән бутамагыз, тыныш билгеләрен дөрес куюга нык игътибар итегез,— диде.

Сания апаларының салмак һәм тантаналы тавышы һәр хатаны кисәтә кебек. Шушы тынычлыкта бер Әнәс кенә тик утыра алмый: башын әле уңга, әле сулга бора. Ул үрелгән саен елак тавыш чыгарып партасы шыгырдап куя иде. Борылмас иде, күчерәсе бар. Күчермәс иде, аныклагычларда әлефне таяк дип тә белми ул.

Аннары әдәбият дәресе булды. Аңа Әнәс соңга калып керде. Утыргач, гәүдәсен төрлечә бөгәрләп, кыланып, артына карап авызын ерды: янәсе, күрәсезме, мин кем?

Илһамия атлы кыз парталар алдына чыгып сөйли генә башлаган иде, Әнәс укытучыга кычкырды:

— Апа, кесәдән ручканы алып килим әле!

Билгеле, җавап бирүче укучы туктап калды. Укытучы, дәвам итәргә кушып, аңа ым какты. Илһамия кабат сөйли башлауга, Әнәс аны янә бүлдерде:

— Ручка кирәк иде, алыйм әле? — Үзе җавап көтеп тормастан урыныннан кузгалды.

— Галимшин, утыр урыныңа! — Сания апасы тавышын күтәрмәде, Илһамия, тырышып-тырышып, өченче тапкырына сөйли башлады.

Әнәс урынына утырып як-ягына каранды, үзен хуплаучыны күрмәсә дә канәгать кыяфәттә авызын ерды. Күрмисезмени, нинди батыр бит ул!

Сания апалары исә Илһамияне утыртты да:

— Хәзер Галимшин дәвам итә,— диде.

Әнәс урыныннан торып мәшәкатьләнмәде:

— Белмим,— дип җавап бирде.

— Галимшин, укытучы белән ничек сөйләшәләр?

Торып басарга мәҗбүр булган Әнәс авыз эченнән ботка пешерде:

— Белмим дидем бит инде...

— Утыр.

Кул күтәреп, теманы Шакир дәвам итте. Әнәс, туктарга кушып, парта астыннан аңа йодрык күрсәтеп карады, ләкин туктатырсың Шакирны алай гына. Бик курка ди ул синең янавыңнан. Әнәс исә мыгырданырга тотынды: «Һы, үзе ручканы алып килдертмәде дә... Һы, моны мин дә сөйли белә идем. Һы... Ручкасыз ничек утырыйм ди мин дәрестә...»

Сания апалары тагын берничә мәртәбә кисәтү ясап карады, әмма кисәткән саен Галимшин узына гына барды. Чөнки классташларының игътибары бары тик аңарда гына дип уйлый иде.

Менә шунда Сания апаларының түземе җитмәде:

— Бар, югал күземнән! — дип кычкырды ул үзенә дә ят тавыш белән.

Әнәс Галимшинның мондый кычкыруларны гына күргәне бар иде сигезенче ел уку дәвамында.

— Нигә куасың? Личный классыңмы әллә? Укытучы булдым дигәч тә...

Укытучылары элеккедән дә яманрак тавыш белән тагын кабатлады:

— Вон! Чыгып кит!

Шул минутта укытучыга әллә нәрсә булды. Башы әйләнеп китте, аяклары сыгылып төштеләр. Ул, хәлсезләнеп, өстәл читенә тотынды һәм урындыкка утырып өлгерде.

Бәхеткә каршы, тиздән кыңгырау шалтырады. Ләкин Саниягә бик озак тоелды бу вакыт. Башы уйлаудан туктады. Укытучылар бүлмәсенең ишегеннән керүгә, ул идәнгә егылды.

Аңына килгәндә ул өйләрендә ята иде. Ашыгыч ярдәм машинасы белән район үзәгеннән килгән врач тиешле уколларны кадаганнан соң борчылмаска, өйдә тыныч кына ятарга кушып кайтып китте. Тәмам терелеп җитми торып эш турында уйларга да ярамый иде. Тик андый кешеме соң Сания Закировна! Өйдәгеләрнең каршы торуына карамастан, ул урын өстендә ике генә көн ятты да укытырга китте. Башкалар алдында сер бирмичә атнадан артык эшләп йөргәч, ул кабат аяктан егылды. Бу юлы колхоз автобусы белән туп-туры больницага алып киттеләр үзен. Ләкин соң, эш узган иде инде: бу юлы аны тылсымлы уколлар да коткарып кала алмады: илле яшен дә тутырмаган укытучының йөрәге тибүдән туктады.

МИНЕМ ТУГАН КӨНЕМ

Бүген кызыбызга дүрт яшь тула. Әнисе белән без иртәдән алып кухняда кайнашабыз. Ул пешерә, ә мин өстәлгә тезә торам. Кечкә таба кунаклар — кызымның иптәшләре киләчәк.

Башка елларны: «Кечкенә әле, үсә төшкәч үткәрербез

туган көнен»,— дип йөргән идек. Беркөн үзен Гөлнараларга чакырдылар. Аннан чыккач:

— Без Гөлнараларга кердек. Аның туган көне булды. Эти-и,— диде ул бераз суза төшеп,— минекен кайчан үткәрәбез? Үткәрик әле, эти, ә!

Аның бу соравы минем күңелдә моңа кадәр онытылып торган хатирәләремне уятты.

Туган көн. Безнең балачак туры килгән сугыштан соңгы еллардагы туган көн. Ул чакта кайчан туганыңны белергә дә этиләрнең вакыты юк иде. Шулай да дүртенче класста укып йөргәндә, каян исемә килгәндер:

— Туган көнне үткәрик әле? — дип, эти белән энинең теңкәсенә тиеп, туйдырып бетердем.

— Анысы ниткән сүз тагын? Авылда, илдә булмаганны! Нинди туган көн ул, кемдә күргәнең бар? — дип, баштарак эти кулын гына селтәде. Мин дә уйлана калдым: чыннан да, ничек үткәрәләр соң аны? Ант итеп әйтәм, иптәш малайларның берсе дә бу сорауга җавап бирә алмас иде. Чөнки безнең авылда андый гадәт юк. Авылда булмаса да илдә бар икән шул. Эти белән эни белмәгәч тә. Эти, баштарак белмим дип кул селтәсә дә, бик йөдәтә торгач, беркөнне:

— Кая, энкәсе, бир әле малайның метрикәсен, кайчан туган икән,— дип, энидән сандыгын ачтырып, таныклыкны алды. Без алты бала үсә идек. Эти һәрчак безгә:

— Абыең кышын, апаң көлтә бәйләгәндә, кече абыең ташу вакытында туды,— дип әйткәли иде.

Бу юлы ул сыңар колакчыны сынган күзлеген борын очында тотып миңа карады да гаҗәпсенеп куйды:

— Бәй, син печән өстендә тумадыңмыни? Монда декабрь язылган.

— Сөйләмә инде тузга язмаганны! Анысы Мансур бит. Әдип туган көнне утыз градуслы чатнама суык иде,— диде эни.

— Шулай икән шул,— ул энигә карап хәйләкәр елмайды.— Әллә, анасы, бишле»ләр дә алгалый, туган көнен үткәрәбезме соң шул малай актыгының?

Мин чыннан да төпчек бала. Ләкин эти төпчек булган

өчен генә әйтми малай актыгы дип. Кәефе яхшы вакытта абыйларга да шулай эндәшкәли.

Әни дә каршы килмәде.

— Ярар, үткәрербез алай булгач.

Шуның белән эш хәл ителгәнгә санап таныклыкларны сандыкка кире бикләп куйдылар.

Менә ул минем туган көн! Уянгач, башка көндәге кебек урында киерелеп ятмадым, абыйлардан алда сикереп торып киендем дә эти белән әни чәй эчеп утырган өстәл янына бардым. Туган көн булгач, өстәлгә тәмлерәк нәрсәләр дә куелгандыр дигән өмет бар иде. Кая ул! Гадәттәгечә җиз самавыр чыжылдап утыра, табында этиләр карабодай ипие белән чәй эчәләр. Хәтта кайбер көннәрдә өстәлдә күренгәләп ала торган шикәр дә юк. Ул карабодай ипиеннән болай да туйган инде. Кыш буе ашадык, төче үзе, баллы. Беренче ашап карауга тәмле тоелса да, тиз биздерә. Тансыкка дип, мәктәптә малайлар аны тәм-томга, бодай күмәченә алышкалыйлар. Тәмле дип ашыйлар. Ә мин, алышсыннар гына, арыш ипиенә дә риза.

Өметем алданса да, сиздермәдем. Югыйсә, бик шыңшый башласаң, этинең сугыштан алып кайткан каешы ничек чыжылдап сыртыңа төшкәнен сизми дә калырсың.

Бер кыерчык ипи белән ике чынаяк чәйне сүзсез генә капладым да кайнар самавырга ышкып галстукны шомартып алдым. Кат-кат ямалса да әле чиста булган чалбарымны әнинең сырлы бәләге белән «үтүкләп» кидем.

Киенеп ишек янына баскач:

— Әни, үземнең туган көнгә иптәшләрне дә чакырам! — дип кычкырдым да мәктәпкә йөгердем. Абыйларның мыштырдаганын көтеп торырлык түземем калмаган иде.

Мәктәпкә ашыгып барып кергәнгәме, минем шомарган галстукка да, «үтүкләнгән» чалбарга да игътибар итүче табылмады. Алар өчен бүгенге көннең кичәгесеннән һич аермасы юк иде. Күңел өчен генә булса да шунда хет берсе:

— Нигә бик фыртландың? — дип сорасын. Үзләренең,

югыйсә, чалбарларын әйткән дә юк, галстукларына кадәр бозау муенчагы кебек бөтәрләнеп беткән. Ярар, сорамасалар сорамасыннар. Тик туган көнгә ничек чакырырга? Кызларга әйтергәме, юкмы? Әйтсәм, миннән көлеп, малайлар күземне ачырмаслар. Бигрәк тә Мәхмүттән көн булмас. Әле болай да:

— Ай-ли, Диләрә, Әдипкә хат җибәрә! — дип, җай чыккан саен такмакламый калмый. Хикмәт шунда: өченче класста укыганда, Диләрә кәгазь кисәгенә нидер язып торганда, Мәхмүт аны тартып алды. Без Диләрәнең чәбәләнүеннән барыбыз да кызык табып көлгән идек. Их, ни язылганын белсәм, аны Мәхмүткә укытып, читтән көлеп тормас, сугышып булса да, хатны үземә алыр идем. Анда: «Әдип, синең күзләрең үзе яшькелт, үзе матур. Ә колагыңның берсе тырпаеп тора. Бүген дәрестән бергә кайтабызмы?» — дигән сүзләр булган икән. Мәхмүт шуны уку белән:

— Малайлар, Әдип белән Диләрә сөешәләр икән, менә хатлары! Ы-гы-гы,— дип, бөтен класска яңгыратты. Хәзер дә кулына күмер эләгәме, акбурмы, җай чыккан саен коймаларга, стеналарга «Әдип плюс Диләрә» дип күбрәк Мәхмүт яза.

Уйладым, уйладым да шул пумала баш чырылдык кызларга әйтмәскә булдым.

Соңгы дәрес бетүен белдереп, кыңгырау шалтырады. Класс җитәкчесенең чыгып китүен генә көттем дә башкалар урыннарыннан кузгалганчы сикереп торып:

— Малайлар, бүген минем туган көнем, кунакка килегез! — дип кычкырдым. Үзем тизрәк чыгып йөгердем.

Мәктәп капкасын чыккач кына Мәхмүт белән тагын берничә малай мине куып җиттеләр.

— Әдип, малай, синең туган көнгә хәзер үк барырга булдык. Өйдәгеләр барыбер кайтмаган. Ашарга да әллә бар, әллә юк.

— Киттек, малайлар, киттек, әйдәгез хәзер үк киттек!

Өйгә кайткач кичерәсе күңелле минутлар күз алдыма килеп җаным рәхәттә йөзә. Әни тәмле нәрсәләр пешергәндер, алар кайнар, авызга кабуга телеңне йотарлыктыр.

Шуларны уйлагач, авыздан сулар килеп китте. Бу рәхәтне мөмкин кадәр якынайтырга теләгәндәй, җитәкләшеп өйгә таба йөгердек.

Кайтсак, син күр дә мин күр, ишектә — йозак! Ачып кердек. Әни әле эштән кайтмаган, иртән ягылган булса да, өй суынырга өлгергән иде. Безне күргәч, почмакта күшәп яткан бозау шатлыгыннан мөгрәп, аягына басты һәм Мәхмүтнең сумкасына таба телен сузды. Идәндә йөгереп йөргән сарык бәрәннәре атылып сәкегә менеп киттеләр. Морҗаның кайсыдыр тишегеннән кычкырган чикерткә дә бер мәлгә тынып калды. Идәндә сарык бәрәннәре туздырып ташлаган печән калдыклары иде.

«Туган көн, туган көн!» — дип йокыдан торганда ук бик күпкә өметләнеп, тантана итеп йөргән булсам да, малайлар белән таракан катып үләрлек буш өйгә кайтып кергәч, нишләргә белмичә, аптырап калдым. Ярый әле Мәхмүт бар. Башымны кашып торганны күргәч, ярдәмгә килде.

— Син, Әдип, юкка кайгырма, малай. Туган көн — бәйрәм көн. Ә бәйрәм көнне, үзең беләсең, тәмлерәк ашыйлар.

— Әни берни дә пешермәгән ахрысы әле.

— Пешермәсә, пешерер, без көтәрбез әле. Ул кайтканчы капкалый торырга нәрсә булса да ярар...

Мәхмүтнең тел төбен аңларлык. Гомеремдә дә сандыкны ачып караганым юк иде. Ләкин әни аны ачканда ниләр барын күргәнем бар. Сандыкка үз белдегең белән кергән өчен әниең баштан сыйпамасын яхшы беләм, ләкин малайлар алдында сер бирергә ярамый. Хуҗа кешелә мин! Өстәвенә, бүген туган көнем. Өченчедән, кунакларым бар.

Шкафтан ачкычны алып сандыкны ачтым, әниең елына ике-өч кенә күрсәтә торган конфет, прәник ише тәмлерәк нәрсәләрен өстәлгә утырттым. Сәке астында кичә аерган каймак бар иде, аны да алып куйдым. Каймак булгач кашык та кирәктер дип кузгалган идем, Мәхмүт:

— Мәшәкатьләнмә, Әдип, болай да ярар,— дип, прә-

ниген каймакка батырды. Аның бу кыю адымы башкаларга да ошады.

Сыйны яраттылар малайлар. Берсеннән-берсе уздырып, мактый-мактый ашадылар. Иртәдән бирле канатланган күңелем эреде. Тагын боларны ничек сыйлыйм икән дип уйлый торганда искә төште: әни, карчыкларны җыйгач, аларга акча да өләшә иде. Андый вак-төяк акчаларның сандыкта кайда сакланганын беләидем, шуннан алып малайларның һәрберсенә унбишәр тиен акча бирдем. Мәхмүт, акчаны әйләндереп-әйләндереп карагач, кесәсенә салды да:

— Яшә, Әдип, чын егет икәнсең! — дип мактады.— Синең туган көнең быел тагын булмыймы? Булса, безне калдырма, яме, малай. Әбәзәтелне килербез. Ие бит, Рәхми?

— Шту син, килмичә! — диде Рәхмәтулла, ике конфетны берьюлы кабып.

— Киләбез, киләбез! Әдипнекенә дә килмәгәч...

Төргәктән алып, алар алдына соңгы конфет-прәникләрне салдым. Ашау белән шулкадәр мавыгылган, әнинең кайтканын да сизмәгәнбез.

— И-и, кунаклар да бар икән,— дигән тавышка борылып карасак, әни. Мин ни әйтергә дә белмичә урынымда калдым, малайлар, дәррәү кузгалып, киемнәренә тотындылар. Рәхмәтулла, киенеп тә тормыйча, пальтосын култык астына гына кыстырып чыгып сызды.

Әни ачуланыр дип курыккан идем, ачуланмады.

— Кая барасыз? Бүген улымның туган көне, хәзер коймак пешерәм. Бар, Рәхмәтулланы да чакыр,— дигәч, эреп киттем. Дөньяда минем әнидән дә яхшырак берәү дә юктыр ул. Әнә бит орышмады, шуның өстенә хәзер коймак белән дә сыйлыйм, ди. Елына сабан-туй белән Октябрь бәйрәменнән башка вакытта коймак авыз итеп карау бәхетенә ирешмәгән безнең кебек авыл малае мондый сыйдан баш тартамы соң?

Рәхмәтулла да кергәч, малайлар, киемнәрен чөйгә кабат элеп, өстәл янына килеп утырдылар. Әни мичкә ягып җибәрде, бер савытка йомырка сытып, сөт салып коймак туглый башлады.

Самавыр куярга су беткән икән, Мәхмүт белән икәү чыгып коедан су алып кердек.

— И, малай, кабырганы саный инде дигән идем әниеңне,— дип пышылдады Мәхмүт, суга чыгышлый.

Әни тиз генә самавырга су салды да мичтәге утлы күмер белән кайнатырга утыртты. Ул арада мич өлгерде. Әни, табаларны чыжылдатып, коймакларны салып тора, пешкәннәрен мичтән алып тора. Мин бер савыт коймакны майлап өстәлгә китердем.

— Кунакларың белән үзең дә аша инде,— дип, әни кайнаган самавырны өстәлгә куйды.

Коймак белән берәр чынаяк чәй эчкән идек, абыйларга ияреп тагын Сәгыйть, Дамир һәм Зөбәер килеп керделәр.

Тора-бара безнең эшләр хутка китте. Иптәш малайлар киләләр, ашап-эчеп китә торалар. Соңарып кына Салих белән Гата килделәр. Алар бездән бер класс түбән укыйлар.

— Әдип, синең туган көнең икәнне без ишетмәгән идек, гаепләмә инде, яме, Мәхмүт кенә әйтте трай тибеп уйнаганда,— диде Гата. Ә үзенең күзе миндә түгел, өстәлдәге коймакта.— Ачуланма инде, яме.

— Ачуланмый, ачуланмый. Әйдәгез, өстәл янына утырыгыз! — Әни аларны түргә чакырды.

Чәй эчертеп Салих белән Гатаны да озаттык.

Караңгы төште. Классташ малайларның икешәрләп-өчәрләп һәммәсе дә килеп киттеләр. Әти кайтты, ул да ашап-эчте. Абыйлар буага кәшәкә сугарга чыгып тайдылар. Ихтимал, башка керүче булмас дип, табынны җыештырып куйдык. Мин дәрес хәзерләргә утырдым.

Шул вакыт әкрен генә шыгырдап капка ачылганы ишетелде. Кемдер сак адымнар белән ишегалдына үтте. Менә керерләр, менә керерләр дип көтсәк тә, ишекне ачучы булмады.

— Ишек токкасын табалмыйлардыр... Малларны да карап керермен.— Әти, җилкәсенә тунын салып, чыгып китте. Бераздан аның:

— Нигә кермисең, кызым, кер. Әдип тә өйдә,— дигән тавышы ишетелде. Шулай сөйләнә-сөйләнә ул ишектән,

беләсезме кемне, Диләрәне кертте. Әйе, әйе, өченче класста миңа хат язып, икебезне дә оятка калдырган Диләрәне.

Әти үзе кереп тормады, ә Диләрә ишек төбендә басып калды. Башын аска игән, кулын артка яшергән. Мин дә ни әйтергә белми торам. Әле ярый әчке яктан әни чыкты.

— Бәлеш, Әдип, нигә кунагыңны утыртмыйсың? Уз, Диләрә, уз. Мин хәзер чәй хәзерлим.— Әни әчке якка кире кереп китте.

Ул кереп китүгә:

— Әдип, туган көнең котлы булсын! — дип, Диләрә миңа дәфтәр битенә төрелгән нидер сузды. Мин аны алуга, үзе ишектән чыгып та сызды. Сүз әйтергә дә өлгерми калдым.

Ишек тавышына әни чыкты.

— Кая китте кунагың?

Әни күрмәсен дип, Диләрәнең бүләген кесәгә яшердем. Үзем, җинаять эшләп тотылган кебек, кая карарга белмим. Әни янымнан киткәч кенә җиңел сулу алдым.

Диләрәнең төргәген бик карыйсым килсә дә, әти белән әни йокларга ятмыйча кыюлыгым җитмәде. Алдым. Минем кулда зәңгәр белән читләнгән ак кулъяулык иде. Аның өч почмагында кып-кызыл роза чәчәкләре. Ә берсенең тажы уртасында «Д» хәрефе чигелгән. Кинәт миңа әйтеп бетергесез рәхәт булып китте. Тәнем кызыша сыман. Йокларга яттым. Күзгә йокы керәме соң? Әледән-әле кулъяулыкны сыйпап куям. Ахырда, түзмичә торып, тәрәзәдән карап торган айның саран яктысында тагын бүләккә текәлдем. Үзем куркам. Әгәр Мәхмүт, башка малайлар белсә? «Кияү» дип күзне ачырмаслар бит.

Йокыга китәргә тырышып күземне чытырдатып йомам. Миңа барыбер Диләрә күренә. Юрганны баштан ук бөркәнеп ятам. Күз алдымда һаман шул ук Диләрә тора сыман. Кара әле, аның килүе, туган көнемә бүләк күңелне урыныннан кузгатты ич. Уйлап карасаң, класстагы, юк, класстагы гына түгел, авылдагы кызлар арасында да иң сөйкемлесе ул икән бит. Ничек мин моңарчы сизми йөргәнмен? Кызларның бүләге шундый була микәнни?

Шуларны уйлый-уйлый йокыга киткәнмен...

Туган көнемне беренче искә алу әнә шулай үткән иде. Бераз үсә төшкәч, бигрәк тә студент чакта һәм эшли башлагач туган көннәрне ел саен диярлек билгеләп үтә башладык. Ләкин аларның берсе дә иң беренчесенә охшамады. Бүген кызымның соравы әнә шул көнне күз алдына китереп бастырды. Бала. Заман. Язмыш. Мөмкинлекләр...

Мин иң кадерле истәлекләребез сакланган чемоданны ачтым. Һәм дәфтәр битенә төрелгән кулъяулыкны алып карадым. Зәңгәр читле ак кулъяулык. Өч читендә янып торган роза чәчәкләре. Берсенең уртасына «Д» хәрефе чигелгән. Хәзер аның тәҗрибәсез бала кулы белән эшләнгәне күзгә ташланып тора. Ләкин хикмәт ничек чигелүендәмени? Минем иң беренче тапкыр уздырган туган көнемнең бердәнбер бүләге бит ул. Ул бүләк, бәлки, аннан да зуррак сергә иядер әле. Минем туган көнем бүләге.

ӨЯНКЕ

I

Матур бүген көн. Каурый болытлар, һәркемнең игътибарын үзләренә тартырга теләгәндәй, җирне көязләнеп күзәтәләр. Кояш, әле генә гашыйк булган төсле, тауларны, яшеллеккә төренгән болын-тугайларны, карасу-зәңгәр урманнарны, көзгедәй ялтырап күренгән сулыкларны иркәли. Назлы җил юл буендагы бөдрә кылганнарны сыйпап-сыйпап үтә дә Юлчыга килеп сарыла.

Таулар арасындагы иңкүлектән сукмак уза. Аның башы каядыр еракка, офыкка барып тоташа, ә дәвамы алда күренгән тау түбәләре артында күздән югала.

Безнең Юлчы җилгә дә, кояшка да, бер минут эчендә әллә ничә төрле кыяфәткә кергән көяз болытларга, хәтта баш очында гына сайраган тургайларга да игътибар итмәстән бара да бара. Ашыга ул, күзенә тар сукмактан башка берни күренми. Юлы озын — акрын атласа, барасы җиренә якты күздә барып өлгермәячәк.

Юлчының гамьсезлегенә аккоштай болытларның хә-

терләре калды бугай: кай арададыр куерып өлгергәннәр. Күк йөзе кинәт караңгыланды. Әле генә Юлчыга килеп назланган җил усалланды: битне тырнап-тырнап китә һәм шунда ук, өереп китереп, юл тузанын күзгә сылый башлады. Җир белән күк арасында утлы сызыклар илче булып йөрергә керештеләр.

Юлчы адымын тагын да кызулата төште. Табигать белән аның арасында тартыш көчәйде. Кинәт, шик-шөбһәгә салып, борыны төбендә генә бөтен тирә-юньне яктыга күмеп яшен яшьнәп алды, аның артыннан тауларны дер селкетеп күк күкрәде. Күк патшасының әмер бирүе шул булды, ахрысы, эре-эре яңгыр тамчылары сукмакта сикерешә башладылар. Берничә минуттан тирә-юньне ап-ак су пәрдәсе каплап алды. Ерганаклар, бер-берсе белән узышып, түбәнгә ашыктылар.

Юлчы, ышыкланыр урын эзләп, як-ягына каранды. Юлдан аз гына читтәрәк чокыр буенда үсеп утырган ялгыз өянкене күреп алды. Ышыкланырдай башка урын булмагач, Юлчы әлеге өянкегә таба йөгерде. Бәхете бөтенләй үк ташлап бетермәгән икән егетне: карт өянкенең ул сыярлык кына куышы да бар иде.

Яңгыр явуын дәвам итте. Ул инде хәзер чиләкләп коя иде. Юлчы, куыштан сирәк-мирәк кенә башын чыгарып, күк йөзен караштырды. Ниһаять, ничек кинәт ява башласа, җәйге яңгыр шулай туктады да. Күк йөзендә инде кичке шәфәкъ нурлары җәелергә өлгергән иде. Яшенле яңгырдан соң гына була торган хуш ис борынны кытыклый, сулу алулары рәхәт иде. Тик кичке салкынча һава Юлчының юеш киемнәре аша тәненә, җелекләренә кадәр үтте.

Юлчы инде кузгалып китәргә ниятләгән иде, ләкин якындагы авылга күпме барасын хәтеренә төшергәч, уеннан кире кайтты. Иңенә аскан капчыгын кабат җиргә куйды, биленә кыстырган балтасын кулына алды, аның йөзен капшап карады. Үткенлегенә ышангач, өянкегә күз ташлады һәм, киерелеп селтәнеп, аның купшак тәненә балтасын батырды. Өянке моны көтмәгән иде, сискәнеп китте. Ул әле тәнендәге авыртуны сизәргә өлгерә алмый калды. Икенче тапкыр селтәнүдән соң авырту аның язгы сулар

ергалап, ашап бетергән төсле чокыр-чакырлы карт тәне буенча таралып китте. Өянке түзә алмыйча аһылдап, иңрәп куйды. Бөдрә яфраклары балта килеп кагылган саен шыбыр-шыбыр яшь түктеләр. Өянке, сыкранып, егеткә инәлде:

— Егет, кисмә мине! Әле яшисем, юлчыларны җилдавылдан ышыклыйсым бар, канатлары талган кошкайларны кочагымда ял иттерәсем бар. Кисмә мине, егет, кисмә...

Өянке ялварды. Юлчы, аның сүзләренә, аһ-зарына, күз яшьләренә игътибар итмичә, балтасын тагын да җәһәтрәк селтәргә кереште. Аңа эссе булып китте: бер читкә күлмәген салып ыргытты.

Өянкегә балта чабылган саен якындагы таулардан кайтаваз булып иңрәү авазы яңгырады:

— Е-е-гет, кисмә-ә ми-не-ү...

— ...Кисмә-ә-ә мин-не-ү!..

Куыш өянкенең йомшак тәне көчле егет кулындагы үткен балтага озак каршылык күрсәтә алмады, һәр селтәнүдән соң кәүсә нечкәрә барып, тиздән ул ыңгырашып җиргә ауды. Юлчы, биленә таянып, аның тау кадәр булып яткан йөз еллык мәһабәт гәүдәсенә сокланып карап торды. Аннары, маңгаена чыккан тирен сөртеп, агачның корырак ботакларын туракларга тотынды. Утыны җитәрлек булгач, ул өянкегә утырып учак кабызырга кереште. Яңгырда чыланган ботаклар тиз генә кабынып китәргә теләмәделәр. Шулай да Юлчы морадына иреште — аны кабызып җибәрде. Ялкын дөрләп китеп, инде сүнмәсенә ышангач, канәгатьләнүдән ул елмайды һәм чәй кайнатырга утыртты. Үзе, чишенеп, учак өстендә киемнәрен киптерергә тотынды.

Коры киемнәр киеп алгач, Юлчының кәефе тагын да күтәрелде. Йолдызларга карап бераз утырды да ул, җылы көл өстенә өянке яфракларыннан урын хәзерләп, йокларга ятты.

Кояшның беренче нурлары белән уянды Юлчы. Кичтән калган чәйне кайнатып эчте һәм иртәнге томан аша каралып күренгән тау түбәләренә карап юл тотты. Ул кал-

дырып киткән учакның күмерләре, көзен соңгы яфраклар өзелеп төшкән сыман, бер-бер артлы сүнә тордылар. Өянке төбе, баласы тарафыннан рәнҗетелгән карт анадай, тын гына, тавышсыз гына елап калды...

II

Әбиләр чуагы күптән узган, көзнең көн аралаш салкын яңгырлар ява башлаган чоры иде.

Күп җирләр йөреп, күп илләрдә булып инде өенә кайтканда әлеге Юлчыга шул сукмактан кабат үтәргә туры килде.

Иртәдән бирле күктән салынып торган елак болытлар кичкә таба каралганнан-карала бардылар. Иртән әле сирәк-мирәк чеметкәләп киткән җил дә үзенең очлы сөңгеләрен рәхимсез рәвештә Юлчының битенә батыра башлады. Аның кояшта янып, җилдә киселеп беткән йөзеннән инде туктаусыз яңгыр суы ага иде.

Тора-бара яңгыр юеш карга әверелде. Баруы тагын да кыенлашты. Юлчының аяк асты тая, каршыдан искән җил керфекләренә кар сылый, яшьләнеп, күзләре томалана иде. Тәнне генә түгел, җанны да өшетә торган суык көн иде. Инде юл күренми башлады: кайда да ак рәшә. Һәр адым гаять зур көч, түземлек, ихтыяр сорый. Табигать белән көне буе көрәшеп, Юлчы бөтенләй хәлдән тайды. Менә аның аяклары, бу авырлыкка түзә алмыйча, сыгылып төштеләр. Шунда Юлчы, хәтерен җыеп, җәй көне кискән өянке агачын исенә төшерде. Инстинкт Юлчыны өянке янына бер ялгышусыз китерде. Учак урынын кар күмгән, өянке кәүсәсен дә җирдән чак аерырлык иде. Иңенә аскан капчыгын көч-хәл белән ычкындырды да Юлчы, җилгә аркасы белән борылып, аңа утырды. «Я, раббем!» Бәлки, гомерендә беренче тапкыр авызыннан шундый сүз чыккандыр. Моңарчы ул үзенә үзе алла иде.

Кар яуганнан-ява, тәнгә сырышканнан-сырыша бара, туктарга исәбе дә юк кебек.

Ләкин безнең Юлчы боларның берсен дә: юешне дә, суыкны да, җилне дә гүя сизми, хәрәкәтсез утыра бирә.

Үзенең ойый башлаганын тоепмы, ул күтәрелмәкче булды, тик һәрвакыт аңа тугры хезмәт күрсәткән аяклары бу юлы тыңламадылар, сыгылып төштеләр. Ихтыярыннан тыш аңын ниндидер хис телеп үтте, җан биргәндәге төсле, гәүдәсе калтыранып, тартышып куйды да, Юлчы йокыга китте. Тиздән аның гәүдәсен өянке төбеннән аерып булмый иде инде.

Юеш кар ишелеп-ишелеп явуын дәвам итте.

III

Бер генә минутка кеше вакытны үз ихтыярына буйсындыра алса иде, белер иде нишләргә икәнен. Юк, аның моңа кодрәте җитми; вакыт дигән дәрья миллион еллар элек ничек акса, хәзер дә нәкъ шулай ага бирә: ярларны җимерә, тауларны чүктерә, тигез җирне түмгәк итә, чокырларны тигезли. Кешеләр дөньяга киләләр, тиешле гомерләрен яшәгәннән соң, китеп тә баралар. Вакыт каршында байлык та көчсез. Вакыт сатылмый да, әҗәткә дә бирелми. Әйтерсең, кеше тормышы мәңгелек дип аталган юлда бер поезддан икенчесенә күчеп утыру өчен бар ителгән бер станция генә.

> Якутлар табыладыр вакыт белән,
> Вакытлар табылмыйдыр якут белән.

Биктаһир үзен бер дә вакытка бирешер кеше кебек сизми иде. Бирешмәссең сиңа! Ничек авызлыклаганын сизми дә калды.

Электәге сәламәтлек ташып, беләкләрендә уйнаган көчтән шартлар чиккә җитеп торган мускуллары хәзер таянып йөри торган таягын һәм табын янында кашыгын авызына кадәр күтәрүдән башкага ярамыйлар. Эчкә баткан яшькелт-көрән күзләре, дөге басуындагы сыман ерганаклар белән тулган сырлы яңаклар, авызының тешсезлеген яшерер өчен калдырылган иләмсез зур мыекларны күргәч, бу кешенең тормыш ачы-төчесен җитәрлек татыганын чамалыйсың. Әмма тышкы кыяфәтенә карап, аның таш тутыргандай авыр юл капчыгын асып, очлары болытлардан

өскә күтәрелгән тауларга кайчандыр эһ тә итмичә менә алуына ышану кыен иде.

Бүген таңга таба Биктаһир төш күрде. Имеш, аның әле малай чагы. Җәй. Сулышка каба торган эссе чиллә вакыты. Ул бер атна кайтмый йөргән сарыкларын эзләргә Түбән оч көтүе төшә торган туплауга барырга чыккан. Күк ап-аяз, бер генә болыт әсәре дә юк. Ләкин кинәт кенә нәкъ Биктаһирның баш очында кап-кара болыт күренде. Кечкенә болыт, үзенең төсе шулкадәр кара, күкнең зәңгәрлегенә әйтерсең бер чиләк дегет түккәннәр. Биктаһирның йөрәгенә шул болыт шом салды, ул борылды да куркуыннан кире авылга таба йөгерергә тотынды. Кайтып җитәргә ерак та түгел кебек. Ләкин кара болыт аның артыннан калмый, чеби тибәргә җыенган тилгән сыман һаман эзәрлекли шул. Аның инде тыны кысыла башлады, ашыгудан ялан аягы белән ташка абынды, гөрселдәп җиргә барып төште. Абынган бармагының тырнагы купты, борыныннан кан китте. Торып тагын йөгерде. Болыт түбәнәя, менә-менә Биктаһирны куып җитәр сыман.

Кая качарга, кая ышыкланырга? Яр астында куыш күреп, шунда керергә теләде. Ләкин борыны төбендә генә кушының калын ишекләре ыңгырашып ябылдылар. Биктаһир ишекне ачарга теләп аягы белән типте, куллары белән сукты, бирешмәгәч, ачудан маңгае белән тутыгып беткән тимергә китереп бәрде. Дыңк иткән саңгырау тавыш ишетелде. Чәчрәп, аның сыңар күзе чыкты һәм, тамырларын асылындырып, ишеккә килеп кадалды. Шунда болыт килеп җитте һәм Биктаһирның өстенә сикерде. Биктаһир кадалган күзен чак алып өлгерде, аннан җан-фәрманга тагын авылга таба элдертте. Эзәрлекләүчесе, капкага орынып, янә өскә күтәрелде һәм тагын куарга кереште. Аралар якынайган саен болытның куллары, тырнаклары үсеп чыга барды. Ул аны менә-менә куып җитәчәк һәм ерткалап ыргытачак иде. Шунда могҗиза хасил булды: каршысында карт өянке калыкты. Биктаһирның монда күпме йөргәне бар, бүген дә шуннан узды — бу кадәр юан агачны бередә генә түгел, әйләнә-тирәдә дә очратканы юк иде. Өянке Биктаһирны кочагына алды һәм, әкияттәге сыман,

куышына яшерде. Болыт күреп калган иде, үкерә-үкерә агачның төбен казырга кереште, иләмсез зур куллары белән агачны йолкып алырга теләде. Тирәнгә киткән тамырлар бер-бер артлы шартлап өзелделәр һәм кара болыт өянкене эләктергән көе югарыга күтәрелә башлады. Бикташир куыштан чыгарга, сикереп төшеп калырга тели, ләкин болыт аңа ирек бирми. Ул кычкыра, әнисен чакыра — тик тамагына таш утырган төсле тавышы чыкмый. Болыт агачны бөтереп йөртте-йөртте дә ялкын эченә китереп ыргытты... Өянкенең ботаклары канатка әверелде. Алар каурый урынына яфрак белән капланган иде. Канаттагы яфраклар куырылып көя, эсседән Бикташирның тамагы карлыга, тыны кысыла. Ялкын эчендә тагын аз гына торса ул янып көлгә әвереләчәк бит. Өянке дә аңа кипкән иреннәре белән: «Түз, түз!» — дип пышылдый. Тавышы әнисе мәрхүмәнеке төсле ягымлы. Баксаң, ул әнисе кочагында икән...

Бикташирның үз гомерендә мондый да куркыныч төш күргәне юк иде әле. Бөтен тәне шабыр тиргә баткан икән ич. Ул маңгаендагы тир тамчыларын юрган тышы белән сөртеп алды.

Яшәгән гомерендә төрлесен кичергән Бикташир һичнигә гаҗәпләнмәскә өйрәнгән иде. Ләкин бу төше аны аптырашка салды: ни диеп юрарга икән? Әллә Мәгыйшә карчыкка сөйләп карарга мы? Юк, ярамас, бөтен авылга таратыр. Әллә соң көннәре санаулы калып барамы? Шушы гөманлау күңелендә әйтеп бетергесез тирән сагыш уятты. Әлеге минутта ул, әгәр дә бүре була алса, озак итеп улар иде. Ләкин адәм баласы бүре түгел. Әмма кешегә хәтер сандыгында казыну, язмыш тарафыннан җибәрелгән көннәрен, дисбе тарткан шикелле, энәсенә-җебенә тикле берәмтекләү сәләте бирелгән.

«Картайдың, Бикташир,— диде ул үз-үзенә,— картайдың. Җыясы тәгамең бетеп килә торгандыр. Аз яшәмәдең. Чама белергә кирәк. Әнә Мәрфуган өченче елын инде гүрдә ята. Урыны оҗмахтадыр. Ә синең комсызлыгың җитәрлек, якты дөнья белән һич кенә дә хушлашасың килми».

Болай ятып эш чыкмас, теш тә чыкмас. Бикташир юр-

ганын ачып ташлады, сыкранып кына торып утырды. Күлмәк җиңе белән янә тирләрен сөртте һәм ак ыштаны өстеннән чалбарын киярга кереште. «Киленгә рәхмәт, керемне юа, өемне караштыра»,— дип уйлап алды кинәт кенә, үзенең дәфтәр кәгазедәй ап-ак ыштанына күз салгач.

Биктаһир өченче елын инде өйдә ялгызы яши. Мәрфуганы җирләгәннән соң балаларының һәрберсе әтиләрен үзләренә, читкә чакырдылар. Карт бармады. Ул көн дә йокыдан уянуына ук тәрәзәсеннән әнә шул таулар күренеп тормаса, урам капкасы буенда шаулап утырган юан тупылга оялаган каргаларның чыр-чуын ишетмәсә, кичләрен яшьтәш картлары белән гәп сатмаса, җәйләрен ишегалдындагы бәбкә үләненә яланаяк басып хозурланмаса, кыскасы, авылның йөзләгән шундый вак-төякләрдән торган тормышыннан аерылса, үзенең гомере кыскарасын, яшәвенең яме кимүен тоя иде. Шәһәрнең нәрсә: дүрт ягың таш стена, күрше күршене белми, яше картларга сәлам бирми. Кунакка барган чакларда да җанын кая куярга белмәде Биктаһир. Бу җәһәттән караганда Мәрфугасы да шулай хис итә иде үзен. Шәһәргә килүләренең икенче көнендә үк тәрәзәдән күзен алмый. «Тавыкларыма ашарга бирделәр микән, Чуарборын бәрәнләргә тора, күршем йоклап калмаса ярар иде»,— дип борчылудан арына алмый иде. Һәм алар, атна-ун көнгә дип кунакка килеп тә икеөч кич кунуга балаларының ай-ваена карамыйча, кайтып китәргә ашыгалар иде.

Шуңа күрә Биктаһир тол калгач та авылыннан китмәскә тырышты. Аннан соң авылда ул бөтенләй үк япаялгыз да түгел ич. Иң олы улының гаиләсе җиде-сигез өй аша гына яши. Мәрзия килене килен ише генәме соң! Тракторы белән силос базына төшеп Мисбахы үлгәнгә ун ел, ә ул һаман кайнатасына тугрылыклы килен булып яши, итагатьле иде. Идән-сәкесен дә атнага бер юып чыгарга өлгерә, киемнәрен дә юа. Оныклары көн аралаш диярлек хәлен белергә кереп торалар. Шәһәрдәге киленнәреннән дә авыр сүз ишетеп, караңгы чырай күргән кеше түгел, тик Биктаһир эчке сизенү белән сизенә: авылдагы килене Мәрзиягә җитәргә ерак әле аларга...

Карт, торып, электр чәйнеген утка тоташтырды. Малайлары шушы чәйнекне алып кайтып биргәннән соң рәхәткә тиенде ул. Берүзенә җиде литр керешле самавыр куеп азапланасы калмады.

Өтәләнә-пешә ике-өч йотым чәй кабуга Биктаһир карт тәненә рәхәтлек йөгергәнен сизде: гүя оешкан тәне язылып китте, тамырлары буенча каны җәһәтрәк йөри башлады. Чәйдән соң зиһене дә ачыла төшә сыман иде. Чәй эчүдән хозурланса да, күргән төше тәэсиреннән айнып бетә алганы юк әле аның. Кайдан килеп керде соң ул төш? Җитәрлек яшәдең, чама белергә кирәк дип, күкләрдән килгән ишарә түгелме? Әллә күңеленең эчке сизенүе шулмы? Ничек кенә булмасын, соңгы юлга хәзерләнә тор, итәкҗиңеңне җыя башла дигән ишарәдер инде.

Табын яныннан кузгалганда ул ни эшләячәген белә иде инде. Башына түбәтәен киде, кулына соңгы елларның аерылмас юлдашына әверелгән таягын алды. Бу таякны моннан ун еллар чамасы элек чикләвек агачыннан ясаган иде.

«Алмас өйдәдер, тегендә-монда китеп югалгаланганчы тотарга кирәк үзен»,— дип уйлады Биктаһир, килене йортына табан юнәлеп. Бик ашыгыр чакларда да ул адымын кызулатмый, чөнки ашыга башласа, үз таягына үзе үк абынып егыласын белә.

Алмас фермада терлек карый. Иртән бер кат эшләрен бетергәч күпмедер вакытка ул бушый төшә һәм, йортына кайтып, үз эшләре белән шөгыльләнә. Кирәксә, хәтта «Жигули»ена утырып шәһәргә дә барып кайтырга өлгерә. Шуңа күрә кая да булса чыгып тайгалаганчы онығын ничек тә күреп өлгерергә кирәк. Картның ашыгуы тикмәгә түгел иде.

Биктаһирның күңеле дөрес сизенгән икән: ул капкадан килеп кергәндә Алмас машинасын гараждан алып чыккан, пыяласындагы тузаннарын сөртеп тора иде. Бабасын күрүгә, чүпрәген ташлап, күрешер өчен каршысына атлады.

— Исәнме, бабакай!

— Шөкер әле, улым, ходайның биргәненә шөкер.— Карт сузмаска, шунда ук гозерен әйтергә булды.— Алмас

улым, мине машинаң белән бер җиргә алып барып кайт әле.

Алмас гаҗәпкә калды: моңарчы картны «Жигули»га кыстап-кыстап та утырта алганы юк иде. Нәрсә булган моңа? Фельдшер Гөлниса шәһәргә барып дарулар алып кайтырга булышуын сорагач, ул ризалашкан иде. Бабасына шуны ничек аңлатырга? Картлар хәтере пыяла, тимәс борын уала, дип әйтәләр ич.

— Бабай,— диде ул кыяр-кыймас,— башка көнгә калдырып булмыймы соң ул бер жирне? Бүген барасы җирем бар иде.

— Кая тагын? — диде Биктаһир карт.— Кем белән? — дип тә өстәде.

Әйтергәме-әйтмәскәме? Икеләнеп торганнан соң Алмас турысын ярып салды:

— Шәһәргә, Гөлниса сораган иде. Дарулар беткән, ди.

«Чибәр духтыр» Гөлниса исемен ишетүгә картның чыраенда елмаюга тартым бер дулкын чагылып узды. Күзендә шаян чаткылар уйнап алды:

— Алай икән,— дигән булды ул сузып кына, беләбез сезне, дигән сыман һәм тагын бер тапкыр: «Алай икән»,— дип кабатлады. Аннан машинаның уң ягына чыгып ишеген ачарга тырышып карады. Ачылмагач, нәрсә карап торасың дигәндәй, күзләрен оныгына текәде.

Кабина аша үрелеп Алмас алгы ишекне ачты. Биктаһир карт тавыш-тынсыз гына машина эченә кереп утырды.

— Киттек,— дип команда бирде карт.

— Кая?

— Кая булсын, Гөлниса янына дисең ич.

Шаяртамы әллә дип, Алмас бабасына карады. Аның аптыраулы карашын тоеп, Биктаһир янә:

— Киттек,— дип кабатлады.

Капкадан чыккач кына ул кая барасын әйтте.

— Шәһәргә Карагаш кулы аша барырсың. Курыкма, мин үземә кирәк җирдә төшеп калырмын. Сезгә артык йөк булып йөрмәм. Кайтканда кереп алырсыз.

Алмас шактый четерекле хәлдә калган иде, мондый җиңел чишелеш табылуына куанганын бабасына сиздер-

мәскә тырышты. «Сарык та исән, бүре дә тук». Шулай килеп чыга түгелме соң? Чыннан да, Гөлниса алдында да вәгъдәсез булып калмый, бабакаеның да сүзен җиргә екмый...

Медпунктта Гөлниса әзерләнеп көтеп торган икән. Сигнал бирүгә, сыланып торган күлмәге эчендәге тыгыз тәнен уйната-уйната килеп тә чыкты. Машина эчендә утырган картны күргәч, бер мәлгә битендәге елмаюы югалган иде дә, үзен бик тиз кулга алып өлгерде. Җил-җил атлап килеп, арт ишектән кереп утырды.

— Исәнме, бабай! Исәнме, Алмас!

Алмас башын иеп сәламне алды, Биктаһир:

— Шөкер, кызым, шөкер,— дип җавап кайтарды.

Кузгалып киткәнче Алмас кызга аңлатма бирүне кирәк санады:

— Гөлниса, башта бабайны Карагаш кулында калдырабыз, син каршы килмәсәң. Аз гына уратып барасы булыр.

— Миңа барыбер.— Кыз, үзенә чыннан да барыбер икәнлеген раслау өчен, җилкәләрен җыерып алды.

Күпердән инеш аръягына чыктылар. Бераздан авыл артта калды. «Жигули»га булмаса да, Биктаһир машинага бөтенләй утырмаган кеше түгел. Шулай да утырган саен тизлеккә, күз алдындагы сурәтләрнең әдигәнче алмашынуына гаҗәпләнүдән туйганы юк. Җәяү яки атта барганда, карашың белән алда нәрсәнедер билгелисең дә, шуңа карап барасың да барасың. Аңа килеп җиткәндә инде арыган, талчыккан буласың. Ә монда һәрнәрсә күренергә өлгерми, очкан коштай каршыңа якыная һәм, син күр дә мин күр, артында күздән дә югала.

Менә Бакыр базы да артта калды. Юл өстенә ни дә булса җәелмәсә дә, яңгырдан соң моннан грейдер үткән, юл тигез иде. Каршыда ике тау арасына сузылган Карагаш кулы күренде. Машинаны афәттән саклап калырга теләгәндәй, Биктаһир карт алга табан иелде, күзләрен пыялага ук терәп диярлек бара башлады.

Карагаш кулының башына элек каракошлар куна торган булган. Исеме шуннан калган дип сөйлиләр, диде карт.

Каракошлар тауның нәрсәсенә кызыкканнардыр, Алмас шуңа төшенә алмады. Иңкүлеге иңкүлек сыман, тавы башка тауларга охшаган: әллә ни сөзәк тә, текә дә түгел, уртача гына.

Иңкүлекне урталай бүләргә теләгәндәй Карагаш кулын тирән чокыр кисеп чыга иде. Кырыена килеп җитми торып аның бик тирән һәм текә ярлы икәнлеге белмәгән кешенең башына да килмәс иде. Менә шул чокырга якынлашуга Биктаһир оныгының кулына кагылды. Күңеле алгысыган җиргә берьялгызы, шаһитларсыз гына барырга теләде ул.

Бабасының кинәт ясаган бу хәрәкәтеннән Алмас дерт итеп куйды.

— Улым, калдыр мине шушында,— диде карт, туктарга кушып.

Алмас машинасын туктатты да төшеп бабасына чыгарга булышты. Бабасыннан артык сүзне кадак суыргычы белән каерып та алып булмасын белсә дә, кызыксынуын тыя алмыйча сорады:

— Нишлибез, бабай?

Биктаһир күңеле белән башка дөньяда иде, шулай да оныгының соравын җавапсыз калдырмады:

— Сез, балалар, барасы җиргә барыгыз. Үз вакытыгыз белән кайтышлый кереп алырсыз. Мин ә-әнә шул чокыр тирәсендә булырмын.

Алмасның икеләнебрәк торуын күреп, тагын кабатлады:

— Барыгыз, бар. Юл кешесенең юлда булганы яхшы.— Үзе, минем сездә эшем юк дигәндәй, юл кырыенда чыгып торган ташка барып утырды.

Машина кузгалып киткәч, Биктаһир уйлары белән япаялгыз калды. Машинада чакта ул курка-курка килде: Алмас та, бигрәк тә артта утырган сөрмәле күз доктор кыз да аны үтәдән-үтә күрәләрдер сыман тоелды.

Бүген ул башка берни дә теләмәс, кодрәтеннән килсә, вакыт дигән дәрьяны кирегә борыр иде дә гайрәте ташып торган көннәрнең карлы-бозлы көзенә кире кайтыр иде.

Тукта, Биктаһир, син бит бирегә иләс-миләс уйларга бирелер өчен килмәдең, ниятең бүтән иде бит синең...

Ул, кулы белән капшап ни-нәрсәдер табарга теләгәндәй, утырган ташы тирәсендәге җирне тоткалап карады. Кайда да ташлы балчык. Биктаһир тураебрак утырды да, кулын каккалап, күп юудан соргылт төскә кергән чалбарының балагына сөртте.

— Болай утырып булмас, ниятләгән җиргә барырга кирәк. Югыйсә Алмас кайтып та җитәр,— дип сөйләнде дә торып басты. Кулын кашы өстенә куеп, ераккарак карарга теләде.

Еракта биек-биек тау тезмәләре, ә аның эзләгәне кайдадыр шушында, якында булырга тиеш бит.

...Аңына килгәндә Биктаһир егет ап-ак бушлык эчендә ята иде. Кайда ул? Күз карашын кар аклыгы камаштыра, ә үзенә нигәдер бер дә салкын түгел кебек, кар эчендә ят та, салкын да булмасын, гаҗәп... Әллә җылы кар да буламы? Кул-аякларына ни булган? Таш бәйләгән шикелле авыр тоелдылар алар.

Больницада ятуын бераздан соң гына аңлады ул. Карагаш кулында буран эчендә калуын, соңыннан, тәмам хәлдән тайгач, киселгән өянке төбенә килеп егылуын бик авырлык белән генә хәтерли алды. Ул чакта боз энәләре ничек рәхимсез кадалсалар, хәзер дә хәле шуннан җиңел түгел, хәзер дә кулының, битенең, аягының әрнүенә көчхәл белән чыдап ята иде.

Беренче тапкыр күрешүендә Мәрфугасы, аңын югалткан кешедәй, бик озак сүз әйтә алмый торды. Аннары гына: «Исән, исән!» — дип иренең күкрәгенә капланды, ихтыярына буйсынмаган аяклары хәлсезләнеп, сыгылып төштеләр. Тәне әрнүгә чыдый алмыйча кычкырудан чак тыелып яткан Биктаһир, кулын сузу түгел, хатынын юатып авыз да ача алмады. Хәле хәл, үзе тере мәет белән бер иде...

«Адәм баласы — ерткыч. Мин дә ике аяклы бүремен». Кинәттән үзен бүре белән чагыштыруга Биктаһир карт чыраен сытты: «Таптың чагыштырыр җәнлек. Кайсы

кешегә, кемгә этлек эшләгәнең, ерткычлык кылганың бар?»

Биктаһирның адымнары акрын. Үзе атлаган саен таягын җиргә төртеп куя, гүя шул рәвешле соңгы сәгатьләре алдыннан бугазыннан алган борчуларыннан котылырга, булган һәм бар дип фараз иткән гөнаһларын җиргә тапшырырга исәпли.

Кинәт колагына:

— Егет, кисмә-ә-ә мин-не-ү! — дип иңрәгән тавыш ишетелеп китте сыман. Биктаһир карт сискәнеп туктап калды һәм бөтен тәне белән борылып дүрт тарафны күзәтеп, барлап чыкты.

Карагаш кулы — алар авылыннан унбиш-егерме чакрымнарда иде. Инде аның байтактан, шәһәргә турыдан күтәртелгән юл салынганнан бирле бирегә аяк басканы юк иде.

Теге вакытта больницада дүрт ай чамасы ятты Биктаһир. Терелеп өенә кайтканының икенче көнендә үк больницага эләгәүе аркасында көзен бугазланырга өлгерми калган бер яшьлек печкән тәкәне иртән иртүк суеп алды. Ике кулына алты бармак калган иде, шулар белән сарык тунавы җиңел булмады аңа. Ләкин алда әле шактый яшисе бар иде. Алты бармак белән сарык сую гына түгел, аннан да катлаулырак эшләр башкарырга туры киләчәген белгәнгә күрә ул ярдәмгә кеше чакырмады, тешен кысып түзде.

Хәзер түшкәне салырга ат кирәк иде. Анысына да каршы төшмәделәр. Сәгать тә узмагандыр, ул бригадирның артлы җиңел чанага җигелгән Бурлы айгырына утырып, авыл капкасыннан урманга таба чыгып бара иде.

Урманчы Садыйкны тирә-юньдәге авылларда белмәгән кеше бар идеме икән? Урманга рөхсәтсез аяк басучыларга карата Садыйк кырыс булды. Агач кистеңме яисә печәнлекне таптап берәр кәҗәлек кенә булса да аны чабып арбаңа салдыңмы, сизми дә каласың: Газраил кебек калкып, каршыңа Садыйк килеп чыга. Ә ул урман шүрәлесе кулына килеп каптыңмы, елап кан-яшь түк, елан мөгезе белән күгәрчен сөте вәгъдә ит — файдасыз иде. Садыйк тәртипне тиешенчә саклый, хәрәмләшергә юл куй-

мый иде. Инде бик тә мохтаҗ чагың икән, үзен күр, хәлеңне аңлат, ышандыра алсаң, ярдәм дә итми калмас.

Әмма урманчының даны моның белән генә чикләнми иде. Күпләр мылтык асып йөреп сыңар куян да ата алмаганда, Садыйкның, тере бүре тотып, халыкның ушын алмый калган еллары сирәк булды. Садыйк урман патшасын чанага бәйләп сала һәм авыл саен күрсәтеп йөри. Аучының иң бәхетле минутлары, мөгаен, шулдыр. Үзен сунарчыга санап, берсеннән-берсе ыграк арттырып, комнан бау ишүчеләр буа буарлык. Сез менә бүрене тере көе кулга төшереп карагыз. Монда инде, туган, сүз озайтуның, шапырынуның кирәге юк. Әнә, чанага карагыз. Бүрелегенә ышанмасаң, авызына бармагыңны тык. Белерсең кем белән эш иткәнеңне!

Чананы сырып алган халык, урманчының булганлыгына соклануын яшермичә, бүре белән әвәрә килгәндә, Садыйк, чак кына мыскыллы елмаеп, калын олтан салган киез итекләре белән бер читтә тәмәке тартып торыр. Башка вакытта бик батыр күренергә тырышкан авыл этләре, койрыкларын кысып, капка артыннан гына ара-тирә һауһаулап алыр иде...

Биктаһирны теге вакытта шул кеше үлемнән йолып калды. Шуның өчен бүләккә дип алып барган ит түшкәсен дә Садыйк кире биреп җибәрде. Өстәвенә, сиңа дәвасы булыр дип, әле бер калҗа бурсык ите дә тыккан иде. Урманчы күп сүзле адәм түгел, Биктаһирны ничек коткаруын ике-өч җөмлә белән сөйләп бирде:

— Буранның икенче көнендә, чана җигеп, урман чистартучылар янына барган идем. Кайткан чакта Карагаш кулына сугылырга уйладым. Берзаман Акмуен чиный-чиный кар актарырга кереште. Бәхетең бар икән, энем... Миңа рәхмәт әйтмә, эткә әйт. Акмуен булмаса, күрми үтеп китә идем, валлаһи!

Кар астында төн кунып та Биктаһир сул кулының өч, уң кулының чәнчә бармагын югалту белән чикләнде. Күлмәк белән туган димичә, ни дисең... Ә менә язмышның рәхимсезлеге — Садыйк шуннан соң өч-дүрт елдан артык яшәмәде. Урманда чакта йөрәк авыруыннан үлгән, мәр-

хум. Өенә аты алып кайткан. Язмыш шулдыр инде, күрәсең. Биктаһир исә коткаручысын күмешергә дә бара алмады, соңыннан гына ишетте.

«Үткән гомер — аккан су». Су аккан җирнең эзе кала, үткән гомер йодрык кадәр баш миенә иксез-чиксез хәтер булып кунаклый. Биктаһирның хәтере дә тау кырласы сыман киртләч-киртләчтер.

Күңеле ашкынган, иртәдән бирле тынгы бирмәгән урынны тапмый торып, хушлашмый торып Биктаһирның бу дөньяны калдырып китәр хакы юк. Кайчандыр мәгънәсезгә кисеп аударган өянке төбе аның өчен бөтен булган гөнаһларын ярлыкар өчен хаҗ кылырдай үзенә бер Мәккә иде хәзер. Ниятен тормышка ашырмаса, теге дөньяда да тынгы тапмас, кайберәүләр әйтмешли, каберендә кыямәт көненә кадәр әйләнеп-тулганып ята бирер. Биктаһир тәгаен белә: соңгы сулышын алган чакта, аның күз карасында өянке һәм тоныκ ай шәүләсе чагылып торыр...

Эзләгән чокыры каршына килеп чыккач, ул үз-үзенә ышанмый, шомырт таягына таянган килеш озак басып торды. Әллә хәтере бутыймы? Яисә күзләре ялгыш күрәме? Берничә адым түбәндә, ямь-яшел чирәм белән каплаган чокыр эчендә бер төптән күтәрелгән өч өянке үсеп утыра иде. Берсенә хәтта саескан да ояларга өлгергән.

Хәлсезлеген онытып, Биктаһир шунда табан ашыкты. Әйтерсең кем тарафыннандыр билгеләнгән вакытка соңара. Гәрчә үзе бу яшьтә беркая һәм беркайчан да соңармаячак икәнен бик яхшы аңлый.

Ашыгып атлаудан Биктаһир кулында таягы барлыгын да онытты. Саксызрак атладымы, яшел үләнгә баскан аягы таеп китте һәм гәүдәсе артка чүкте. Куллары белән җиргә таянып калырга теләде, тик аны бу гына коткармады: җылыда озак торып корышып беткән чүгендер төсле гәүдәсе ярдан аска табан тәгәрәде.

Ул чокырга төшеп җиткәч кенә тәгәрәүдән туктады. Шактый озак, урыныннан кымшанмыйча, күккә карап ятты. Башта, Биктаһирны күргәч, чикы-чакы килгән саесканны күзәтте. Үзенә куркыныч янамаганны күреп, тегесе бераздан тынычланды. Саесканнан соң зәп-зәңгәр күк йө-

зендәге бияләй кадәрле ак болытка текәлде. Тургай сайравын ишеткәч, күзләре белән кырлар җырчысын эзләп табарга теләде. Тургай тавышы шулкадәр якында, аның баш очында гына ишетелсә дә, карт аны эзләп таба алмады.

Ахыр чиктә Биктаһир торырга уйлады. Тәгәрәп төшү тәэсиредер, аның бераз башы әйләнә һәм күңеле болгана иде. Егылмаска тырышып, түбәтәен үрелеп алып киде, ә таягы өч-дүрт адым читтәрәк ята иде, анысына барып тормады.

Нығрак бассам җир убылмасмы дигән төсле, сак кына атлап, Биктаһир өянкеләргә якынлашты. «Менә сез нинди икән, бәгырькәйләр! Рәхмәт, үсеп чыгарлык көч тапкансыз. Һәр агач та үз төбеннән яшь үрентеләр җибәрә алмый. Һәр егылган кеше дә тора алмый, нәселен калдырмыйча үлүчеләр дә бар. Анагыз өянкегә рәхмәт, сезгә дә рәхмәт, бәгырькәйләр. Безнең үрентеләр — балалар, балаларның балалары...»

Карт өшүдән исән калган калтыранган хәлсез бармаклары белән һәр өч кәүсәне дә тотып, капшап чыкты. Гүя ул шул рәвешчә агачларның чынлыгына ышанырга тели иде.

Вөҗданына мунча эзләп чыккан карт өчен шушы агачларны күрүдән дә зуррак нинди бәхет булуы мөмкин? Юк, алар агач түгел, кайчандыр кылган дуамаллыкны ярлыкаучы, бугазыннан кысып алган элмәкне авырттырмыйча бушатучы фәрештәләрдер. Сөенечтән Биктаһирның күңеле тулды, бугазыннан төкерәгә үтми башлады. Сулыш ала алмый башлагач, күлмәген аралап, чалбар кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып борынын сеңгерде.

Биктаһир инде җир белән тигезләнеп калган төп өстенә җайлап утырды һәм карашын өянкедән нибарысы дүрт-биш метр читтә үскән шайтан таягына текәде. Шайтан таягының чәчкәсенә кунган, бик тырышып бал эзләгән кортны күреп алды ул. «Шайтан таягында да бал булсын, имеш»,— дип үзе өчен ачыш ясады.

Кыйбла яктан талгын җил исеп куйды. Өянкеләрнең яфракларына шул да җитте: лепердәшеп, үзара сөйләшеп, күңелләрен бушатып калырга өлгерделәр. Шунда бер

яфрак өзелеп, һавада каз каурые сыман әйләнеп-тулганып торды да Биктаһирның түбәтәе өстенә килеп кунды. Биктаһир моны яхшы фалга юрады һәм яфракны өч бармагы киселү сәбәпле пистолетка охшап калган сул кулының уч төбенә салды. Бу яфрак та аның кулына охшаган: тамырлары бүртеп-бүртеп тора иде.

Үз һәм өянке язмышын күңеленнән кичереп карт бик озак утырды. Яфраклар лепердәве, чикерткәләр черелдәве, ниһаять, иксез-чиксез күктәге кояшның нәкъ аны иркәләргә җибәргән нурлары шулкадәр рәхәт изрәтә, аз гына черем итеп алмау гөнаһ саналыр иде. Моннан күп еллар элек буранда калгач та ул шулай изрәгән иде түгелме соң? Тик ул чакта көз азагы иде, салкын иде, көчле җил, кар иде...

Биктаһир тәненә гадәттән тыш җиңеллек, көч иңгәнен сизде. Үзен яшь чагындагы кебек хис итә башлады. Күзе ярым йомык иде.

Йокысыннан картны «Җигули»ның кычкырткан тавышы уятты. Биктаһир теләр-теләмәс кенә, күрә башлаган төшеннән аерылыр-аерылмас кына күзен ачты.

— Бабакай, хәлең ничек? — дип кычкырды Алмас, бабасының һаман да урыныннан кузгалмавын күреп.— Начарланып киттеме әллә?

Биктаһир ашыкмыйча гына урынынан торды. Тәнендә зур рухи канәгатьлек кичергәндәге сыман ныклык, җиңеллек сизде.

— Хәлләр әйбәт, улым. Берәр яшь киленчәккә өйләнмичә булмас,— дип шаяртып җавап кайтарды ул. Һәм, оныгын гаҗәпкә калдырып, күптән күрелмәгән җитезлек белән машинага табан атлады.

КОЯШ ЭЗЛӘҮЧЕ МАЛАЙ

Аһ, ул тауларның серлелеге! Күксел, зәңгәр төсләргә кереп, тирә-юньгә аерым бер мәһабәтлек, олылык биреп торалар. Болардан да биегрәк бер генә тау да юк әйләнәтирәдә. Бәлки, якында гына түгел, дөньяда да юктыр ан-

нан биегрәкләре. Равилгә шулай тоела. Ә Равил белә, ул инде зур малай, биш яшьтә.

Кайбер көннәрдә бу тауларга болытлар да килеп бәреләләр. Шуннан очкын чыга, яшен яшьни, күк күкри. Бабасы шулай сөйләде.

Ул таулар карап торуга ерак та түгел сыман. Әнә генә ич, кул сузымы җирдә генә кебек. Ә бара башласаң бик ерак. Ерак кынамы соң! Барган саен һаман артка чиккәндәй тоелалар алар.

Равилне бу тауларның биеклеге, зурлыгы, мәһабәтлелеге дә, зәңгәр рәшәгә төренеп, кайчагында кара, соргылт болытлар эчендә калган яшел сыртлары да ул кадәр чакырмый үзенә. Юк, бөтенләй кызыксындырмый дип әйтсәң дөрес булмас. Равил генә түгел, аның яшендәге теләсә кайсы малайның һәркемнән биегрәк менәсе килмиме дә, ул тауларны аркылыга-буйга иңләп йөрисе килмиме! Шулай да аңа тынгылык бирмәгәне бу түгел, бөтенләй башка нәрсә...

Равилнең әтисе язын-көзен тракторда, ә җәй көннәрендә комбайнда эшли. Әнисе — сыер савуда. Һәр икесе эштән өйгә кайтып кермиләр диярлек. Равилнең кайвакыт, бигрәк тә җәйләрен, әтисен атналар буена күрмәгән көннәре дә була. Би-ик сагына ул әтисен андый чакларда. Шуңа күрә бабасына ияреп ындыр табагына юнәлә. Ә ындыр табагында әтисе комбайныннан машинасы белән ашлык ташучы Мөдәррис абыйларының кырдан кайтканын көтеп алалар. Бабасы, кешеләр ишетмәсен дигән сыман, Мөдәррис абыйсының колагына гына әйтә:

— Син, Мөдәррис олан, безнең бу күзегәнне әтисе янына алып бар инде. Бераз эшләп кайтсын.

Эшләп кайтсын дип бабасының юри әйткәнен, шаяртканын белә Равил. Шуңа күрә елмая, рәхәтләнеп көлә. Үзенең ничек итеп комбайн йөрткәнен күз алдына китерә. Узган баруында, чын менә, әтисенең алдына менеп утырды да басуны әллә ничә әйләнделәр. Равил, штурвалга тотынып, әтисенә аны борырга ярдәм итте. Ул көнне кичкә

Күзегән — картларның «хулиган» сүзен бозып әйтүе.

таба бераз яңгыр сибәләп торганда күрә, этисе дә Равил белән өйгә иртәрәк кайтты. Ашап утырганда ул улының чәченнән сыйпап:

— Бүген, әнисе, улым килеп булышкач, тамчы да арымадым,— диде.

Равилнең, шунда ук йөгереп чыгып, бу хакта иптәш малайларына сөйлисе килгән иде. Юк, йөгереп тә чыкмады, сөйләмәде дә. Мактанчык икән димәсеннәр. Бары тик икенче көнне генә иң якын дусты Ниязга моны сер итеп әйтте. Аннан Наилгә, соңыннан Рөстәмгә!.. И кызыкты Нияз, и көнләште Наил, и күзләре очкынланды Рөстәмнең! Кемнең, кайсы малайның комбайн кадәр комбайнны үзе йөртеп карыйсы килмәсен! Андый малайны Караярдан көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Караярда гына түгел, күрше авылда да юктыр әле.

Эти-әнисе эштә, шуңа күрә Равилнең уеннан буш вакыты күбрәк бабасы белән уза. Алар бергәләп чебиләргә сөттә бүртерелгән тары ярмасы ашаталар, тавыкларга җим куялар, абзардан чыгуга ук артын сикертә-сикертә чабарга торган елтыр күзле кызыл бозауны муенчаклап ындыр артындагы үләнгә илтәләр һәм, еракка китмәсен, икмәккә кермәсен өчен казыкка бәйләп калдыралар. Аннан соң күптән түгел генә чыккан ике оя казның йоп-йомшак, сап-сары нәни бибиләрен су буендагы чирәмгә алып төшәләр. Озын муенлы башын горур тотып иң алдан, якын килгән һәр җан иясенә ысылдап ата каз атлый. Очраган бала-чага сизмичәрәк калса ул пычкы кебек тешле томшыгы белән авырттырып чеметеп алырга да күп сорамый. Аның артыннан ике ана каз титаклый, үзләренең барлыгы хакында «пип-пип» дип аваз салган соры йомгаклар тәгәриләр иде.

Су буена төшеп җитүгә бабасы, алып килгән иске ашъяулыкны яшел хәтфә өстенә җәя дә, икәүләп шуның өстенә сузылып яталар. Каз бәбкәләрен әнә шулай саклыйлар. Сакламасаң, яшь биби итен яратучы әшәке тилгәннәр әллә кайдан килеп чыга. Яр буе өянкеләре башында утырган каргалар да каз бибиләренә тыныч карый алмыйлар, чак

кына искәрмичә торсаң, ялт берәр бибине! Ә тилгән күренүгә Равил:

Тилгән, тилгән,
Бер бәбкәгә тилмергән.
Бер күзеңә яфрак,
Бер күзеңә туфрак,
Көш-ш! —

дип, такмакларга керешә.

Су буендагы рәхәтлекнең Равил өчен иге-чиге юк. Бабасы җәйгән ашъяулыктан ауный-тәгәри ничек итеп чирәмгә чыкканын сизми дә кала. Аның, кояшта янып, яр буендагы карасу-көрән бака кабырчыгы төсенә кергән тәненә йомшак бәбкә үләненең җиңелчә салкынлыгы килеп бәрелә. Бәбкә үләне бик эссе көннәрдә дә үзенең салкынлыгын саклый, шуңа рәхәт анда.

Бераздан Равил, әнисенә ияреп болынга чыккан иркә колын сыман шул чирәм-үләнлектә ауный-ауный да, сикереп торып, бәрәңге бакчасы башындагы кычытканлык янына бара. Аннан бабасына кычкыра:

— Бабай, санап тор! Мин ничә сәгатьтә йөгереп киләм?!

Равил әле хәзергә секунд, минут төшенчәсен белми, вакытны бары тик сәгатьләп кенә саный. Ә йөгерүен ул чынлап та шундый тиз йөгерә, Наилне дә, Ниязны да уза. Равилнең үзенә, йөгерә башласа, сабан туенда беренче килгән Кола айгырны да узар сыман тоела.

Аның бабасы яшь чагында атлы җайдак булган. Ат өстеннән кылыч болгап акларны ничек кырганнарын сөйләп җибәрсәме! Равил, Наилләр авызларын ачалар да калалар. Шулчак тыңлый-тыңлый үзеңне кылыч тотып ак дошман белән сугышып йөргәндәй хис итәсең, дөньяңны онытасың. Каз бәбкәләрен өянке башында сагалап утырган каргалар алып китсә дә, Равил сизми калыр иде, ләкин бабасы карт солдат шул: бер күзе каз бәбкәләрендә булса, икенче күзе карга, тилгәннәрдә. Кулларын бутый-бутый кызып сөйләп утырган җиреннән ул:

— Көш-ш, рәхмәт төшкерләре! — дип кычкырып җибәрә, каргаларга бармак яный. Соңыннан, берни булмагандай,

сөйләвен дәвам итә. Равил күңеле белән бабасы сугышкан җирләрне әллә ничә тапкыр урады инде. Аркылыга-буйга йөреп чыкты. Иң әшәке ак офицерның башын кылыч белән кисте, аның ярдәмчесен атыннан сөйрәп төшерде. Кайчак бабасы сөйләгәндә ишеткәннәре, кинода күргәннәре һәм үз фантазиясендә туган төрле маҗаралар кушылып, буталып бетәләр...

Бабасын бүлдерми тыңлый белә Равил. Кызык җирләрдә күзеннән очкыннар сибелеп куя куюын. Аннары ул бабасы сөйләп туктауга тотына сораулар яудырырга:

— Бабай, син ничә дошманны үтердең?

Бабасы авызында сакланып калган астагы бер, өстәге ике тешен күрсәтеп, кеткелдәп куя:

— Кем санаган инде аны,— ди ул ничәнче мәртәбә.

Равил белә: аның бабасыннан да батыррак, көчлерәк, кыюрак башка берәү дә булмагандыр. Көтмәгәндә зиһененнән бер уй чагылып уза:

— Ә дөньяда иң көчле кеше — Ленин! Бабай, әйеме?

Бабасы башын күтәрә төшә. Күзе әллә кояшта чагыла, әллә оныгына дикъкать беләнрәк карыйсы килә — маңгаена кулын күләгәләп ул Равилгә текәлә.

— Кем әйтте?

— Һы, беләм шул, бер малай әйтте.

— Кем соң ул бер малай?

— Белмим. Зу-ур малай. Быел мәктәпкә бара. Мин аны танымыйм. Ул Наилләргә Азнакайдан килгән.

Тора-бара алар башка нәрсә турында сөйләшә башлыйлар. Равил барысын да белергә тели. Әйтик, нигә эт «һау-һау» ди, ә мәче «мияү» дип кычкыра? «Волга»ның багына ничә литр бензин сыя? Нигә аның әтисе «Жигули» генә сатып алган?

— Нинди машина кирәк иде соң? — дип сорый бабасы.

— Гамил абыйныкы төсле кызыл машина. Янгын сүндерә торган.

— Нишләр иден ул машина белән?

Равил бабасына шуны да белмисеңмени дигәндәй караш ташлый:

— Аның, бабай, о-озын баскычы бар, беләсеңме? Ул

кычкыртса, әллә кайларга ишетелә. Безнең «Жигули»ның тавышы — бә-ә! Кәҗә тавышы.

Беркөнне Равил уйламаган-көтмәгән җирдән бабасыннан:

— Бабай, ә нигә төн була? — дип сорады.

Бабасы, күзен кыса төшеп, бер кояшка, бер оныгына карады.

— Һы,— диде ул аннан соң,— кояш баткач, төн булмыйча, ни булсын.

— Ә ничек бата? Суга батамы? Баткач ничек чыга? Аны кем чыгара?

Көтелмәгән сораудан бабасы аптырабрак та калды сыман.

— Бата дип... суга батмый инде ул, улым. Ә-әнә теге,— ул кулы белән зәңгәрләнеп торган тауларга ишарәләп күрсәтте,— әйе, әнә шул таулар артына барып ял итә.

— Ничек ял итә?

— Аягын салындырып утыра,— дип хәйләкәр көлемсерәде бабасы.

— Ә нигә йокламый?

— Бәлки йоклый да торгандыр...

— Кем аңа урын җәя? Әнисеме?

— Белмим шул, улым, минем анда барганым юк,— дияргә мәҗбүр булды көймәсе комга терәлгән бабасы.

Менә сиңа мә! Аның дөньядагы иң батыр бабасы, әллә кайларда сугышып йөреп тә борын төбендәге әнә шул тауны барып күрмәсен, имеш. Равил бабасына шикләнеп карады.

— Син шаяртасыңмы, бабай? — Ул алдамыйсыңмы дип сорамый, чөнки зурларның алдамаганнарын, бары шаяртырга яратканнарын белә.

— Чынлап, улым, барганым юк.

Бераз уйланып торганнан соң Равил, бер карарга килеп, катгый төстә әйтте:

— Ә мин барам анда! Ә мин кояшның ничек йоклаганын күрергә барам!

Менә шул көннән башланды Равилнең тынычсызлыгы.

Аларның авылында көтү кояш баеганда гына кайта.

Элегрәк Равил, кайтмый калган сарыкларны бабасы белән эзләп, кояшның ничек югалганын сизми дә кала иде. Хәзер, кич җитте исә, бар кайгысы кояшта. Берсендә хәтта коймага менеп күзәтергә булды, аннары, күрше Нәҗип абыйларының алмагачы комачаулагач, абзар түбәсенә үк үрмәләде. Әнә-әнә, кояш бөтенләй кызарып бетте, түм-түгәрәк күмәчкә әверелде. Буе җитә торган булса, Равил аны үрелеп сыйпап алыр иде. Ул үрелде дә бугай әле, чак егылып төшмәде.

Кызыл күмәч, бабасы күрсәткән таулар турысына җиткәч, кителә башлады. Күзгә күренеп кими барып, санаулы минутлар эчендә тәмам юкка чыкты. Шул урыннан баштарак яктылык сирпелеп торган иде, озакламый берни күренмәс булды. «Кояш күзләрен йомды, аның өстенә әнисе юрган япты,— дип уйлады Равил.— Ә йокыдан ничек тора икән? Кем уята аны?»

Кояшны якыннан бер генә тапкыр күрсәң иде! Их, ул тауда яшәүче малайларга рәхәттер. Кояш алар авылында йоклый ич. Ник аңа берәр тапкыр Караярда да кунып калмаска! Гел-гел таудагы малайларга гына димәгән лә!

Беркөнне аның бу теләге кабул булды. Тәгәри-тәгәри кояш Равилләрнең ишегалдына төште дә, сикереп, печәнлеккә менеп китте. Үзе Равилне дә чакырды:

— Әйдә, мен монда, икәү йоклыйбыз.

Равилнең кояш янына бик менәсе килә, тик ул печәнлектә тычканнар барын белә. Чөнки аларның йомшак песиләре Инбай нәни бәбиләр алып кайткан вакытларда печәнлектән көнгә әллә ничә тычкан тотып төшә иде.

Бит урталарын чокырайтып кызгылт-сары чырайлы кояш көлә:

— Ник менмисең? Куркасыңмы әллә?

Равил сер бирми:

— Һы, курыкты ди, курыкмаганны! Курыккан кушарлар.

Сарайга сөяп куелган баскычтан Равил башта түбәгә менде. Ә печәнлек түбәсе терәлеп үк тора — кучуе кыен түгел. Кояш аңа, кулын сузып, печәнлеккә сикерергә ярдәм итте.

— Син минем йоклый торган түшәгемне күрсәң иде,— диде кояш, әлеге тауларга күрсәтеп.— Теләсәң, яныма кунакка кил.

Тагын ниләр сөйләшкәннәрдер, Равил башкасын хәтерләми. Уянып китүгә беренче соравы шул булды:

— Баба-ай, ә кояш кайда?

Бабасы оныгының соравын үзенчә аңлады:

— Кайда булсын, улым, син йокы чүлмәгенең уянганын кем көтеп торсын. Кояш күптән үз эшендә инде. Әнә кара: кайда җиткән.

Равил йөгереп тәрәзәгә барды. Чыннан да кояш инде шактый югары күтәрелгән, дөньяга нурын сибә иде. Тәрәзәдән карап торган Равилне күргәч, елмайды да бугай әле.

— Баба-ай, ә мине кояш яныннан кем алып төште?

Оныгы күргән төш турында берни белмәгән бабасы шаяртып җавап кайтарды:

— Синең кебек зур егетне кем алып төшсен, үзең төштең. Шулаймы?

Кайсы малай үзенә «егет» дип зурлап эндәшкәндә, түгел дип, каршы килсен.

— Шулай.

Күпме генә көтсә дә, ничекләр генә теләсә дә, Равилләрнең печәнлегенә кояш бүтән төшмәде. Шуңа күрә Равил ул күрешүнең төшме, өнме икәнен аңлый алмый калды. Иптәш малайларына кояшның бер төнне аларның печәнлегендә йоклаганын сөйләгән иде. Нияз:

— Шыттырма! — диде.

Наил дә ышанмады.

Әй, ышанмасагыз ышанмагыз сана! Равилнең бик исе китте ди. Үзләренә кояшның килгәне юк, кунакка чакырганы юк, шуңа ышанмыйлар да.

— Ә мине... ә ул мине кунакка чакырды! Белдегезме?!

Малайларның күзләре маңгайларына менде.

— Кит!

— Булмас!

— Кояш сөйләшә дә белми әле.

— Син үзең сөйләшә белмисең! Сөйләшә. Үзем сөйләштем.

— Син урычча белмисең лә!

— Ә мин татарча сөйләштем.

— Сөйләштең ди сиңа, бар, сөйләш. Кояш ул, сөйләшсә дә, бары урычча гына сөйләшә!

— Кем әйтте?

Равилнең бабасы булса, Ниязның исә һәммәсен дә белә торган әбисе бар. Нияз күзен дә йоммый алдады:

— Әби әйтте.

— Һи, әбиең нәрсә белә ул! Минем бабайдан сора, ышанмасаң!

— Минем әбиме? Минем әби синең бабаңны чәнчә бармагы белән дә төртеп аудара!

— Аударды ди, аударган кушарлар, бар күтеп тор! Минем бабай аклар белән сугышкан!

— Сугышса соң! Ә минем әби...

Нияз нәрсә әйтергә белми торганда, Наил:

— Ә минем Камил абыем бар,— дип мактанды.— Әни әйтә, көз көне армиядән кайта, ди. Ул миңа күп-күп значоклар, солдат каешы, фуражка алып кайта. Тагы-ын... моряк киеме алып кайта. Үскәч, мин дә солдатта матрос булам.

Әле генә сугышыр чиккә җитеп бәхәсләшкән Равил белән Нияз шунда ук тынычландылар.

— Наил,— диде Равил,— синең значокларың күп булгач, берсен миңа бирерсең, яме. Ә мин сиңа, мин сиңа... пистолет бирәм. П-ух, тых, трах, пуф...

— Әй, минем пистолет бар!

Нияз алмашка «КамАЗ» тәкъдим итте.

— Минем «КамАЗ» бар.

Ахыр чиктә дуслар болай килештеләр: значокны Равил Мәскәүдән әтисе алып кайткан, чын утлар чыгарып ата торган автоматка, Нияз тимер «Конструктор»га алмаша. Ул «Конструктор»дан машина да җыярга мөмкин. Ә Наил икесенә дә бирәр значок өстенә абыйсының фуражкасын да киеп карарга биреп торачак, солдат каешын да буып йөрерләр.

Кояшны күрүе хакында сөйләгәч, иптәшләренең ышанмавы Равилгә көне буена тынгы бирмәде. Иртәгә ул беркемгә берни әйтмәс, торыр да кояш кайтып йоклый торган әнә шул серле тауга китәр. Кояшны эзләп табып, тагын үзләренә чакырыр. Әнә шунда Нияз белән Наилгә дә эндәшер. «Шыттырма!» Күрсеннәр, белсеннәр Равилнең ялган сөйләмәгәнен.

Равил төшендә тагын кояш белән сөйләште. Тик бу юлы кояш тау башында, ә Равил түбәндә иде.

— Син нигә мине уятмадың? — диде ул аңа, үпкәләп.

— Йоклый идең, йокың туйсын дидем.

— Ә мин озак йокламыйм. Печтек кенә күз йомып алам.

— Син зур үскән малай шул.

— Кояш абый,— дип эндәште Равил, ни өчен абый дигәнен үзе дә белмичә. Бәлки кояшка «апа» диярга кирәктер.— Наилләр синең безгә килүеңә ышанмыйлар. Печәнлектә икебез йоклаганга да, тычканнан курыкмаганга да.

— Мин аларга үзем әйтермен, ышанырлар.

— Син безгә тагын кайчан киләсең?

— Башта үзең кил, минем тавымны, йоклый торган җиремне күр. Аннан соң сезгә барырмын.

Равил йокыдан торганда кояш тагын югары күтәрелеп өлгергән иде. Ул, күзләрен челт-челт итеп йома-йома, кояшка озак карап торган иде, нәрсәдер аның борын эчен кытыклады. Равил читкә борылырга да өлгермәде, ишегалдын яңгыратып, төчкереп җибәрде.

— Әп-те-чи!

Бабасы сипкән арпа бөртекләрен кырт-кырт килеп чүпләп йөргән тавыклар, куркышып, як-якка сибелделәр. Кайберсе койма башына яки сәндерәгә үк кунаклап, кызыл кикрикле башын әле уңга, әле сулга борып карады. Берничәсе баскыч астына кереп качтылар. Әллә Равилгә, әллә юктан-бардан да курыккан тавыкларга ачуланып, саргылт этәч җирне тырный башлады. Үзләре телендә титибикәләргә нидер әйтүе булды, тегеләре аның янына йөге-

решеп килеп тә җиттеләр. Һәм, яраргa тырышып, тирәсендә сырпаланырга керештеләр.

Равил ипи өстенә каймак һәм варенье ягып, шуны иртән сауганнан соң әнисе сөзеп калдырган сөт белән ашагач, бабасына дәште:

— Бабай, мин киттем!

Йокымсырап яткан бабасы кая барасын да сорап тормады. Беренче тапкыр чыгып китүе түгел лә! Сыңар күзен ача төшеп:

— Бар, улым, бар. Сак йөрергә тырыш, машина юлында уйнама,— дип әйтү белән чикләнде.

Кирәге чыга-нитә калса дип Равил кесәсенә бер телем ипи дә кыстырды. Бүген ул кояшны күреп сөйләшмичә кайтмаячак!

Су буена төшкәндә Равилне күрше Нәҗип абыйларының эте Акмуен куып җитте. Куып җитте дә салкынча борынын аның кулына төртте. Миңа да синең белән барырга ярыймы, янәсе.

Акмуен белән Равил күптәнге дуслар. Акмуен ит ярата. Шуңа күрә Равил, өлкәннәргә күрсәтмичә генә (күрсәләр рөхсәт итмиләр), аштан үзенә тигән өлешне кайвакыт эткә бирә.

Акмуен кызыл телен чыгарган да Равилнең күзләренә карый иде. Әйдә кузгалыйк, кая барабыз, дип әйтергә тели ул. Анысын гына аңлый Равил.

Иптәшкә Акмуенның иярүенә Равил бик шатланды. Акмуен шундый акыллы эт — аның белән кояш эзләп кенә түгел, әкияттәге Каф тавы артына да китәргә мөмкин.

Наил белән Ниязга юри әйтмәде Равил. Алар аңа ышанмадылар, көлделәр ич. Көлсеннәр, әйдә, ышанмасыннар. Ә хәзер ул Акмуен белән ә-әнә теге биек тауларга барачак. Барачак та...

— Акмуен, киттек!

Шушы әмерне генә көтеп торган эт, кызыл телен асылындырып, алга ыргылды. Әмма ул ерак китмәде, бераз баруга туктады һәм, борылып, артына карады. Бу аның, дөрес бараммы дип, бер яктан үзен тикшерүе булса, артта калмыйсыңмы дип, дусты турында кайгыртуы да иде.

Тар инешне Равил басмадан, ә Акмуен су аша йөзеп чыкты. Коры җиргә басуга, эт тәнен шундый итеп калтыратты ки, йонына эләккән су тамчылары, чәчрәп, як-якка сибелделәр. Кыска гына бер мизгелдә Равилнең күзенә хәтта салават күпере күренеп алды.

Су буйлап сузылган авыл урамын кисеп чыгуга, дуслар Сары тауга күтәрелә башладылар. Сары тау авылга орынып ук тора, үзе биек тә түгел. Уйсурак урыннарда язгы ташу һәм яңгыр сулары, җирне ашап, чокыр ясаган. Тау кырласыннан көтү йөреп киртләч-киртләч сукмак салып бетергән. Әле дә ике бәрән иярткән кәҗә, алгы аяклары белән ташка басып, муенын сузып сукмак аръягындагы үләнне чемченеп тора иде. Йөгереп уйнап йөргән бәрәннәр һәм карт кәҗә яныннан Акмуен тыныч кына үтеп китә алмады. «Һау!» дип бер өргән иде, кәҗә бәрәннәре икесе тиң туп кебек өскә ыргылдылар. Әниләре, очлы мөгезләрен Акмуенга төбәп, сугышырга хәзерләнде. Ләкин маэмайдан куркыныч янамавын күреп шунда ук тынычланды.

Сары тау артында тагын бер тау бар. Анысы — Кызыл тау. Кызыл тау белән Сары тауны Равил кибетче Кадрия апасының ияк астына охшата. Аның ияк асты да шулай икегә бүлтәеп тора бит.

Тау өстендә өч җирдә өч көтү йөри. Аларның берсе Равилләр очыныкы. Әнә, әнә ич көтүче Ансар абыйсының кечкенә гәүдәле йонлач эте сарыклар куркыту белән мәшгуль. Парин исемле эт ул, Равил белә. Паринны күрүгә Акмуен аның янына китте. Ике эт ниләр сөйләшкәннәрдер, борыннары белән бер-берсенең яңагына, корсагына төртә-төртә бераз тордылар да, Акмуен кире килде.

Равилнең күңеле сизә: әгәр дә ул кырда берьялгызы өлкәннәр күзенә чалынса, аны кая барасың, нишләп йөрисең, кемнән сорап чыктың кебек сораулар белән аптыратып бетерәчәкләр. Өлкәннәр беләмени ул синең сереңне! Беләләрмени алар синең кояш эзләп баруыңны!

Шуңа күрә Равил Айбалык чокырына, челтерәп чишмә аккан җиргә төшәргә булды. Монда аларны беркем дә күрмәс. Күрмәсеннәр дә!

Чокырга Акмуен Равилдән күп алда төшеп җитте. Төш-

те дә таштан-ташка сикерүче юлдашына карап торды. Гүя кисәтергә теләде: егыла күрмә, монда текә. Тик Акмуенның сүзсез кисәтүен Равил әллә аңламады, әллә аңлап та саксыз кыланды. Төшеп җиткәндәрәк кызыл балчык өстендә дымланып яткан ташка сикергән иде, таеп китте дә арты белән балчыкка егылды һәм аска кадәр шуып төште. Терсәгенә, кыска балаклы ыштанына, күлмәгенә үзле кызыл балчык сыланды. Ярый әле озак шуарга туры килмәде — чокыр төбе ерак түгел иде.

Чокырда егылуның бер рәхәт ягы бар: монда сине беркем күрми. Равил салкын чишмә суында башта кулына буялган кызыл балчыкны юды. Аннан соң, сандалиларын салып, бөтенләй чишенеп ташлады да киемнәрен юарга кереште. Акмуенга рәхәт, аның бер җире дә пычранмаган, ул чишмәдән су гына эчте. Ә Айбалыкның суы салкын, ул Равилнең кулын өшетә, ләмгә батып торган аякларына да салкынча иде. Салкыннан аның күкрәге, беләк тирәләре каз тәне белән капланды.

Сандалиларының эченә тулган балчыгын кырасын кырып, кагасын кагып кигәч, Равил чокыр эчендә челтерәп агып яткан үтә күренмәле чишмә инеше янәшәсендәге сыерлар күп йөреп таптап бетергән сукмактан агымга каршы атлады.

Айбалыкның ярлары урыны-урыны белән сөзәк, чирәм белән каплаган, урыны белән текә, хәтта куышланып ук тора иде. Андый урыннарда яр коточкыч зур авызын ачкан аждаһаны хәтерләтә. Менә-менә аждаһа авызыннан төтен, ялкын сибелә башлар сыман тоела Равилгә.

Кояш инде шактый югары күтәрелеп өлгергән, үзенең кечкенә дустын җылыта, иркәли, йомшак нурлары белән аның беләкләрендәге каз тәнен эретә сыман иде. Равилнең күңеле күтәрелеп китте, шуңа күрә кызурак атлый башлады.

Хәзер инде чокырдан чыксаң да ярый. Көтүләр ерак калды, ә авыл күренмәс булды. Берәрсе очрап туктатыр да авылга борып кайтарыр дип куркасы калмады.

Кинәт каяндыр әче итеп сызгырган тавыш ишетелде. Равил куркып калды, ә Акмуен томырылып шул якка таба

чабып китте. Анда ике арт аягында басып торган йомран күренде. Зур йомран, үртәгәндәй, тагын бер сызгырып, Акмуен килеп җиткәнне генә көтте дә өненә кереп чумды. Маэмай өнгә башын тыгарга да тырышып карады, ал аяклары белән җирне казымакчы да булды — ташлы балчыкны казу уен эш түгел шул.

Чокырдан Зәңгәрәй тавы күренми иде, ә моннан ул уч төбендәге сыман күз алдында. Әнә, әнә генә ич! Равилгә ул тауларга инде бик якын калган шикелле тоелды. Акмуен белән хәзер барып җитәчәкләр. «Барыбер барып житәм, җитәм!» — дип кабатлады ул, үҗәтләнеп.

Алдагы юллары да кечкенә үрләр, уйсулыклар һәм артык тирән булмаган чокырлар аша иде. Өлкәннәр монда авыш урын дип тормаганнар, нидер чәчкәннәр, ә бер урында кап-кара итеп сөрелгән җир иде. Равилләр хәзер игене урылган басудан баралар. Мондагы салам эскертләрен ул таныды, бу арышны Равилнең әтисе урды ич. Аның бирегә килгәне, комбайнга утырып йөргәне бар. Кайдадыр басу аркылы уза торган юл да булырга тиеш, тик Равил аны эзләп тормады, камыл аша турыдан атлый бирде.

Камыл ерып атлавы малайга да, эткә дә җиңел түгел. Кыска камыл чыбык кебек каты, аяк балтырын тырный, Акмуенның йомшак табан астына кадала иде. Тик Равил авыртса да, игътибар итмәскә тырышты. Кулын авырттыргач та еламады әле ул. Зур яшел чикерткә сикереп кунган җирне уч төбе белән шапылдатып каплаган иде, чикерткә качып өлгерде, ә Равилнең уч төбеннән, камыл кадалган җирдән, кан саркып чыкты. Уч төбе әрнегәч бик елыйсы килгән иде, тик кызганыр кешесе булмагач еламады. Малай башың белән эт янында балавыз сыгып торсаң, эт түгел, бая өненә кереп качкан йомран да көләр үзеннән.

Равил ымсындырып, чакырып торган Зәңгәрәй тавына туп-туры барырга тырышса, Акмуен турыдан гына атлый белми: әле аяк астыннан гына пырхылдап очып чыккан берәр кош артыннан ташлана, әле нәрсәдер эзләп еректан урап килә. Берәр җан иясе барлыгын тоядырмы, экрен генә барган җиреннән томырылып чабып китә, комбайн

төшергән салам төпләрендә иснәнә, тиктомалдан җирне казырга керешә иде.

Камылны узып, яшел чирәмгә аяк басуга, Равилгә шулкадәр рәхәт булып китте, ятып аунамыйча түзә алмады. Аунады-аунады да чалкан ятып калды. Койрыгын болгый-болгый карап торган Акмуен да янына йөгереп килде, аның битен ялап алды. Эт ул теләсә кемне яламый, теләсә кемгә сырпаланмый, бары тик яраткан кешеләренә, дусларына гына шул рәвешле якын итүен белдерә.

Кояш инде төшлекне узган, ә Зәңгәрәй тавы әле һаман ерак иде. Ашыгырга кирәк. Равил торып басты, арыганлыгы онытылды,

— Акмуен, әйдә!

Алар йөгереп үк киттеләр. Равил бик тырышса да маэмайны уза алмады. Эт аны узып китә дә туктап көтеп ала, аннан тагын чаба, тагын туктап көтә. Хәзер инде Равилнең кая таба барасын ул да чамалый бугай, юнәлешне гел Зәңгәрәй тавына турылый иде. Күп йөрүдән Равилнең эчен кату алды, сулышы кысыла башлады, ә эт уйламый да, телен салындырып чабуын белә.

Бервакыт дөнья караңгылана башлады. Равил күккә карады: кояшны болыт каплаган икән. Әнә ул, зур мөгезле сөзгәк сыер кыяфәтендәге ак болыт, кояшны Равилдән яшермәкче була. Кояш нурлары аңа буйсынмаска, әле тегеннән, әле моннан Равилгә елмаеп, сөзгәк сыердан котылырга телиләр сыман.

Кояш ишетсен дип Равил кычкырып такмакларга керешТе:

Эт кояшы, тегеләй кит,
Тәтәй кояш, болай кил!

Ишетте аның соравын, ишетте Кояш! Ак сыердан котылып, Равилгә дусларча җылы сәламен җибәрде.

Бераздан Равил карыны ачканын тойды. Моның ише чакта әнисе «үтереп-үтереп ашыйсы килә», ди торган иде. Ни өчен алай әйтә икән?

Әнисе исенә төшүгә ул өйләрен күз алдына китерде. Алар инде төшкелекне ашаганнардыр. Бабасы белән әни-

се Равилне эзләгәннәрдер: кая барасын әйтми китте бит. Әйтәсе калган. Ә әйткән булса, мөгаен, җибәрмәсләр иде. Хәзер, аны тапмагач, борчыла торганнардыр. Әллә кире борылыргамы? Юк, кояшны тапмый торып ул өенә кире кайтмаячак. Озак йөргән өчен әнисеннән каеш эләгәсен дә беләә. Хәер, әнисе бит каеш белән куркытыр өчен генә селтәнә, авырттырырга тырышмый. Улы шуны сизми дип уйлый ахрысы.

Ул кесәсеннән ипиен алып ашарга керешге. Моны сизенгән Акмуен дустының аяк арасында буталырга тотынды. Равил телемнең яртысын сындырып өскә чөйде:

— Ал!

Әлсерәп йөргән Акмуенда андый җитезлек кайдан табылгандыр: туп кебек атылып, ул, ипи җиргә төшкәнче үк, авызы белән эләктереп тә өлгерде.

Көннең кызуы кими төште. Кояш шактый түбәнәйде, тауларга якыная башлады. Ул тауга төшкәнче Равил анда барып өлгерерме? Караңгы төндә таныш түгел бу ике тау арасында берьялгызы калмасмы?.. Мондый уйлардан аның тәне чымырдап куйды, күз алдына әллә нинди куркыныч җанварлар, бөҗәкләр килде. Әгәр елан очраса? Кызыл калфаклы кызның юлында сагалап торган төсле каршысына бүре килеп чыкса? Равил елап җибәрер хәлгә җитте. Күзеннән яшь тә тәгәрәр иде бәлки, маэмае кинәт һау-һаулый башлады. Нindидер кошны куркыткан икән, тегесе пырхылдап күккә күтәрелде һәм, күреп калыгыз дигәндәй, баш ачында бер әйләнде дә кояш ял итәсе тауга китеп күздән югалды.

Үзәнлеккә төшеп җиттеләр. Ашаганнан соң Равилнең бик эчәсе килгән иде, ул буралап куелган чишмәнең улагы янына тезләнде дә бите белән суга капланды. Су салкынын тоюдан аңа шулкадәр рәхәт булып китте ки, тамагы бик кипсә дә ул ашыкмыйча, озаклап эчте. Ә астарак, чишмә суы сазлыкка таралган җирдә, Акмуен рәхәтләнә. Ул чыланып һәм пычранып өлгергән иде.

Шул чакта Равил якында үскән камышлар арасында тырпаешып утырган җикәннәрне күрде. Алып кайт дип әтисенә күпме әйткәне бар. Тик әтисе һаман вакыт таба

5*

алмый иде. Менә хәзер үзе алып кайтыр, өйдәгеләрне шаккатырыр әле!

Камышлар тирәсендә баткаклык иде. Равил аны-моны уйлап тормады, бер түмгәккә басты, икенчесенә сикерде дә таеп китте. Ике аягы да тез тиңентен салкын сазга баттылар. Аның борынына сасы ис килеп бәрелде. Тиз генә тартып алам дисә дә саз аякларны җибәрмәде, Равил шуннан соң корсагына ятты, кулы белән үзе бая баскан түмгәккә үрелде һәм сарутка тотынып бар көченә тартылды. Аяклары, ниһаять, урыннарыннан куптылар. Аннан соң да әле аларны тәмам сөйрәп чыгарганчы Равилгә озак мышнарга туры килде. Акмуен исә янына килеп, эчкерсез карашы белән аңа төбәлгән иде.

Котылганына куанып аягына баскач кына Равил сандалиларының аягында юклыгын сизде. Сазлык йоткан. Сазлык, җикәнен алырга теләгән өчен, Равилгә ачуланган. Инде анда керергә, сазлык йоткан аяк киемнәрен эзләргә кыюлыгы җитмәде. Исенә тагын әе, әтисе, әнисе, бабасы төште һәм, үзе дә сизмәстән, ул мышык-мышык борынын тартырга керште. Равилгә буйсынмыйча аяклары да сыгылып төштеләр һәм ул чирәмгә чүгәләде.

Ул утырган арада кояш, Равил сандалисыз калды дип тормады, гаепле төс белән соңгы тапкыр елмайды да зәңгәр тау артына кереп китте.

«Бик тә ерак икән бу Зәңгәрәй тавы,— дип уйлады Равил.— Ә мин аңа барыбер барам әле!» — диде ул, үҗәтләнеп.

Чишмә янында бүтән юанмыйча ул кояш нурлары алланып күренгән биеклеккә таба кузгалды. Тауга менү — төшү түгел иде шул. Көне буена да туктап тормаган аяклары хәлсезләнгән, аяк астындагы ташлар аның өрфия калынлыгы тиресе аша табанын авырттыралар иде. Менә ул очлы нәрсәгә басты, авыртудан:

— Ой! — дип кычкырып җибәрде.

Аны куркуга салып төрле яктан: «Ой! Ой!» — дип кабатлаган авазлар яңгырады. Таулар җибәргән кайтаваз икәнен белмичә Равил як-ягына каранды. Якында беркем дә күренмәде. Бары тик куркыныч зур канатын җилпеп

бер кош очып узды. Бу кошның бары тик ябалак икәнен Равил шулай ук белми иде. Кемгә таянырга, кемгә барып сыенырга? Малай алданрак атлаган этнең муенчагыннан тотып алды һәм инде аны ычкындырмады. Ни генә әйтсәң дә, икең бергә булганда ышанычлырак шул.

Кичке салкын төште. Равилнең шәрә беләкләре, балтырлары аша ул бөтен тәненә үтеп керә. Шуның өстенә ялгызлык куркыта иде. Тәмам караңгыланды. Инде берни күренми, ул ике тау арасындагы тар сукмактан Акмуенга ияреп атлый бирә. Ләкин хәтеренең кайсыдыр төше аңа нәкъ менә шул юнәлештә атларга кирәген гел искәртеп тора. Выжылдап очкан коңгызларның кайберләре битенә, маңгаена килеп бәрелә, каршыдан һәм ян-яктагы урман эченнән шомлы авазлар: кемнеңдер ыңгырашканы, уфылдаганы ишетелгәндәй тоела.

Ниһаять, алар тауга менеп җиттеләр бугай. Тәмам хәлдән тайган Равил бер ташка килеп утырды. Көн дәвамында зур таш шулкадәр кызган булган, хәзер дә Равилгә җитәрлек җылысы сакланып калган.

Ташның киртенә тәхеткә утырган патша малае кебек урнашкан Равил як-ягына каранды: кайда соң аның кояшы? Нишләп күренми ул? Әллә бабасы ялгыш әйткәнме? Юк, бабасы ялгышмас, чөнки Равилнең тау артына кереп киткән кояшны күпме тапкырлар карап торган бар. Бүген дә күрде. Кайда соң ул шулай булгач?

Малайның кинәт: «Кояш абый, син кайда?» — дип кычкырасы килде. «Кояш» сүзен әйтергә өлгермәде, як-яктан:

— ...яш-яш-яш! — дигән кайтавазлар ишетелә башлады. Ул, куркудан бөрешеп, тотлыгып калды.

Ташның җылысы рәхәт изрәтә, аның тәнен нидер баса, күз кабаклары авырайганнан-авырая бара иде. Бирешмәскә теләп соңгы көчен җыйды, күзләрен авырттырганчы киереп як-якка каранды һәм шатлыгыннан чак кына кычкырып җибәрмәде: каршындагы агач арасыннан яктылык саркылып чыга иде. Әлбәттә, әлбәттә кояш шунда! Бүтән тагын кайда булырга мөмкин?! Бабасы дөрес әйткән. Әнә ич: тавышлар да килә. Трактор тавышын Равил танымый димени! Тагын бер тавышны таный ул:

тимер тавышын. Торбага тимер белән бәргәндә шулай ишетелә. Үзенең дә бәреп уйнаганы бар. Ә ыңгырашкан тавыш кайдан чыга, анысы кемнеке — бусы табышмак, белми. Иң куркынычы әнә шул тавыш.

— Ыу-охо-о-ы!

Никадәр генә куркыныч булмасын, Равил анда бармый, кояш абыйсын күрми калмаячак. Тик менә, тик менә бераз гына утырып тора да, бераз гына хәл җыя да, печтек кенә, бармак башы хәтле генә ял итә дә...

Кояш Равилнең каршысына чыкты.

— Исәнме, килеп яхшы иткәнсең.

— Исәнме,— малай үзенең кечкенә, салкынча кулларын кояшка сузды. Кояшның куллары йомшак, җылы, рәхәт иде.

— Туңгансың,— диде кояш, Равилнең кулын сыйпап.

— Юк, печтек тә туңмадым.— Үзе кояшка һаман ныграк елыша бара. Әллә кояш та Акмуен сыман йонлы инде?

— Ничек мине эзләп таптың? Арыгансыңдыр.

— Арымадым,— диде малай.— Тик өйдә әниләр генә белмиләр синең яныңа киткәнне.

— Әйтәсең калган.

— Болай озак торасымны белмәдем шул...

Кояш ниндидер кара-соры төскә кереп, юкка чыкты. Аның йонлач тәненнән калган җылы да озак сакланмады.

Нәни дусты таш өстенә сыгылып төшкәч, Акмуенга да аның янына килеп ятудан башка чара калмаган иде. Эткә дә бит янында кеше булуын, аның җылысын тою рәхәт. Ләкин ул — эт. Эт нинди хәлдә дә этлеген онытмаска тиеш. Бу очракта Акмуенның бурычы — ярдәмчесез калган дустын зур, көчле кешеләр кулына тапшыру. Ничек кенә булса да!

Торасы килмәсә дә торды Акмуен малай яныннан. Борынын киерә төшеп иснәде. Сизгер борыны күптән таныш булган куян, тычкан исен, ул белгән һәм белмәгән башка исләрне тоеп алды. Кайдадыр якында тагын бер ис — йөз мең еллар элек аның ерак бабалары сиену эзләгән кеше

исе дә килергә тиеш. Бу исне сизәр өчен Акмуенга малайның якынлыгы комачаулый... Шуңа күрә аңа читкәрәк китәргә кирәк иде.

Урман аша күренгән утлар ягына таба карап беразйөгергәч Акмуен борынын сузып тагын бер иснәде. Этлек инстинкты аны алдамаган икән: тавышлар ишетелгән яктан ул чак-чак кына сизелерлек кеше исен тойды. Һәм, тоемлавының хаклыгына ышангач, игелекле җан иясе агачлар аша өметләндереп күренгән утларга табан әкрен генә юыртып китеп барды.

Төшке аш вакытында эзләп-эзләп тә таба алмагач Равилнең әнисе каенатасына әйтте:

— Син, әткәй, ул малайга катырак була күр инде. Теләсә кайда коры-сары ашап йөреп ашказанын боза бит ул бала. Гастрит белән үземнең гомер буена җәфаланганым да җиткән.

Сүз шуннан артыкка узмады. Табылыр, кая китсен ул. Уен белән мавыгып, дөньясын оныткандыр дип тынычландылар. Инде кичкә таба да кайтмагач пошаманга төшеп, авылны күтәрделәр. Су буйлары, чокыр-чакырлар, силос базларын тикшерделәр. Ләкин Равилне күрүче-белүче табылмады, җир йоткандай, ул юкка чыккан иде.

Караңгы төшкәндә бу хәбәр район эчке эшләр бүлегенә барып житте. Кем белә, бәлки, берәр машинага утырып, кая да булса авылдан читкә чыгып киткәндер.

Эчке эшләр бүлегендә хәбәрне санаулы минутлар эчендә күрше-тирә районнарга, Казанга ирештерделәр. Хәзер инде Равилнең яше, төсе-бите, киеме, аерым билгеләре, хәтта сул як калак сөяге өстендәге кара миңе барлыгын да бик күпләр беләләр иде. Белүен беләләр, ләкин югалган малайның әти-әниләрен борчылмагыз, табылыр, дип тынычландырудан башка чарасызлар иде.

Утларга карап бара торгач Акмуен урманның аръягында урнашкан вышка янына килеп чыкты. Көчле яктылык күзенә китереп бәрдеме, ул тукталып калырга мәҗбүр булды. Чөнки мондый көчле прожекторны да, ыңгыраша-

ыңгыраша эшләгән бораулау вышкасын да аңа үзенең барлы-юклы гомерендә күрергә туры килгәне юк иде. Яшәгән дәверендә алган тормыш тәҗрибәсе тумыштан килгән үз-үзен саклау инстинкты белән кушылып аны кисәтте: сак булырга кирәк. Кешеләрнең дә төрлесе бар. Дөресен генә әйткәндә, Акмуен хәзер монда керүгә караганда, төне буе урманда йөрүне артыграк күрер иде. Тик ул нинди генә хәлдә булмасын, урманның икенче читендә таш өстендә ятып калган кечкенә дусты барлыгын бер генә минутка да исеннән чыгарырга тиеш түгел.

Шуны тою Акмуенга кыюлык, үзендәге куркуны җиңәрлек көч бирде.

Буровойда эшнең тыгыз чагы иде: колонна күтәрәләр. Торбаларны күтәрү куәтле двигательгә дә уен эш түгел. Ул колак тондыргыч тавышлар чыгарып көчәнә, уфтана, ыңгыраша. Эш белән мавыккан бораулаучылар мәйданчыкка килеп чыккан этне күрмәделәр дә.

Акмуен уйга калды: нишләргә? Яннарына барсаң, торба бәрүе яки берәрсенең аяк астында калуың бар. Ләкин Акмуен чарасын тапмый кала торган этләрдән түгел иде. Ул двигательнең улавы кимегән чакны чамалап торды да бар тавышына өреп җибәрде. Бу аның бик әһәмиятле хәбәр алып килдем, игътибар итегез диюе иде.

Беренче өрүендә ишетүче, борылып караучы булмады. Акмуен тагын да көчлерәк итеп өрүен кабатлады. Тик бу юлы аның өрүе авыр, калын торбаны стеллажга салган чакка туры килде. Металл чыңы аның тавышын күмеп кенә калмады, колак тондыргыч бу ят чинауның металл чыңы гына икәнен, аңардан курыкмаска кирәген аңламаган эт кырыйга сикерде һәм яңарак кына үзе кергән ачыклыктан тышка атылды. Башта урман эченә үк элдергән иде дә, артыннан куа килүче юклыгына ышангач, кире борылып, яктылык белән караңгылык кисешкән ноктага җитәрәк туктап калды. Аннан арт аякларына утырып буровой ягын күзәтергә кереште.

Буровой әледән-әле ыңгыраша, яңарак кына Акмуенның котын алган чыңлау авазы да кабатланып тора иде. Кызыксынуын тыя алмыйча эт якынрак килде. Хәзер инде

ул бу тавышның кайдан, нәрсәдән, ни сәбәпле чыкканын төшенде булса кирәк. Монда иң беренче якынайгандагы кыюлыгы кире кайтмаса да, кыяр-кыймас кына бораулаучыларга таба һаман шуыша барды. Кинәт җирне дер селкеткән буровой тынып калды. Бораулаучыларның ялга туктаулары иде бу. Тавышка инде күнегеп килүче Акмуен, колакларына ышанмыйча, аларны селкетеп алды. Барысы да дөрес, хак икән. Хәзер ул нишлисен белә. Минут эчендә этнең куркуының, кыюсызлыгының эзе дә калмады. Урыннарыннан кузгалырга өлгермәгән бораулаучылар арасына килеп керде дә:

— Һау-һау! — дип аваз салды.

Бу юлы инде бораулаучылар сискәнде.

— Бүре! — диде берсе, тимер кисәгенә үрелеп.

— Курыкканга куш, койрыгы белән биш,— дип көлде анардан икенчесе.— Этне бүредән аермаган башың белән ничек бораулаучы булып йөрисең син?

Бораулаучылар дәррәү көлеп җибәрделәр. Аларның көлүеннән Акмуенның тәненә рәхәт дулкын йөгерде. Бу кешеләрнең әйбәтлегенә, арыган-талган дустын коткарасыларына җаны-тәне белән ышанды ул. Тик аларга якында, урман аръягында гына йоклап калган малай хакында ничек аңлатырга? Ничек шунда алып барырга? Акмуен әле берсенең, әле икенчесенең күзләренә карап чыкты. Их,. ул да кешеләр телендә сөйли белсә икән! Юк, сөйли белми шул. Акмуенда беренче тапкыр дөньяга эт булып тууына, кешеләрчә сөйләшә алмавына үкенү хисе туды. Шул хистән күзләренә моңсулык тулды. Этләр телендә аның белмәгәне юк, сәмәй көчекләргә генә түгел, бульдог, овчарка, эрдельтерьер кебекләргә дә сөякнең тәме турында да, яңарак киптерелгән печән өстендә йоклауның рәхәтлекләре һәм төннәрен йортны ничек сакларга икәне хакында да — кыскасы, этләр дөньясының маҗараларга бай һәм кызыклы тормышы хакында теләгән кадәр сөйләр, кирәксә дәрес тә бирә алыр иде ул. Ә монда кешеләр телендә:

— Анда минем дустым калды, ярдәм итегезче! — дип, нибарысы алты сүз әйтергә кирәк. Шуны да әйтә алмый.

Аптыраудан ул, аякларын күтәреп, сыртына ятты һәм кызганыч тавыш белән шыңшып җибәрде.

Бораулаучыларның өлкәнрәге:

— Аягыңа шырпы кадалдымы әллә, мескенем? — дип, Акмуенның аякларын карады. Акмуен карышмады.

— Габдулла абзый, аның ашыйсы килгәндер,— диде башта этне бүре дип уйлаганы.

— Ә кайдан килеп чыкты соң ул?

— Кайдан булсын, якын-тирәдәге берәр авылдандыр.

— Син ни сөйлисең, Гамил энем? Иң якын авылга да моннан сигез-ун чакрым бардыр.

— Кыргыйлашкан эт түгел микән?

— Кыргый эт монда кермәс. Әнә муенчагы да бар. Әйдәгез, ашарына биреп карыйк. Бәлки чыннан да ачыккандыр. Маһ-маһ!

Үзен аңладылар дип куанган Акмуен алдан чыкты һәм урман ягына табан юнәлде, әмма, артыннан иярүчеләр күренмәгәч, туктарга мәҗбүр булды.

— Маһ, маһ! Монда кил, монда кил!

Теләмәсә дә, Акмуен кабат кешеләр янына килде. Тәлинкәгә этнең селәгәйләрен агызырлык тәмле сөякле, итле ботка салынган иде.

— Ашасана!

Бораулаучылар әйтерсең эш турында онытканнар, бөтен игътибарлары көтелмәгән җирдән табышмак булып килеп чыккан шушы эткә күчте. Ләкин Акмуен, аларның кыстауларына һәм бик ачыккан булуына да карамастан, боткага борынын да тигезеп карамады. Ул, чинап, тагын бер-ике адым урман ягына атлады, туктап, тагын кешеләр ягына карады. «Ничек инде аңламыйсыз?» — ди иде аның карашы. Күзләреннән яше тәгәрәп төшәргә җитте. Әгәр кешеләр хайваннарның телен белсәләр икән! Ә бораулаучылар, табышмакны чишә алмыйча, аптырашып тора бирделәр.

Акмуен тагын борылып килде. Бу юлы Габдулла агайның аякларына сырпаланып кына калмады, тешләп брезент чалбарыннан тартты.

— Егетләр, бу эт безне каядыр чакыра түгелме? — ди-

де Габдулла агай.— Ашамый да, һаман урман ягына каера.

— Төн уртасында урманда нәрсә бардыр дисең?

— Урман бит ул, анда ни булмас...

Акмуен һаман Габдулланың балагыннан тартты.

— Юк, егетләр, тикмәгә түгелдер бу. Теле юк бит мескенкәйнең. Булмаса, без карап карыйк, нәрсә күрсәтмәкче икән. Барыбыз да йөрмик, Хәсән, ал фонарьны үзең белән.

Хәсән дигәне, культбудкага кереп, фонарь алып чыкты.

— Калганнарыгыз ашый торыгыз, без озакламый кайтырбыз.

Кешеләрнең үзен аңлауларын Акмуен күңеле белән сизде. Ул ике-өч адымга алданрак бара. Арттагыларның аяк тавышын җаны белән тоеп атлый. Тик туктап кына калмасыннар, кирегә генә борыла күрмәсеннәр!

Күктә ай калыкты. Дөньяны сөт белән күмделәрмени. Ай нуры киң ябалдашлы каеннарның, усакларның шәүләләрен нинди генә кыяфәтләргә кертми. Әле ярый Акмуен — эт. Этнең дә батыры, шуңа күрә курыкмый, ул шәүләләргә дә игътибар итми.

Акмуенның юлын сукыр тычкан үтеп чыкты. Башка вакытта тыныч кына карап калмас, юлын кисәргә җөрьәт иткән бу урман мәхлугына арт сабагын укытыр иде Акмуен. Кем кисте диген әле син аның юлын — тычкан! Тегенди мондый тычкан да түгел — сукыр тычкан! Тик бу юлы Акмуен аның артыннан ташланмады, бүген башкасы мөһимрәк: тизрәк малай янына барырга кирәк. Бүген этлегеңне эт итә торган көн түгел.

Хәсән кинәт туктап калды:

— Юк-бар белән вакыт уздырып, башны катырып йөрмик Габдулла абый.

— Шулай дисең дә бит, энем...— Габулла агай башын кашып алды.— Чыннан да кире кайтыйкмы? Ә каядыр алып бара бит бу эт безне.

Аның сүзләрен расларга теләгәндәй, Акмуен кызганыч тавышлар чыгарып чинады да, килеп, тагын Габдулланың балагыннан тартты.

— Менә ич, Хәсән энем, күрмисеңмени: теле генә юк факырның әйтеп бирергә.

Шулвакыт урман эче тагын көчле шау белән күмелде.

— Әнә, безнекеләр эшли дә башладылар. Әйдә, бераз барыйк та аннан кире борылырбыз.

Равилнең бәхетенә, озакламый алар урман читенә килеп чыктылар. Равил янына килеп җиткән Акмуен шатлыгыннан өреп җибәрде. Тор, янәсе, кешеләр алып килдем.

Таш өстендә ятып туңудан һәм канечкеч черкиләр ашаудан сакланып бөрешә торгач йомгак хәленә килгән Равилне күреп, бораулаучыларның исе-акыллары китте.

— И, балакай, кайлардан килеп чыктың син монда?

Уятудан курыккан Габдулла агай малайның битенә, аякларына кунган черкиләрне куып, кечкенә гәүдәне күтәреп алды һәм күкрәгенә кысты.

Шатлыгыннан ни эшләргә белмәгән Акмуен койрык очын өскә каратып болгый, аяк астында бутала иде.

Буровойда берничә минутка тагын эш тукталды. Бораулаучылар рация аша диспетчерлык белән сөйләшкән Габдулла агайны сырып алдылар.

— Алло, алло, прием! Гәрәй, синме? Безнең монда «ЧП». Машина кирәк!

Диспетчерның куркынган тавышы ишетелде:

— Габдулла агай, нинди «ЧП»? Авария ясадыгызмы? Кеше имгәндеме? Әллә...— Шикләнүе дөрескә чыгар дип курыккан диспетчер сүзен әйтеп бетермәде.

Габдулла, ялгышрак әйтеп ташлаганын сизеп, төзәтергә ашыкты:

— Юк ла, авария димәдем бит, тьфү, авызыңнан жил алсын! Без... ни... малай таптык монда.

Диспетчерның шаркылдап көлгәне ишетелде. Аңа кушылып, бораулаучылар да елмаештылар.

— Син, иптәш Фазлетдинов, акылга җиңеләймәдеңме? Нинди малай табу ди ул? Буровойга берәрегезнең хатыны килгән идемени?

Ничек аңлатыйм микән, дип гаҗизләнеп, Габдулла бораулаучыларга карады.

— Син анда авызыңны ерма әле аңламаган башың белән! Сиңа татарча әйтеп торам ич, бала таптык, кайтарырга машина кирәк.

Барыбер аңа Равилне кайдан, ничек табуларын тәфсилләп аңлатып бирергә туры килде.

Ә Равил уянмый. Ике кулын баш астына куйган да йоклый. Бораулаучыларның берсе аның өстенә халат япкан. Аңа җылы, черкиләр дә тешләми. Ә күзенә төшкән ут яктысы кояшны хәтерләтте һәм Равил елмая-елмая төш күрүен дәвам итте.

Әһә, менә кайда йоклый икән кояш төннәрен! Равил барыбер эзләп тапты, барыбер күрде бит кояшны. Хәзер юлын белә, ышанмасалар Наилләрне, Ниязларны да алып килер. Кояшны уятырга да тырышып карый Равил, уята алмый. Йокласын әйдә. Иртән уяныр әле, шунда сөйләшерләр. Ул Акмуен белән ничек килүләрен, аны ничек эзләп табулары, сазлыкта суырылып төшеп калган сандалиларын, төн җиткәч тә үзенең тамчы да курыкмавын сөйләр. Кояш абыйсы аны мактар. Шуны күз алдына китереп, Равил төшендә көлеп җибәрде.

Бораулаучыларның берсе малай янында калды, бүтәннәре эшкә тотындылар.

Равилләр артыннан килгән машина сәяхәтчеләрне туптуры районның Эчке эшләр бүлегенә алып кайтып тапшырды. Инде таң атып килә иде. Дежур торучы лейтенант Караяр авыл Советыннан алынган билгеләр буенча малайның кемлеген шунда ук таныды. Икеләнерлек урын юк иде. Берничә минуттан качкыннарны «Милиция» дип язылган «Жигули»га утыртып Караярга алып киттеләр. Равилләрнең капка төбенә килеп туктаганда Кызыл тау өстеннән кояш күтәрелеп килә иде.

Шатлыгыннан нишләргә белмәгән Равилнең әнисе түшәккә кертеп салган улының битеннән, чәченнән, тырмалган, каралган битләреннән, черки талап бетергән балтырларыннан, бармак очларыннан елый-елый үбә. Үзе һаман:

— Улым, бердәнберем, качкыным минем! — дип кабат-

лый.— Кайларда гына йөрдең икән,ниләр генә дип барып чыктың икән ул тауларга? Ничекләр генә адашып үлмәдең икән, балакаем, алтын баганакаем минем!

Әллә әнисен тоюдан, әллә өйдәге шау-шудан Равил күзен ачты һәм әнисен кысып кочаклап алды:

— Әнием! — Аннан әтисен кочаклады.— Әбабай, бабакай кайда?

— Хәзер керә, ул көтү куарга чыккан иде.— Тәрәзә аша берәүнең шәүләсе күзгә чалынып узды.— Әнә керә дә инде.

Әтисе белән әнисе кочагыннан ычкынып Равил бабасының каршысына йөгерде.

— Бабакай, мин кояшны күрдем!

— Әйбәт иткәнсең, улым. Кояшлы булсын безнең көннәр!

Улының табылуына инде ышанып җиткән әнисе:

— Улым, ник инде тыңлаусыз малайлар шикелле әйтмичә-нитмичә киттең? — дип шелтәләп сорады.— Нишләтергә инде сине моның өчен?

Өлкәннәрне гаҗәпкә калдырып Равил тавыш-тынсыз бүлмәсенә кереп китте һәм, алар ни дә булса аңларга өлгергәнче, үзенең чалбар каешын алып чыкты.

— Мә! — диде ул, каешны әнисенә сузып.

— Нәрсәгә ул миңа, улым? — әнисе аптырашта калды.— Нигә алып чыктың ул каешны?

— Сорамыйча киткән өчен,— дип җавап кайтарды Равил, черки тешләгән җирләрен кашый-кашый.— Үзе күзләрен туп-туры әнисенә төбәде.— Курыкма, сук сугасың килсә,— дип өстәде аннан соң,— мин еламыйм. Шортикны төшеримме?

Эшнең нидә икәнен хәзер генә аңлаган өйдәгеләр, түзәлмичә, дәррәү көлеп җибәрделәр.

— Ярар инде, улым,— әтисе аның кулыннан каешын алды.— Гаебеңне үзең аңлагач, бер юлга кичерербез. Шулай бит, әнисе?

— Шулай, әтисе, шулай. Минем улым әйтмичә бүтән беркая да китмәс, әйеме?

— Әйе,— диде Равил ышандырырлык итеп һәм кызганыч тавыш белән өстәп куйды.— Әни, минем бик ашыйсым килә. Ашарга бир әле...



СУГА ЯЗЫЛГАН ХАКЫЙКАТЬЛӘР

САМАВЫР БОРЫНЫ

Миңлеҗиһан карчык җиләктән кайтып кергәндә, ишегалдын тутырып бала-чага уйный иде. Хуҗа әбине күрүгә күрше Сабира кызы Фәния, итәгенә җыйган чуерташларын ыргытты да, чыгып йөгерде. Һәрберсе үз уены белән мәшгуль балалар арасында аның китүенә игътибар итүче дә булмады диярлек. Карчык, оныгы Таһир янына килеп, чиләгеннән аңа бер уч җиләк алып бирде. Чиләккә өмет белән карап торган башка балаларга:

— Барыгыз, бар! Тоз суы сипмәгәннәр монда. Урамда, я үзегезгә кайтып уйнагыз! — дип куалый башлады.

Таһир: —

— Китмәсеннәр инде, әби, уйнасыннар инде! — дип инәлеп караган иде. Миңлеҗиһан карчык ике сөйләшерлек итмәде:

— Тик кенә тор! Барыгыз, бар, көш-шегез моннан! Балалар чыгып шылгач, ул урам капкасын эчтән элеп үк куйды. Өйгә керсә, бер мәлгә сүзсез калды. Анда яу узганмыни, ал якның асты өскә килгән, урындыклар ауган, идәнгә нindидер йомычкалар чәчрәгән. Өстәлдә ашалып бетмәгән ипи кисәкләре ята. Сизелеп тора: Таһир, өйдә кеше юклыгыннан файдаланып, бергә уйнаган дусишләре белән кергән дә рәхәтләнгәннәр. Агачтан юнып нәрсәдер ясаганнар, ипине дә кисеп тормыйча ничек кирәк алай сындырып кына ашаганнар. Ипи валчыклары белән идән тулган. Җыештыручы гына табылмаган.

Башка вакыт булса Миңлеҗиһан карчык болай гына тукталмас, Таһирга да эләктерер, башкаларның да эзенә төшеп өлешсез калдырмас иде. Тик эссе көндә җиләктән кайткан кешенең үз хәле хәл. Безнең әбиебез дә мыгырданып алу белән чикләнергә мәҗбүр булды. Уфылдап, су чиләге янына килеп чүгәләде. Бер чүмеч эчте, шуннан соң гына азрак хәл кергәндәй итте. «Я, раббем, биргәненә шөкер, меңнән-мең шөкер»,— дип, ишек бусагасына утырды. Тирләгән маңгаен җиңе белән сыпырып алды, ашыкмыйча гына оекларын салды. Оегының кунычы белән аягына кунган тузаннарын сөрткәндәй итте. Нишләргә соң әле дигәндәй, тагын бераз хәл җыеп утыргач, идәнгә коелган икмәк валчыкларын җыеп алды һәм самавыр кую нияте белән, урыныннан кузгалды. Җиләктән кайткач гөжләп торган самовардан чәй ясап эчүдән дә рәхәтрәк ни бар тагын!

Күпне күргән җиз самавырны мич каршысына китереп утыртты, чүмеч белән аңа су салмакчы иде, кинәт борыны юклыгын шәйләп алды.

— Каһәр суккан нәрсә, су агыза яздым бит! — дип сукрана-сукрана, Миңнеҗиһан карчык як-ягына каранды. Ләкин эзләгәне тәрәзә төбендә дә, кучкарда да, сәкедә дә юк иде.

— Балалар алып уйнагандыр, хәерсезләр,— дип, сәке

астына күз төшерде. Әллә соң базга төшкәнме? Базга төшеп тә карап менде. Аннан да тапмагач, чыгып, ташны ташка ышкып «он» ясап утырган Таһирга кычкырды:

— Улым, самавыр борынын кая куйдыгыз?

Таһир шөгыленнән аерылмыйча гына җавап кайтарды:

— Белмим, тимәдек без аңа.

— Сез тимәгәч, кая китсен ул, әйт, кайсыгыз алды?

— Белмим дидем бит инде, тимәдек без аңа.

Шунда Миннежиһан карчыкның исенә келт итеп Фәния килеп төште. «Шул хәерсез алгандыр, мине күрү белән чыгып сызды. Шулдыр, шулдыр, бик чая нәрсә, мәлгын! Кереп кирәген бирим әле юньсезнең!» Әбиебез җитез адымнар белән күршеләренә юнәлде.

Фәниянең анасы Сабира ашап-эчеп туйган, табынын җыештырган, самавырының көлен кагып тора иде. Фәниянең өйдә күренмәве Миннежиһан карчыкның күңелендәге шиген көчәйтте генә. «Мине күргәч качкандыр, мәлгын, тимәгән булса, өендә утырыр иде, хәерсез».

— Сабира, кызың кая, минем самавыр борынын ул гына алган. Самавыр куярмын дигән идем, тамагым кипте.

— Ни сөйлисең син, Миннежиянтәй? Бер дә андый гадәте юк иде, ничек алыр икән?

— Шул озын куллы кызыңны яклап маташкан булма, ичмасам, ачу китереп! Мине күрүгә корт чаккан кебек чыгып йөгерде. Өйдә булмыйчарак торсаң, борынын гына түгел, самавырын сөйрәргә дә күп сорамас. Мин юкны гына карап тора кызың. Бер дә бездән чыкмый. Ничә әйттем югыйсә, юк, колагына да элми...

— И, бала-чаганың уйнарга керүен дә гаепкә алып торма инде, Миннежиянтәй. Сезнең Таһир да бездән чыкмый кайчакта, аңа карасаң...— Сабира бераз сүзсез торды.— Мә, күрше, хәзергә үзебезнекен алып тор, Фәния кайту белән сезнекен кертербез, әгәр алган булса...

Авыз эченнән нидер сөйләнә-сөйләнә Миннежиһан карчык үзләренә чыгып китте.

Бераздан Фәния кайтып керде. Аяк киемен дә салырга онытып өстәл янына килде һәм ипи белән шикәргә үрелде.

— Ашыйсым килде, әни.

Кызы турында яман хәбәр ишетүдән каны кызган Сабира шулчак аның кулыннан эләктереп алды. Үзенең гомерендә дә кеше әйберенә тигәне юк иде, кайдан килеп кызы кәкре куллы булган диген? Кызыннан кискен генә сорады:

— Миннежиянтәйнең самавыр борынын кая куйдың, оятсыз?! Кертеп бир хәзер үк!

Әнисенең бу кадәр ярсыганын күргәне юк иде Фәниянең, куркуыннан агарып китте, кулын ычкындырырга теләп тыпырчынды.

— Тимәдем, әни, белмим, белмим, дим бит инде! Җибәр инде, әни, авырта бит! Тимәдем! — дип кабатлады.

Ләкин Сабира кызының сүзләрен игътибарга алырлык кына булып кызмаган иде:

— Әйтәсеңме, юкмы! Үтерәм, бир хәзер үк! — Сабира чөйдә асылынып торган каешны эләктереп алды.— Адәм рисвае иттең бит, сабакы кыз! Кемнән өйрәндең урлашырга? Кулыңны тиз кыскартырмын мин синең! — Каеш чыжылдап кызының кулына килеп төште. Фәния кычкырып җибәрде һәм акырып елый башлады.

— Тимәдем мин аңа, тимәдем...

— Олы кеше юкны сөйләмәс, алдашма, юньсез!

Сабира тәмам чыгырыннан чыкты. Каеш хәзер кулга гына түгел, кая туры килсә, шунда төшә башлады.

Тыпырчына торгач, ничектер, Фәния ычкынып китте һәм чыгып йөгерде. Сабира:

— Әле качып котылмакчы буласыңмы?! Качырырмын мин сине, кулыңны сындырмыйча туктамам! — дип, аны урам капкасы төбендә кабат тотып алды. Каеш Фәниянең сыдырылып күлмәге күтәрелгән шәрә аркасында биергә кереште.

Ярсыган Сабираны:

— Үтерәсең бит баланы,— дип, урамнан узучы халык кына аралап алды.

Миннежиһан карчык үзе җыеп кайткан җиләк белән тирли-тирли чәй эчте. И-и, җиләк белән эчкән чәйнең тәмлелеге! Эчеп туйгач, рәхәтлеккә шөкранә итеп, дога кылды. Савыт-сабаларын, тәм-томын җыештырырга тотынды. Чынаяк-тәлинкә ишесен сөртеп шкафка тезде, ипине, прәннекләрне ашъяулыкка төреп куйды. Иң ахырдан самавырның капкачын ачып суын түкмәкче булды. Су белән бергә чиләккә нидер чупылт итте. Миннежиһан карчык аны күргәч аһ итте: чупылдаган әйбер самавыр борыны иде. Аның исенә төште: җиләккә киткән чагында, өй караучысыз кала, бала-чага алып уйнамасын дип, самавыр эченә үзе яшереп куйган иде шул.

— И, бу хәтер дигәнең!.. Картаела ахрысы...— дип сөйләнә-сөйләнә, ул самавырның көлен кагарга кереште.

БУЛЫШЫРГА КАЙТТЫЛАР

(Моңсу хикәя)

Өч яшькә җитсә дә әбисе белән бабасын күрергә өлгермәгән дүртенче оныклары Мәгъсүмне ияртеп, төпчек уллары Рамазан кайтып кергәч, Әүхәди абзый белән Хәмидә әбинең куануларын күрсәгез иде! Җитмәсә, Рамазан, исәнлек-саулык сорашуга ук әйтеп куймасынмы:

— Әти-әни, сезгә ялгыз яшәүләре кыендыр, картайгансыздыр. Без менә булышырга кайттык! — диде ул тантаналы рәвештә. Аннан кече улын бабасына таба җибәрде:

— Бар, улым Макс, әйт әле бабаңа безнең ни өчен кайтканны!

Малай иң башта бабасын кочаклап, чупылдатып үбеп алды.

— Дедушка, без сиңа помощь оказать итәргә килдек!

Мәгъсүмнең әйткән һәр сүзен аңлап бетермәсә дә Әүхәди абзыйның күңеленә оҗмах җилләре исеп киткәндәй тоелды. Карасана, бигрәкләр дә матур сөйләшә белә икән бу бала. Теле яңа гына ачыла башласа да сиксән яшьлек бабасыннан урысчаны шәбрәк сукалый бит бу,

— Үскәнсең икән инде син, улым, үскәнсең икән. Бәхет, тәүфыйктан ташламасын үзеңне,— дип оныгын сөясөя, ул күзенә чыккан яшьләрен кешегә күрсәтмәскә тырышып күлмәк җиңенең очы белән сөртеп алды.

— Рәхмәт, балалар, рәхмәт. Әйдәгез, юлдан арып килгәнсездер, чәй эчеп, ятып хәл җыеп алырсыз.

Бераздан Хәмидә әбинең үзе белән картайган, «пуфпуф» ,«хуш-хуш» дип шаулап торган җиз самавыр да өстәлнең урта бер җиренә менеп кунаклаган иде инде. Хәмидә әби хәзинәдә барын берсен дә калдырмаган: иртән генә аерган каймактан тыш каклаган каз белән кәрәзле балга кадәр табынга куелган иде. Иске күәс эчендә шушы көнне көтеп зарыккан башка сый-хөрмәт тә өстәлгә менеп утырды. Табын янында бераз хәл җыеп, кәефе күтәрелә төшкәч, Рамазан:

— Сагындым шул авылны. Каклаган каз итен ашауга ни җитә,— диде.— Сыра да эчеп җибәрсәң, сарык итләреңне онытырсың!

— Сарыгын да суярбыз, улым. Анаңның корбан бәйрәменә дип симерткән сарыгының мөгезе сынган...

— Я-я, эти, сарык дип, без бит кунакка кайтмаган. Хәер, сам хәҗәен, сам хуҗа дигәндәй, үзеңә карарсың тагын. Әйдә, ашап-эчик тә, мин авылны бер урап чыгыйм. Күптән күргән юк бит, сагындырган. Туган йорт туган йорт инде,— Максчик, киттек!

Сиксән генә чакрымда торсалар да, өч елга бер генә көтеп алган кадерле уллары белән дөньяда бер сөйкемле оныклары кайтуга куанып туялмаган карт белән карчык аш-су хәстәренә керештеләр. Хәмидә әби казан астына ягып җибәрде. Аннан соң тирә-юньдә иң башкисәр булып танылган кызыл әтәчне, тегесенең каравыл кычкыруына һәм тавыкларның әтәч тикле әтәчнең шулай тоттырып торуына чиксез гаҗәпләнүләренә карамастан куып тотып башын аяк арасына кыстырды, бөтерелгән юкә белән тәпиләрен бәйләп тә куйды. Тотып бирүең генә хак булсын, Әүхәди абзый аны нишләтергә белә. Тегене яшел чирәм өстенә, кыйблага каратып яткырды да бисмилласын әйтүе булды, утыз ел буена турылыклы хезмәт иткән

чалгы пәке әле биш-ун минут кына элек кукраеп йөргән әтәчкә «ә» дигәнче «кызыл муенчак» кигертеп куйды.

Әтәч ите, карт булуына да карамастан, пешеп таралып бетте, көтү кайтты, ә кадерле кунаклар юк та юк. Карт белән карчык ясту намазын укып йокларга ятарга җыенганда гына урам яктан Рамазанның җыры ишетелде:

Дус-ишләрем бигрәк юмарт,
Ашаталар колбаса.
Кайтыр хәлләрем калмады,
Хатын килеп алмаса.

Күп тә үтми, йоклаган улын күтәреп, чайкала-чайкала үзе дә килеп керде. Хәмидә әби:

— И, улым,— дия башлаган иде, Рамазан:

— Молчок, әни! — дип бүлдерде.— Ашыйсы килә, бирәр нәрсә бармы?

Атәч боты кимереп утырган җиреннән сәке башында йоклап киткән Рамазанны, күтәреп йөртерлек хәлләре булмагач, мендәр салып, шунда гына аудардылар.

Иртәгесен корбанлыкка симертелгән мүкләк тәкә суелды. Рамазан шулпа өлгерүгә йокысыннан торып юынгандай итте һәм кәефсез генә өстәл янына килеп утырды. Аның әледән-әле кичәгедән калган сыра шешәсе торган шкаф ягына күз салуыннан нәрсә теләгәнен атасы шунда ук аңлап алды. Бераздан соң кунакның кәефе ачылып китте.

— Дуслар бит, теге бергә уйнап үскән Тавык Гатауллалары кыстадылар да кыстадылар,— диде ул, кичәге өчен акланган тавыш белән.— Кунакка кайтмадым, әткәй-әнкәйгә булышып, ярдәм итешеп китәргә генә кайттым дип тә карадым. Кеше аңлыймыни ул синең хәлеңне...

— Киленне дә алып кайтасың калган, хәзинәдә бары бергә-бергә булыр иде.

— Куй инде, аның мыгырдавыннан өйдә дә туйган. Отпускада да бер рәхәтләнеп ял итмәгәч... Шулай бит, улым?

Ә улы исә:

— Мин әнине сагындым! Минем өйгә кайтасым килә! — дип шыңшырга ук тотынмасынмы.

Ашап-эчкәч ата белән ул ишегалдына чыктылар. Сиксәнгә җитеп килүче картның куәте җитмәгәнлектән бу ишегалдында кайтып аударганнан бирле ярылмыйча ятучы бер машина утын да, баганасы черү сәбәпле кыйшаеп беткән койма да, түгәргә кеше булмаганга ике-өч ел буе җыйналып, шактый тарау яткан тирес өеме дә Рамазанга чекерәеп карыйлар төсле иде. Абзар артындагы бәрәңге бакчасын чүп баскан, анда алабуталар кукраеп утыралар иде. Тик Рамазан аларга озак карап тора алмады, чирлим бугай дип, узган елдан калган печән өеменә менеп сузылып ятты.

Бу көнне эшләргә насыйп булмаган икән. Йокысыннан торуга аны авылдагы кардәш-ыруларның берсе ашка алып китте. Ярты төн уртасында өенә кайтып барган Рамазанның кәефе кичәгедән һич кенә дә ким түгел иде.

Шушылай бер-берсенә охшаган көннәре белән атнадан артык вакыт узып та китте. Ниһаять, Рамазан да эшкә тотынды. Өч көн дигәндә койманың череп ауган бер баганасы урынына яңаны утыртты. Төпчек улларының ялга кайтса да эшләгән булып йөрүләренә сөенеп туялмыйлар иде картлар.

— Улыбыз бер генә дә тик тора белми инде,— дип күрше-тирәгә сөйләнде Хәмидә әби.

— Әтиләргә ярдәм итәргә кирәк, бераз караштырам менә,— дигән булды узган-барганнарга Рамазан да.

— Әти, койманы үзең кадакларсың инде,— диде ул аннары әтисенә.— Миңа берсекөнгә заводка эшкә чыгарга. Да, вакыт кына бетте, югыйсә тиресне дә түгеп ыргыткан булыр идем, бәрәңгесен дә утар идем дә... Эш бит, әти, үзең беләсең.

— Ярар, улым, ярар, юкка борчылма. Күрше Җамалыйдан сорап карармын әле, ул түгеп бирмәсме. Син бит кунак кеше.

Булышырга дип сиксән чакрым тикле җирдән өч елга бер кайткан улларын Әүхәди абзый белән Хәмидә әби сарыкның ашап өлгермәгән арт ботын суеп чистарткан ике

тавык янына төреп, уллары белән сөйкемле оныклары Мәгъсүмне автобус тукталышына кадәр озата чыктылар.

— Кунактан нишләп бик тиз китәсең? — дип кызыксынды бериш авылдашлары. Рамазан:

— Эшем көтә бит. Нинди кунак ди ул? Әти-әни бик картайды, булышырга гына кайткан идек,— дип җавап кайтарды.— Иртәгә эшкә, югыйсә, дөньяларын әйләндереп салыр идем.

— Ниләр эшләдегез соң? — дип, Мәгъсүмнән дә төпченүчеләр табылды. Шәһәр малае, тере малай бит, җавабын ничек тиз таба диген, ут борчасы!

— Әбика белән бабайканың петух белән сарыгын, бар бит әле теге мөгезе сынган барашка, шуны ашадык!..— диде.

ЛОТЕРЕЯ БИЛЕТЫ

Кызыл почмакта бүген биллиардка борылып карачы да юк, домино сугучылар да калмаган. Егетләр барысы да, балга җыелган чебен шикелле, тәрбияче кыз Илгизә янында бөтереләләр. Акча-әйбер лотереясының яңа таблицасы кайткан икән, билетларын тикшерәләр.

— Чиратсыз кермә,— дип шаярта Камил, Вәзыйхның җиңеннән тартып.— Я миңа дигәнне отып куярсың. Чур, отсаң, икебезгә уртак!

Илгизә караганнан соң да һәр билетны җиде кат энә күзеннән уздыралар егетләр, тик аңа карап кына бәхет елмаймый.

Сафуан, көлемсерәп, өстәлдән читтәрәк басып тора иде, Илгизә тынычлыкта калдырамы соң!

— Ә синең билетларың кайда?

— Әй, авылда онытып калдырганмын. Блокнотка номерларын язып куйган идем куюын да...

— Китер монда. Номерлары булгач, безгә блокнот та җиткән. Кая әле. «Жигули» отып бирим әле үзеңә. Берәр тапкыр урманга җиләккә алып бармассыңмы...

— Кызларның шул инде. «Жигули» сүзен ишетүгә җиләк дия башлыйлар.— Камил бу юлы да төрттереп

алырга форсатны ычкындырмады. Бер дә минем калтырча «КрАЗ»га утырам дими, «Жигули» ди бит. Ха-ха!

Сафуан теләр-теләмәс кенә блокнотын Илгизәгә сузды:

— Карап та торасы юк инде, барыбер чыкмый.

Илгизә билетларны тәмен белеп тикшерергә кереште. Берсен, икенчесен карады, өченчесен... Һәр кысыр билет саен Сафуанга күп мәгънәле елмаю бүләк итте һәм чираттагы номерны таблицадан эзләргә кереште. Кинәт аның газетага төрткән бармагы калтыранып куйды. Күзләре ялт-йолт килеп, әле блокнотка, әле таблицага текәлделәр. Сөйкемле чырае аклы-кызыллы тимгелләр белән капланды.

— С-с-сиңа м-машина! — диде ул, тотлыга башлап. Гадәттәге яңгыравыклы тавышы, мәгарәдә хәзинә тапкан малайныкы сыман, пышылдап чыкты. Аннан, башкалар ни дә булса аңларга өлгергәнче, сикереп торды да, Сафуан янына йөгереп килеп бит очыннан чупылдатып үбеп алды.

— Малайлар, егетләр дим, Сафуан «Волга» отты!

Унлаган авыздан, өйрәтеп куйган шикелле, бер аваз чыкты:

— Ә?! — Һәм үз күзләре белән күрәсе килеп, барысы да таблицага капландылар.

Сафуан исә кулын гына селтәде:

— Шаяртмагыз сана. Болай да йөрәкнең рәте юк. Тоттырырлар сиңа «Волга»?!

Илгизә аны өстәлгә таба алып китте:

— Ышанмасаң, үзең кара.

Егетләр, генерал каршылаган солдатлармыни, икегә аерылып, үрә каттылар.

— Сөенчегә синнән бер плитка шоколад,— диде Илгизә.

— Акылың алтын икән. Алай җиңел генә котылмасын әле.— Камил Сафуанның каршысына килеп басты.— Илгизә туташ шоколад ашаганда, без суган суы суырыйкмыни? Сезнеңчә ничек, егетләр?

Егетләргә әйт кенә, мондый чакта алар сыната торганнардан түгел, ничек җавап бирергә кирәген беләләр:

— Ничек дип... Ыһы-ыһы. Сафуан башсыз малай түгел, үзе белер...

Баш катырмагыз дигәндәй, Сафуан кулын селтәде.

— Анысы качмас, егетләр. Башта машинасын алыйк. Юктыр, гәҗиткә ялгыш басканнардыр. Һич ышанасы килми...

Шул минуттан алып Сафуан тыныч тормышның ни икәнен онытты.

Дус-ишләрен әйткән дә юк, җиде ятына кадәр котлыйлар. Әле тегесенә, әле бусына кул биреп туеп бетте. Юк йомышларын бар итеп, цехның кызлары да яныннан ешрак урый башладылар. Кем-кем, моңа кадәр сүз каткаласа да, якты чырай күрсәтмәгән Гөлназ нәрсә ди бүген:

— Клубта яхшы кино була икән, миңа да билет алып куялмассыңмы? — Үзе егеткә шундый иттереп карады, башыңа тай типкән бер мәхлук булмасаң, аңларга тиешсең, янәсе.

Аңламыймы соң Сафуан! Төшке ашын ашамаса ашамады, барып, кинога ике билет алып кайтты.

Кичен, Гөлназ белән янәшә утырасын уйлап, кинога җыена гына башлаган иде, ишек шакыдылар.

— Керегез.

Тулай торак егетләренең берәрсеме дисә, зур фуражкаларын кыңгыр салып, берсе озын, берсе карсак буйлы бөтенләй таныш булмаган ике ир килеп керде. Карсагы керә-керешкә, кодасына кунакка килгәнмени, алтын тешләрен ялтыратып елмайды да күрешергә кулын сузды:

— Исәнмесез, Сафуан, исәнмесез! Сезнең белән якыннан танышуга шатбыз. Бәхетле билетыгыз турында бөтен поселок шаулый. Куанычыгызны уртаклашырга кердек. Әйтергә генә ансат: утыз тиенгә «Волга» бит! Барыбыз өчен дә уртак бәйрәм бу! Киенегез, дускай, сезне алырга килдек!

Көтелмәгән бу визиттан Сафуан аптырап калды:

— Кая киттек? Аңламыйм, сез кемнәр!

— Шикләнмәгез, без дә сезнең шикелле, үз хезмәте белән тир түгеп көн күрүчеләр. Әйдәгез, ресторанга заказ бирелгән, акчасы түләнгән.

Рестораннарга йөреп өйрәнгәнмени Сафуан, ни әйтергә белми аптырап калды. Әле ярый, кинога барасы исенә төште.

— Рәхмәт, бара алмыйм. Вакытым юк,— диде, кырт кисеп.

Елтыр тешле фуражкасын салып тумбочка өстенә ыргытты һәм:

— Зыян юк, кадерлем, алайса бүлмәгездә биш кенә минутлык миниресторан оештырабыз,— дип, рөхсәт-фәлән көтеп тормастан, дипломатын ача башлады.

— Сез нишлисез? — Сафуан ачыла башлаган дипломатны ябып өлгерде.— Мин эчмим.

— Кем эчәргә ди? Зур шатлыктан бераз тамак кына чылатабыз.

— Юк, тамак та чылатмыйбыз! — Сафуан ачуы чыга башлавын тойды. Һәм, түземе бетеп, сорауны кабыргасы белән куйды.— Әйтегез, нәрсә кирәк сезгә? Минем вакытым юк, көтәләр.

— Менә бусы ирләрчә! Яхшы кеше икәнегезне мин бер күрүдә үк аңладым.— Елтыр теш, як-ягына каранып алганнан соң, Сафуанның колагына пышылдады.— Сатыгыз безгә бәхетле билетыгызны! Утың мең бирәбез! Теләгән дус-иш, туган-тумачаларыгызны урманга шашлык ашарга чакырабыз.

— Юк.

— Утыз биш мең!

— Юк!

Елтыр теш тагын да нидер әйтмәкче иде, моңа кадәр авызына су капкан шикелле сөйләшми торган озын буйлысы карсакны кулы белән ишарәләп туктатты.

— Кырык биш мең! Ишетәсезме, кырык биш мең! Өч бәя. Малайның туена «Волга» вәгъдә иткән идем. Коткар, дускай, адәм мәсхәрәсенә калдырма, ак чәчләремне кызган! — Көтмәгәндә ул Сафуанның алдына тезләнде.— Сат миңа машинаңны! — Ул менә-менә елап җибәрер төсле иде.

Сафуанга, ак чәчле башын иеп алдына тезләнгән бу адәм кинәт кызганыч тоелып китте. Һәм ул, ансат кына котыла алмаячагын аңлап, хәйләгә сабышты:

— Ул билет юк шул инде. Саттым мин аны. Соңардыгыз.

Озын буйлысы ничек сикереп торганын да сизми калды. Елтыр тешлене̧ң кулыннан дипломаты чак төшеп китмәде. Икесе берьюлы Сафуанның күзенә керердәй булып:

— Кайчан? Кемгә? — дип сорадылар.

— Бөгелмәдән килгән берәүгә.

— Аһ!

Канатлары каерылган үрдәкләр шикелле, өметсезлеккә төшеп, алар ишеккә таба юнәлделәр. Тоткага ябышкач елтыр теш борылып башын иде.

— Хушыгыз. Шулай да, сер булмаса, әйтегез әле: күпмегә саттыгыз?

— Нәрсәне?

— Билетны. Машина билетын!

Машина сатып өйрәнгәнмени Сафуан, уйлап та тормый әйтте:

— Үз бәясенә.

— Ә? — Озын буй фуражкасын койкага атып бәреп, чәченә ябышты.— Я, раббем, нигә шулкадәр гаделсез син? Ник ул отышны кирәк кешесенә чыгармыйсың? Нигә теләсә нинди малай-шалайга «Волга» биреп, затлы машинаның кадерен җибәрәсең? Үз бәясенә ди бит, үз бәясенә! «Волга» кадәр «Волга»ны! Ничек җир күтәрә сине, геноцевале?!

...Сафуанны котлаучылар да, машина юу сылтавы белән тамак чылатырга ишарә ясаучылар да җитәрлек булды бу атнада. Саранланасың диючеләре, үпкәләүчеләре дә табылды. Җомга көн төштән соң моңа кадәр мыек астыннан елмаеп йөргән мастерлары Муса агай да карлыккан тамагын кырып туктатты:

— Карап-карап торам да, Сафуан энем, тагын бер карап куям. Үзең болай юньле кешегә дә охшап торасың сыман. Машина отуыңа миннән дә ныграк куанучы бардыр дисеңме? Юк и һәм булмас та! Ни өчен дисеңме? Болай ул. Безнең бригада — бер гаилә. Ә мастер бригадада ата урынына. Әнә шул атаң урынындагы мастерың

белән сөенечеңне уртаклашырга башың житми. Әллә нинди этрәк-әләм белән зәңгәрләнгәнче югансыңдыр, шәт. Указ дигәч тә, эштә эчәргә димәгән. И һәм ярамый да закон бозарга! Мәрфуга жиңгәңнең пилмәннәре әзер, безгә барырга була...

Мастерының чын-чынлап үпкәләвен күреп, Сафуан акланырга кереште:

— Берни дә отмадым мин, Муса агай. Шаярттым гына.

Муса аңа сөзеп карап торды-торды да йөрәк тавышы белән әйтте:

— Их, энем, әллә мине сиңекен эчәсе килгәннән әйтә дисеңме? Мастерыңны белмисең икән әле син. Шешәне мин үзем ала идем. Ярар, минем белән юарга теләмисең икән, аны туп-туры әйтергә кирәк. Теләсә ничек боргалап, олы кешене алдарга тырышу оят. И һәм килешми дә. Онытма, синең дә картаясың бар...

Сафуан үз башына шаяртканын шунда гына аңлады. Отышлы номерны блокнотына газетадагы таблицадан күчереп язганын кемгә генә әйтмәсен, ышанучы табылмады. Киресенчә, кайбер дуслары хәзер аңа сәерсенеп карый башладылар.

Бәхетле билет турында сүз тарала-тарала хәтта редакциягә үк барып житкән икән. Көннәрнең берендә, бу хакта язарга дип газетаның махсус корреспонденты эзләп килгәч, Сафуан егылып китә язды һәм шиккә калды: әллә соң аның «Волга» отуы чынлап та хак булды микән?..

БЕР МОНОЛОГ

Егылып үлсәм үләм, әмма Ибраевның борынга чирткәнен күтәреп ята алмыйм. Андый хәлнең булганы юк һәм булмас та! Заманы нинди бит, заманы!

Үзгәртеп кору, тизләнеш хакында сүз куера башлагач, баш миенең күптәннән уйларга туры килмәгәнлектән тутыгып беткән шариклары гомер буена дегет күрмәгән

чытыр арба тәгәрмәче кебек шыгырдап булса да урыннарыннан кузгалдылар.

Үзгәртеп кору дигәч тә, әйтүе генә ансат. Бар, бездәге капиталь төзелеш системасын үзгәртеп корып кара! Биш ел элек сала башлаган утыз алты фатирлы йорт янындагы кран башына менеп әтәч булып кычкырсаң да, кирпече дә үзе килми, измәсенең дә безгә дигәне Ибрайныкыларга китеп баруы бар. Корт чаккыры, хәзер измәчеләрнең дә кыланышыннан косасың килерлек бит аның. Элегрәк өч ертык берлеккә алган шешә күрсәтсәң дә: «Гайнан Вәлитович та, Гайнан Вәлитович!» — дип, бер алдыңа, бер артыңа төшә торган, кушсаң, фамилиясен дә алыштырырга риза булган Сафин — измә-бетон узелы начальнигын әйтәм — беркөн үзенә указдан соң ун тәңкәгә алынган ярты күрсәткән идем, нәрсә ди бит:

— Юк инде, Гайнан Вәлитович, синең ул аракыңны эчеп эштән куылыр хәлем юк. Исән-сау ел ярымны уздырсам пенсиягә чыгасы бар. Фондта күпме каралса, шул чаклы измә алырсың,— ди.

Минем урынга куеп карасын иде үзен Сафин! Аннары фондта күпме каралган дип тормас иде. Кемгә генә җиткерим мин ул фонд белән бүленгән измәне? Әле трестның баш инженеры дачасындагы ике катлы йортның нигезе генә салынган. Җитмәсә, партком секретаре гараж сал дип йөри. Сараландагы мәктәп, Ташкичүдәге тавык фермасын, эшчеләр күчәсе торак йортны әйткән дә юк. Бар булган измә дә әле безнең өч адым киткәнче биш тапкыр тарала торган машиналар белән урынына илткәнче ташка әверелә. Ул кирпечләрне төкерек сылап ябыштырыйммыни мин?

Үзгәртеп кору икән, үзгәртеп кору! Искечә яшәргә ярамый, диләр. Нәрсәдән башлыйм дип уйлана торгач, үземнән тотынырга карар кылдым. Иң беренче эш итеп кабинетка тагын бер өстәл керттердем. Чөнки элек утыз-кырык минутта тәгәлләнә торган биш минутлыкларны сәгать ярым уздыра башладык. Тыгында утырмасыннар. Аннан, гадиен баш инженерга биреп, үземә төсле телевизор алдырттым. Карагач-карагач төслесен карарга кирәк.

Производствога якынрак булсын өчен баш инженерның кабинетын икенче каттан беренчегә күчердем. Минем кабинетка тагын бер ишек тишеп янәшәдә ял бүлмәсе ясадылар. Начальник та адәм баласы, аның да ял итәргә хакы бар.

Хәзер инде штатлар белән шөгыльләнсәм дә ярый. Кирәкмәс кешеләрең күп дип трестта әллә кайчаннан бирле бәйләнеп киләләр иде, менә беразга киметик әле үзләрен. Кайдан, кемнән башларга? Аппараттан, минем хатыннанмы? Һи-и, аңардан йон да юк, сөт тә юк. Бухгалтериядә утырса да, дебетны кредиттан аера белми. Шулай булгач, аны кыскарттың ни дә, кыскартмадың ни, кала бирсен.

Сыймас җиргә чөй кагып йөрүдән бушамаган Маргарита Ивановна бар, тик аңа кагылырдан алда миңа иң башта районнан чыгып китү җаен карарга кирәк булачак. Райком секретаре хатынын кыскартырга башка тай типмәгән лә! Фатыйма апа — трест управляющие Гали Ганиевичнең энисе белән бертуган апасы. Ә Гали Ганиевич уф димәсә бу дөньяда кирпеч түгел, яфрак та селкенми. Кызыл иренле Клара — партком секретареның кызы. Ут белән уйнасаң да, ул кыз белән уйнама. Ярты ел элек чәпәлгән шелтәдән әле һаман котыла алганым юк.

Аппаратта тагын биш-алты хатын бар-барын, тик аларны кыскартсаң эшне кем эшләр? Планны үтәмәсәң дә отчетын вакытында бирәсе була бит аның. Начальник башым белән үзем язып утырмам ла!

Уйлап-уйлап баш каткач, штаттан кемне чыгару мәсьәләсе белән шөгыльләнергә комиссия төзергә булдым. Аның өчен эшкә тагын бер урынбасар белән ярдәмгә биш кеше алдык.

Комиссия комиссия инде, җиденчеме, сигезенчеме утырышында менә дигән тәкъдим кертте: барыбер төзелешне тулы куәтенә алып барырга материаллар җитми, ташчылар санын киметергә кирәк.

Дөрес бит, әй! Ничек элегрәк үземнең башка килмәгән бу фикер? Участок саен берәр генә ташчыга кыскартсаң да, баш саны шунда ук дүрт кешегә кими. Шулай ит-

тек тә. Унитазлар, раковиналар юклыктан икенче ел инде эшсез йөргән ике сантехниктан да берьюлы котылдык.

Хәзер бу эш буенча ни урынбасарның, ни комиссиянең кирәге калмады инде, аларын кая куярга? Берсенең дә үз теләге белән эштән китәсе килми. Озак баш ватып тормыйча, әлеге комиссияне кыскарту буенча тагын бер комиссия төзергә уйлаган идем дә, трестта рөхсәт итмәделәр. Ярый әле, болар белән нишләргә белми аптырап йөргәндә дәүләт кабул итү комиссиясе дигән нәрсә уйлап чыгардылар, приказ белән барысын да, хезмәт хакларын арттырып, шунда билгеләдем. Дөрес, хәзергә кабул итәр нәрсә юк югын, тик анысы зур бәла түгел, өметне өзмәскә кирәк: ике-өч елдан безнең дә берәр объект төзелеп бетәр әле.

Партоешма секретаре үзгәртеп кору буенча безнең идарәне райком бюросында тыңлаячакларын әйтте. Тыңласыннар, без тамчы да курыкмыйбыз, аллага шөкер, үзгәртеп кору хакында районда түгел, Мәскәүнең үзенә барып та авыз тутырып сөйләрлек эшебез бар. Әнә Ибраев курыксын, төзүдән башканы белгәне юк.

СУГА ЯЗЫЛГАН ХАКЫЙКАТЬЛӘР

Кереш

Кешеләрне иҗат иткән чакта табигать фантазиясен кызганмаган: ахшам күләгәседәй озыннар янында өтер кебек кыскалары бар, берсе балык мичкәседәй юан булса, икенчеләре тал чыбыгыдай нечкә.

Холык, гадәт мәсьәләсенә килсәң, шулкадәр төрлелеккә исең-акылың җитәрлек түгел: юмартлар янәшәсендә сараннарны күреп гаҗәпкә каласың, газраилдәй усаллар белән бер рәттән фәрештәдәй киң, яхшы күңелләләр көн күрә. Ата ялкаулар борын очына кунган чебенне куарга иренеп ятканда, үзендәге эшен төгәлләп күршесенә ярдәмгә йөгерә торган уңган киленнәр, миһербанлы җиңгиләр, ни тотса шуны коеп куючы алтын куллы зирәк агайлар яши.

Кемгәдер акыл «потлап-потлап» бирелгән, икенчеләренә исә тамызып кына өләшкәннәр. Андыйларга нинди генә исем такмаганнар: юләр, исәр, тиле, шыр тиле, дивана, тулар-тулмас һ. б. Безнең авылда, мәсәлән, ир-атның акыл ягын түбәндәгедән чыгып чамалыйлар: әгәр кеше үзен мактаса, урта юләр, хатынын мактаса — шыр юләр, диләр. Халык белән бәхәскә керәп булмый, шуңа күрә мин ни үземне, ни хатынны мактамаска тырышам.

Көн-төн лыгырдап, бөтен кешене туйдырып бетергән бер егеткә лыгырдык Габасс дип кушамат такканнар иде. Берәү, солдатта хезмәт итеп кайтканнан соң, өч көн үткәч кенә «исәнмесез» дип әйткән, имеш. Ышанам, ни булмас бу дөньяда.

Ләкин безнең тормышта шушы кадәр бай характерлар янында атаклы Хуҗа Насретдиннар, барон Мюнхаузеннар яшәмәсә, дөньяның бер чите китек, төсе сыек, ямеким булыр иде. Кеше ышанмасын белә торып «тузга язмаганны» сөйләүчеләр авыл саен очрый һәм аларга халыкның ихтирамы бер дә кимеми, минем бу кырык алдарларның берсен дә халыкның яманлап сөйләгәнен ишеткәнем юк. Киресенчә, аларның исемнәре яратып искә алына, ә төрле кызык хикәяләрен телдән телгә күчереп йөртәләр, җитмәсә, үзләреннән дә кушып, өстәп җибәрәләр. Заманында мондый тапкыр, җор күңелле кешеләр авылның радио һәм телевидениесен дә алыштырганнар.

Озак уйланып йөри торгач, мин шундый фикергә килдем: ә нигә әле безнең атаклы якташларыбыз турында авылдан читтә дә белмәскә тиешләр? Тимерне кызуында сугарга яратанга, җиде төн уртасында сикереп тордым да ут та кабызып тормыйча, тәрәзәдән төшкән ай яктысында ишеткән-белгәнне язарга утырдым. Яза торгач, мавыгып китеп, дөньям онытылган, иртәне кичтән, уенны чыннан, булганны булмаганнан аермый башлаганмын. Хәтта геройларымның исемнәренә кадәр буталып беткән. Хәер, андый гына гөнаһны, әгәр чыннан да гөнаһ дип әйтергә яраса, мулла кызыннан да табарга мөмкин диләр бит. Бәйләнәсе җиренә тәнкыйтьчеләр барыбер бәйләнми

калмас, шуның өчен алар тәнкыйтьче бит, ипиләре шул. Ә укучыларым мине гафу итәрләр, әз-мәз кыегына күз йомарлар, килмәгән җирен китереп укырлар дип өметләнәм. Беләм ич: алар үзләре дә җор табигатьле, борын салындыруның ни икәнен белми торган һәм бераз гына «су кушарга», ягъни арттырып сөйләргә яраталар.

Бәдретдиннең куян тотуы

Тыйнаклыгым аркасында гомергә көч-куәтем белән мактанып йөрмәдем. Ә гайрәт бар иде, ба-ар. Алты потлы кистән белән бүре ауларга йөргәнне сөйләп тә тормыйм, анысын, кайткач, бабагыздан сорарсыз. Бүреләр, мескеннәр, мине күрүгә йөрәкләре ярылып, чабып барган җирдән егылып үлә иде.

Әзмәверләр көче булса да, сабантуйларда көрәшергә чыкмадым — Гыйззебанатымны ирсез, балаларны атасыз калдырасым килмәде.

Көче көч инде аның, яшереп булмый, ә менә җитезлегемне, куян куарга туры килмәсә, үзем дә белми үлеп китәр идем.

Ничек булды дисезме?

Төшәү елны, ягъни өйләнешкән елны әйтәм, теге ике катлы таш йортның икенче катында Гыйззебанат белән яратышып туймый ятабыз. Берзаманны тәрәзә аша өйгә төшкән ай яктысы кимегәнгә күтәрелеп карасам, сыер кадәр ике куян авыз ерып торалар. Әй, ачуым чыкты шуларга! Яңарак кына үргән тал читәнне кимереп, сарык сыярлык тишек ясаганнарые, ничек яткан булсам, шулай ак күлмәк-ыштаннан сикереп тордым да башка малахайны, аякка чабатаны эләктереп (анысының киндерәсен бәйләргә дә онытканмын) чыгып йөгердем болар артыннан. Алар элдерәләр, мин бастырам, алар чаба, мин куам. Куяннар да тиле түгел, иң биек тауның иң текә җиренә менеп киттеләр. Янәсе, мин менә алмам. Мин — алар артыннан. Кыш көне бит, кар күп, аяк тая. Алай да бишалты гына сикердем тау башына менеп җиткәнче.

Соңыннан белдем: минем аяк шудырган кар белән

безнең ишек күмелеп калган да Гыйззебанат аны ачып чыга алмый интеккән, тәрәзәдән йөргән икән.

Ярар, Гыйззие үз өендә дигәндәй, ул калып торсын әле. Куам шулай куяннарны. Ает кулы чокырын чабып чыгып киттеләр болар, мин дә бер генә ыргылдым артларыннан. Аннары Карагаш кулын сикереп уздык. Күрәм, куяннарның берсе сулга каера башлады. Әһә, мин әйтәм, Бәдретдин абзагызны алдый алмассыз, икегә аерылып качарга уйладыгызмы? Утыртма читәнне кимергән өчен дә, кеше йоклаганда тәрәзәдән карап көлеп йөргән өчен дә ачу килгән чак, кесәдә — чүкеч, кулда — пычак. Юләр әйткәндәй, сулга каерганын, көтүдәге качкын сыерны борып китергәндәй, кире эзенә төшердем бит.

Тора-бара безнең авылның кыр-яланнары бетеп Урманай җиренә кердек. Инде, илаһем, куяннарым тирләп чыкты. Мин дә, берсен тотам дигәндә, аяк таеп, башым белән зур көрткә төртелдем. Килгән шәпкә кар өемен егерме метрлап тишеп барганмын. Борылып карагач үзем дә аптырап калдым, артымда зур чокыр. Әле генә юк иде, кайдан килгән бу, мәйтәм. Әфсен белән казылганмы әллә дим, җен-пәринең булуына ышанмасам да. Үзем шуып барган эз икәнен уйларга акыл җитми. Эшнең нидә икәнен аңлагач сикереп торган идем — бүрек юк. Аны табып, каккалап кигәнче куяннарым күздән югалганнар. Ну, үземне дә эт затыннан түгел инде диген син: иснәнеп эзләреннән киттем боларның. Әкрен барсаң туңдыра, тиз барсаң өшетә, чабам гына буш ялан буйлап. Яктырган чакта күреп алдым тегеләрне. Җан-фәрманга элдерәләр генә мин сиңа әйтим. Шул көе күздән яздырмыйча, моннан кырык чакрымнар ераклыктагы Чәкән дигән авыл янында куып тоттым мин куяннарны. Әле ничек диген! Чабып барган җирләреннән икесенең дә арт аякларыннан берьюлы эләктереп алдым. Куяннары да таза иде шул: берсе-берсе бозау чаклы. Ким дигәндә алтышар пот. Җиде потка тартулары да мөмкин. Чөнки үземне кардан әллә ни гомер өстерәп бардылар.

Хәлләрен бетереп туктаткач нишләргә икән дип баш вата башладым. Бу көе кайтырга чыксаң, ардыра төшкән,

тирләткән дә. Җитмәсә, бер кат күлмәк-ыштаннан бит мин. Әйткәнемчә, алтышар потлы ике куян да җилкәгә салынган. Алар мине тешләгән, тырнаган булып маташалар — болай күтәреп әллә кая барып җитә алмам, суык тидереп чирләп китүең дә бар, Бәдретдин, дим. Туктале, мәйтәм, мине бу куяннар хәлдән тайдырды, кызык итим әле үзләрен. Чәкән базарына барганда кереп йөри торган Микулай ызнакум бар ие, шуңа сугылырга булдым. Берәр җае чыкмый калмас, мәйтәм.

Кердем тегеңә. «Ай да вай, Бадри,— ди бу исе китеп,— ничек тоттың, бик нәселле куяннар икән. Кырык ел аугa йөреп ни татар җирендә, ни башкорт яланында моның ишеләрне очратканым булмады»,— ди. Мин, үзегез беләсез, күп сөйләшә торган кеше түгел, мактануны җенем сөйми. Микулай ызнакумның кунакка йөри торган артлы җиңел чанасын сорап алдым, ике куянны тәртәләр арасына кертеп җиктем, әй, икесенә бер дуга куеп! Үзләрен авызлыклап җибәрдем. Микулай дәдәйнең исе-акылы китеп тора, һаман ай да вай дип, башын чайкый. Алдагы базарга килгәндә кертермен дип, төлке тунын алып кидем, аю толыбын бөркәндем дә, әллүр капкадан! Чыккан чакта кызулык белән чак кына бер ялгыш китте китүен: чана үрәчәсе белән орынып, капканың бер имән баганасын сындырганмын.

Куяннар таза, чана белән мине җилтерәтеп тартып очалар гына юл буйлап. Ялкаулана башласалар чыбыркы очы белән бераз тамызып алам үзләренә. Сәгать ярым дигәндә кайтып та җиттем үзебезнең авылга. Куяннарны тугарып абзарга кертеп яптым. Дулап абзарымны җимерә яздылар. Хатын боларның яннарына чыгарга курка, бик таза куяннар, ди. Аларны ашату-эчертү берүземә калды. Затлы куян күрергә дип авыл халкы да, читтән дә килә башладылар. Ахыр чиктә, бер сарыкның аягын тибеп сындыргач һәм икенчесенең тешләп койрыгын өзгәч, ачуым килеп, бу куяннарның икесен тиң суеп ташладым. Гыйззебанат белән рәхәтләндек кенә итләренә: ике тапкыр бәлеш пешерергә җитте.

Бәдретдиннең фронттагы еллары

Кемгә ничектер, минем үземә сугышның буеннан-буена, ягъни башыннан азагына тикле катнашырга туры килде.

Дәбрәбүлис булып килеп төштем фронтка. Ну, мәйтәм, фашист тәресе, чыда гына, бугазыңнан алырга Бәдретдин Биктимер улы үзе килде. Иң баш командир янына кереп, үзебезчә:

— Әссәламегаләйкем! — дип сәлам бирдем.

Сәламемне алгач, сорый бу:

— Син кем, кайсы яктан?

Командир янында күп сөйләшергә ярамый, чатнатып җавап биреп барам:

— Азнакайдан, иптәш командир!

Азнакай кадәр Азнакайны ишеткәне юк икән, ә безнең авылда аны өч яшьлек бала да белә. Бер картага, бер штабтагыларга караганнан соң сорады:

— Ә кайда соң ул сезнең Азнакай?

— Безнең Әсәй янында, иптәш командир!

— А-а! Күптән шулай диләр аны.

Кыюлыгым җитеп гозеремне белдереп калырга ашыктым:

— Иптәш командир, сугышка мин күп сөйләнеп вакыт уздырырга килмәдем, давай, мәйтәм, тизрәк җибәр син мине разведкага!

Командир минем буй-сынны баштанаяк күздән кичердә дә янындагыларның берсенә әйтте:

— Гринюк, Остапка ярдәмче кирәк дигән идеңме әле?

— Так точно, иптәш командир.

— Алайса рядовой Биктимеревне аның карамагына тапшыр.

Их, мәйтәм, эшләр пеште болай булгач, разведкага беренче баруымда ук Гитлерның үзен үк булмаса да берәр атаклырак фюрерларын эләктереп кайтам икән. Ышаныч күрсәтүе өчен командирга рәхмәт укыйм. Бүген үк түкми-чәчми бу хакта Гыйззебанатыма хат язарга кирәк.

Гринюк мине кыр кухнясына алып килде.

— Менә, Остап, бу иптәш разведкага дип атлыгып тора. Тамагын туйдыр да, интектермә, җибәр син аны разведкага. Чалгы, сәнәгең бармы?

Әһә, мәйтәм, болар алдан ук маскировка ягын да кайгырталар икән.

Гринюк киткәч Остап белән иплэп кенә таныштык. Ул миңа мул гына итле ботка салып бирде. Эшкә нык булсам да, үзегез беләсез, тамакка нәзберек мин. Бишенче кәтилүкне көч-хәл белән ашап бетердем. Югыйсә Остап кыстый да кыстый.

— Рәхмәт, җитте,— дим.— Әйдә син миңа аңлат, кайсы якка, кем белән разведкага барырга? Задание нинди?

Остап көлә:

— Ат җигә беләсеңме?

— Тиз җигү буенча, теләсәң, әйдә ярышабыз!

— Ул чагында әнә теге җирән алашаны җик тә, урман буеннан печән чабып алып кайт.

— Һи, шул гынамы?

— Беренче тапкырга җитеп торыр.

Арбага чалгы белән сәнәк салдым да киттем разведкага. Немец мине печәнгә килгән икән дип уйласын әле чыннан да.

Печәнне чабып алдым да арбага төяп бетермәдем, җирне тетрәтеп көтмәгәндә бер танк килеп чыкты. Мин аны башта үзебезнекедер дип уйлаган идем. Карыйм, тәресе бар тегенең маңгаенда һәм туп-туры миңа таба килә. Ни гранатам юк, ни мылтыгым арбадагы печән астында калды. Инде ни эшләргә? Сизеп торам, буыннар сыекланa төште сыман. Якында гына күптән түгел казылган бер тирән чокыр күреп алдым. Яшисе килә бит, җан-фәрманга шунда йөгердем. Сәнәкне үземнән калдыру юк. Танк минем арттан куа килә. Чокыр төбенә постым да утырам сулыш алырга да куркып. Ә мәлгунь дошманнар кораллары булса да миңа атмыйлар, люктан башларын чыгарып:

— Ыздаваес! —дип кенә кычкырдылар.

Минем бирелмәгәнне белгәч, ачуланып, танк белән чокыр өстенә килә башладылар. Өскә балчык коела, күзгә

тузан керә. Үлемем шушы икән, мәйтәм Гыйззебанатым тол, балаларым ятим кала икән. Юк, болай гына үләсе килми бит. Куркуым узды. Үземне сүгәм: нишләп чокыр төбен тычкан сыман саклап утырасың, дошман белән көрәшергә кирәк, дим. Шунда сәнәгемне ике куллап кысып тоттым да җан ачысы белән танкны әйләндереп торып җибәрдем. Яшисең килсә көч арта икән ул. Ята фриц танкысы корсагын күтәреп, чылбырларын әйләндереп.

Траншеядан сикереп чыктым да әйләнеп йөрим танк янында. Бер заман моның чылбырлары әйләнүдән туктадылар. Карыйм, әкрен генә люк ачыла башлады һәм берсенең башы күренде. Мин ялт тегене сәнәккә! Күтәреп алып болгап-болгап-болгап тордым да, чөеп җибәргән идем, каен башына эленеп калды бу.

Икенчесен дә шулай хәл иттем.

Өченчесе чыкмый да чыкмый. Шуннан кычкырам тегеңә нимесчәләп:

— Айн, цвай, двай! Чыгайт будешь? Ату танкыңны яндыраусь!

Нимесчә бик каты кисәтеп әйткәч курыкты бу. Башта ике кулы күренде. Миңа шул гына кирәк тә. Кулларыннан сөйрәп чыгардым да, ул-бу уйламаслык булсын дип, ипи шүрлегенә берне менеп төштем. Күреп торам: бусы әфисәр кисәге. Коралларын алдым да үзен дилбегә белән бәйләп ташладым.

Инде бу танкны нишләтергә? Калдырып китсәң, хуҗа табылыр. Өр-яңа танк бит, яндырсаң — кызганыч. Сәнәк белән танкны урынына кире бастырырга тырышып карыйм, кая ул — көч җитми. Кыймшатып та булмый. Ну, сез минем башның ничек эшләгәнен беләсез. Печәнне ал күчәрдән күтәреп аттым. Арба кендегенә аркан тактым да танкны ат белән тарттырырга керештем. Бер талпынды бахбаем, ике талпынды җанкисәгем. Үзем аңа күсәк белән кизәнеп ярдәм итәм. Тәки өченче талпынуында танкны аягына бастырдык бит икәүләп.

Аннары печәнле йөкне ал күчәргә күтәреп утырттым. Атны тугарып, йөкне танкка тактым, җирән алашаны

арба үрәчәсенә бәйләдем. Фашист эфисәре ята җирдә ни тере, ни үле хәлдә. Аның кулын бәйләгәнне чишеп үзен танк эченә алып кердем. Үзем кулда аның пистолетын тотып торам.

— Кабызгаись! — дим тегеңә нимесчә. Минем белән шаяруның юньлегә алып бармаганын аңлаган иде инде ул, «әйт» дигәнгә «тәйт» дип кенә тора. Остап янына кайтырга кузгалган гына идек, күңелемә шик төште: ә безне, дошман танкысы дип уйлап, юк итеп ташласалар!

Туктаттым да танкны, сәнәк очына бер кочак печән кадап, сәнәк сабын танкка беркетеп куйдым. Ничек тә аңларлар, мәйтәм, тилебәрән орлыгы ашамасалар.

Безнең танкны күрүгә бәрәңге әрчеп утырган Остап су мичкәсе эченә кереп качмакчы иде. Люктан башны чыгарып кычкырдым тегеңә:

— Нәрсә шыр җибәрәсең? Үзебезнекеләрне танымый башладыңмы әллә? Бу мин, гвардий рядовой Бәдретдин Биктимерев бит! — дим.

Барыбер танктан төшеп өстенә бер чиләк салкын су сипмичә Остап аңына килмәде.

Нимеч эфисәрен үзем штабка илтеп тапшырдым. Ә танк белән атнадан артык су ташып, печән кайтарып, складтан азык-төлек китереп, аны вак-төяк эшкә файдаланып калдык. Әллә үзебезнең колхозга озатыйммы икән дигән уй да килгән иде башка, затлы малның кадерен белмәсләр дип курыктым.

Ун-унбиш көннән соң, генерал кушуы буенча, ул танкны бездән алдылар. Менә бу орденны,— Бәдретдин карт елга бер тапкыр гына тагып чыга торган медаленә төртеп күрсәтеп алды,— әнә шуның өчен бирделәр.

— И, оланнар, разведка-разведка дип йөреп, шулай килеп каптым кухняга. Гвардий рядовой Биктимеров Бәдертдин утын кисә дә бәрәңге әрчи, савыт-саба юа, казан кыра да ат карый. Гыйззебанатыма дөресен язарга кулым бармый. Өйдә мин бәрәңге әрчеп караган кешеме! Язсам да ышанмас иде минем Гыйззебанат. Чөнки мин өйдән разведчик булам дип чыгып киткән кеше ласа! Стрәпкә

булдым дип хат язмый торырга да ярамый. Йә мине үлгәнгә санап, Гыйззебанатыма берәрсенең күзе төшә башлар. Җиңгәгез бит дөньяда бер чибәр иде. Язам тегеңә, махсус задание үтим, ни икәнен әйтергә ярамый, хәрби сер дип кенә җибәрәм.

Остап яралангач, кухня эшләре тулысынча минем өскә калды. Рядовойдан ефрейторга, ягъни генералның унөченче ярдәмчесе итеп күтәрделәр. Урыны төтенле булса да җылы, пачут бар, тамак тук. Бер көнне эфисәрский составка бәлеш пешереп ашаткан идем, телләрен йота яздылар. Ничек пешердең дә ничек пешердең, диләр. Ә мин сер бирә торганнардан түгел.

Шулай да күңел түзми. Йә разведкага, йә алгы сызыкка күчерүне сорап яза торгач, ниһаять, хәлемә керделәр бит. Передовойга эләктем. Фрицларның борын төбендә генә ятабыз. Йоклаганда гырлаганнарына тиклем ишетелә. Бер атна эчендә ике тапкыр наступлинжага да бардык. Батыр ярасыз йөрмәсен дигәндер, сул кул башын фашистның бер саташкан пулясы сыдырып үтте.

Үзем передовойга эләккәнче тамак кайгысының ни икәнен белми йөргәнмен икән, бер атна эчендә аңладым. Солдатлар монда поварларның ата-бабаларын җәһәннәмгә олактыралар:

— Вәт элек телеңне йотарлык тәмле итеп пешерәләр иде. Бу поварларның ыштаннарын салдырып, арт яклырына утлы кисәү басарга кирәк,— диләр. Командирга зарланалар.

Мин, әлбәттә, шым гына утырам, тегеләрне мактамыйм да, яманламыйм да. Пешергәннәре чыннан да авызга алырлык түгел: я тозлы, я ярмасы пешмәгән. Солдатларның элек мин пешергән ашны сагынып искә алулары күңелне кытыклый.

Алгы сызыкка эләгүемә атна-ун көннәр үттеме икән, безнең янга генерал килеп төште. Тфү, шайтан, генералның машинасы гына иде, чак арттырып җибәрмәдем. Машинадан ябык кына бер эфисәр чыкты да командирыбыз блиндажына кереп китте. Генерал үзе дә, машинасы да көн саен безнең ротага килеп тормый, шуңа күрә көтәбез

без аяктан егарлык бирәр хәбәр. Күпмедер вакыттан соң командирыбыз ишекне ачты да:

— Биктимерев, минем янга! — дип кычкырды. Биктимерев дигән абзагызның мин икәнен беләсез инде сез. Тез буыннарым калтыраганын сиздертмәскә тырышып барып кердем. Үрә катып:

— Туварищ командир, вашей приказанжю ефрейтер Биктимерев җәвился! — дидем. Уң кулда мылтык иде, каушаудан честьны да ялгыш сул кул белән биргәнмен. Әллә сизмәделәр, әллә сизеп тә эндәшмәделәр.

— Әйдә, җыен, дивизия штабына барасың! Генерал янына,— ди командир.— Биш минуттан машинада утырган бул!

— Җесть! — дим.

Передовойдагы солдатның нәрсә, кәтилүк белән кашыкны капчыкка тыктым да машинага таба киттем. Сорый солдатлар:

— Кая китүең, Бодрушка?

Ә мин борчакны эредән сиптерәм:

— Генерал Капитанов үзе чакырткан, мәйтәм, чәй кайнаган дип әйтә, ди.

Безнең генералның фамилиясе Капитанов иде, әле ничек Ефрейторов түгел диген син! Ул да тапкан фамилия. Капитанов фамилияле генералга караганда Генералов фамилияле капитан булуың мең кат әйбәтрәктер, мөгаен.

Киттек шулай генерал машинасында. Мин артта утырам, шофер белән янәшәдә майор. Үземнең эчне туктаусыз корт кимерә: ниндирәк гаепләрем бар икән, штабка, генерал тикле генерал янына, тикмәгә чакыртмаслар бит? Элегрәк язган рапуртларымның берсен, разведкага җибәрүләрен сорап, генералның үзенә адреслаган идем. Шуңа түгел микән, дип фараз кылам...

Аның берьюлы ике футбол тубын йоткан төсле кабарган корсагына, метр ярымнан чак кына калкурак буена, иягә бәйләп үстергән сыман кәкре аякларына күз салгач, Бәдретдин агайдан нинди «җитез» разведчик чыгачагын күз алдына китерү кыен түгел иде.

— Шуннан, туганнар, теге майор белән генерал янына кереп үрә каттым. Генерал минем белән кул биреп күреште, кочаклап алды. Майорны чыгарып җибәргәч, үз янәшәсенә утырырга кушты. Мин ышанырга да, ышанмаска да белми, кыяр-кыймас кына барып утырдым. Ашарга китерттте. Чүмәләдәй өеп икебезгә дә берәр савыт ботка бирделәр.

— Аша, Биктимерев! — ди генерал, әллә кыстый, әллә әмер бирә, аңламассың.

Мин уйлыйм инде: рас генерал тикле генерал үзе янына утыртып кыстый-кыстый ботка ашата икән, значится, миңа гадәттән тыш важный берәр задание бирә икән, мин әйтәм. «Любой эшне бир, генерал абзый җаныкаем, башымны, соңгы тамчы канымны җәлләмим», — дим эчтән генә. Күңелем нечкәрүдән күземә яшь килде.

Их, мәйтәм, хәзер кәртечкәгә төшеп авылга җибәрәсе иде, Гыйззелбанатымның ике күзе дүрт булсын иде. Һе, теләсә кемгә генерал белән бер өстәлдә ашау эләкми ләбаса. Кая бергә ашау, кайберләре, дүрт ел сугышып, тере генерал да күрми кайттылар.

— Аша, аша, ефрейтор Биктимерев! — дип, генерал абзый бәгырькәем тагын әйткәч, үрелдем боткага. Алып каптым калак очына гына эләктереп. Капитанов, гашыйк булганмыни, туп-туры миңа карап тора. Валлаһи, мин капканны ул йотып бара диярсең. Каушаудан капканымның тәмен сизми дә калдым, йотып җибәрдем.

— Кабаланма, Биктимерев, кабаланма, — ди генерал абзый бәгырькәем.

Сизәм, ул нидер мәтәштерергә уйлый. Ашыкмыйча чәйним, һич кенә дә йотарлык түгел, тәмсез бит ботка. Ботка димәсәң хәтерең калыр. Юньлерәк хатынның тавыкка бүрттергән ярмасы да аруррактыр, валлаһи газыйм. Ачтан үләр хәлдәге кешегә ярар да иде әле, минем ашаганга ике сәгать тә тулмаган, әле тагын ике-өч сәгать корсак киереп, рәхәтләнеп кикереп йөрерлек. Генерал карап торгач яхшысынмыйм, калак очына эләктереп, тагын ике-өч тапкыр боткага юлладым да шуның белән вәссәлам. Үтми генә тамакка. Үзем уйлыйм: нуҗәли мине бот-

ка ашатыр өчен генә чакырткан бу? Юк, бик мөһим задание бирергәдер. Ким дигәндә немец генералын урларга кушар бу миңа.

— Аша, Биктимерев, аша! — ди генералым, кыстап.

— Рәхмәт, иптәш генерал, туйдым.

— Тәмлеме?

Менә шайтан, тәмле дисәң, күрәләтә алдашу була. Тәмсез дисәң, поварны яманлау; ризык өстенә сөйләү шулай ук килешми.

Аптырагач әйттем:

— Яшәргә була, иптәш генерал!

— Хәйләкәр татар икәнсең, ефрейтор,— ди генерал, мыегын бөтереп.— Сиңа теләсә нинди эшне ышанып тапшырырга ярый.— Шуннан генерал кулын минем җилкәгә салып әйтте: — Бел, Биктимерев, сугышта тупчы да, әйтик, разведчик та, бик кирәк. Берүзеңнең нимеч танкын әсир иткәнеңне дә беләбез. Разведкага билгеләүләрен сорап рапорт язгансыз икән. Укыдым...

Их, туганнар, тибә йөрәк, дөп-дөп тибә, Гыйззебанатымның куенына беренче кергәндәге төсле тибә. Хәзер, мәйтәм, разведкага күчерә бу мине.

Шуннан генерал Капитанов миңа озак карап торды да әйтте:

— Разведчик булырга теләвең яхшы, синнән менә дигән разведчик чыгар иде...

— Рәхмәт, иптәш генерал!

— Ләкин безнең дивизиядә сиңа разведкадан да мөһимрәк бер эш бар.

— Ышанычыгызны акларбыз, иптәш генерал! — дим, утка кушса — утка, суга кушса суга керергә хәзер торып.

— Иң мөһиме, иптәш ефрейтор, хәзер сугышчыларны тәмле итеп ашату.—Моны ишеткәч тез буыннарым чак сыгылып төшмәде.— Ботканың тәмен үзең татып карадың. Зарланалар да зарланалар солдатлар, сине кабат кухняга кайтаруны сорыйлар.

— Иптәш генерал, мин дә бит калинарный техникум бетермәгән. Өйдә бәрәңге дә әрчеп караган кеше түгел бит мин...

— Димәк, син үзеңнең осталыкны белми йөргәнсең. Минем белән шундый итеп сөйләшә, әйтерсең без ага-братлар менә.

— Иптәш генерал, ә разведка...— дип әйтә башлаган идем, генералым:

— Отставить разговоры! — дип кенә куйды. Аннан соң, каты кагылдым ди микән, генерал абзый бәгырькәем аркамнан сөеп әйтте.— Үпкәләмә, ефрейтор, ач карынга җиңү яулау түгел, җыр да җырланмый. Балтадан да ботка пешерә аласың икән, бу һөнәреңне сугыш беткәч тә ташлама.

Генерал белән, фамилиясе Капитанов кына булса да, бар, бәхәсләшеп торып кара. Кәтилүк-кәстрүл шалтырата-шалтырата, казан болгата-болгата Берлинга барып кердем.

Ә соңыннан теге мин әсиргә алган танкны авылга алып кайтырга сорап караган идем дә, буявы купкан дип, бирмәделәр.

Гармун

— Мактанып кына йөрмим, нинди гармунчы икәнемне болай да беләләр. Уйнап җибәрүемә Гыйззебанатымның еламый калганы юк әле. Аның күз яшьләрен кызганып кына уйнамыйм.

Гармунчысы гармунчы да, тик үземнең гармун гына юк әлегә. Бер заманны миңа яшьтием Сәйфи ахири әйтә:

— Бәдретдин дус,— ди,— Ютазыда бер тальян бар икән, сәдәфләре көмеш, телләре алтыннан икән. Синең кебек кешегә, тирә-юньдә бер атаклы гармунчыга, тегенди-мондый гармун гына ярамый, әйдә шуны барып алабыз,— ди.

Андый затлы гармун турында ишеткәннән соң тәмам ашау-эчүдән яздым, йокысыз калдым. Миңа карап Гыйззебанатым, корыган канатым, шикләнә башлады: янәсе, берәрсенә күзем төшмәгәнме? Ә мин һаман баш ватам: кайдан акча табарга? Ул бит прастуй-мрастуй гармун тү-

гел, сәдәфләре көмеш, телләре алтын. Аның өчен күпме каерасыларын шайтан белгәнме...

Баш вата торгач таптым чарасын — Гыйззебанатым өйдә юк чакта сыерны Сәйфи яшьти белән егып суйдык та, итен сатып, киттек шуның акчасына гармун алырга. Юлда арбага печән чабып салдык. Барып кердек Ютазыга гармун хуҗасы янына. Сат та сат дибез, бер алдына, бер артына төшәбез, сандугачлар булып кына сайрамыйбыз. Юк, бирми генә бит бу:

— Сатлык гармуным юк,— дип кенә җибәрә, сөйләшми дә.

Ялынып-ялварып та саттыра алмагач, тотып кына булса да карарга бирүен сорадым. Бирде. Үзе гармуннан күзен дә алмый. Янәсе, тегеләй-болай итеп бозып куймыйм.

Уйнап җибәрүем булды, гармун хуҗасы телсез калды. Үлмәсә ярар иде дип куркып туктадым. Теге шуннан соң безгә берни әйтмичә эчке якка кереп китте дә аннан ашъяулык алып чыкты. Нишли икән бу дип Сәйфи белән карап торабыз, күзләрне акайтып. Ә ул гармунны ашъяулыкка төрде дә миңа сузды:

— Мә, Бәдретдин, мин аны сиңа бүләк итәм. Синең кебек уйнаучыны күргән-ишеткәнем дә юк иде. Адәм түгел, җендер син,— ди.

Колакларым ялгыш ишетәме дип торам. Аңга килгәч, хуҗа кире уйлаганчы дип, рәхмәт әйттек тә чыгып утырдык атка. Сәйфи Кара айгырга бер генә сыдырды, Ютазыны чыкканны сизми дә калдык. Бераз китүгә, җан түзми бит, гармунны алдым да сыздырап җибәрдем. Кара айгырны туктатып булмый башлады, элдертә генә. Атны тыярга тырышып Сәйфи ахиринең куллары канап бетте. Бер борылмада чана ныграк салулап киткән иде, гармун да, мин дә, Сәйфи ахири дә очып барып төштек. Гармунның телләренә кадәр чәчелгән иде.

— Бәдретдин бабай, печән чабып салдык дигән идең бит... Нинди чана ди ул?

— И-и, энем, сөяксез тел ни сөйләмәс, кинәт кенә кар явып киткән иде шул...

ЭЧТӘЛЕК

Минем туган көнем

Ана
3

Поезд
9

Чалбар
13

Сер
23

Минем туган көнем
27

Өянке
35

Кояш эзләүче малай
52

Суга язылган хакыйкатьләр

Самавыр борыны
70

Булышырга кайттылар
83

Лотерея билеты
87

Бер монолог
92

Суга язылган хакыйкатьләр
95

Әхмәдиев Н. Г.

Ә87 Кояш эзләүче малай: Лирик һәм юмористик хикәяләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.— 110 бит.

ISBN 5—298—00123—8

Бу җыентыкка шигърияттә үз юлын тапкан шагыйрьнең хикәяләре тупланды. Кайбер хикәяләр вакытлы матбугат битләрендә басылып чыккан иде, үз укучысын тапкандыр, дип өмет итәбез.

Ә $\frac{4803010200—014}{М132(03)—89}$ 144—89 ББК 84(2Р-Тат)-4

ОЛЫ ҺӘМ УРТА ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

Ахмадиев Нур Гарипович

МАЛЬЧИК, ИЩУЩИЙ СОЛНЦЕ

Лирические и юмористические рассказы

(на татарском языке)

Редакторы *Л. Хәмидуллин*
Рецензенты *А. Гыйләҗев*
Художнигы *Ю. Денисов*
Художество редакторы *Ф. Хәсьянова*
Техник редакторы *М. Абитова*
Корректоры *С. Мифтахова*

ИБ № 5262

Җыярга тапшырылды 11.10.88. Басарга кул куелды 22.12.88. ПФ 09245. Форматы 84×108 1/32. Типогр. кәгазе № 2. «Литературная» гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 5,88. Шартлы буяу-оттиск 6,3. Нәшер-хисап табагы 5,45. Тиражы 15 000 экз. Заказ Е-559. Бәясе 20 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

20 тиен.